ТР ФАнең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты
Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе

# Әнвәр Хәйри укулары:
# Милли-мәдәни мирасны барлау, өйрәнү һәм пропагандалау юлында

Казан – 2016

УДК 929=512.145(470.41)
ББК 63.3 (2Рос.Тат)
Ә 57

**Редакция коллегиясе:**
*И.К.Заһидуллин* (төзүче),
*А.В.Әхтәмова* (җаваплы редактор),
*И.Җ.Фәйзрахманов* (фәнни редактор)

**Әнвәр Хәйри укулары: Милли-мәдәни мирасны барлау, өйрәнү һәм пропагандалау юлында.** Республика фәнни-гамәли конференция материаллары (Казан, 2015 ел, 27 ноябрь). – Казан: ТР ФАнең Ш.Мәрҗани ис. Тарих институты, 2016. – 188 б. + 16 б.: ил.

**ISBN 978-5-94981-233-4**

© ТР ФАнең Ш.Мәрҗани ис. Тарих институты, 2016

# ЭЧТӘЛЕК

Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары
Г.А. Нигъмәтуллинаның «Ә.Хәйри укулары»нда
катнашучыларга сәламләү сүзе ........................................ 5

## Истәлекләр

**Гатина Ф.Г.** Тарихыбыз, мәдәниятебез күрке –
якташыбыз галим Әнвәр ага Хәйри ........................................ 6
**Гыйлманова Д.Г.** Әнвәр Хәйри – остаз һәм тәрбияче ..................... 12
**Солтанов Ф.М.** Әнвәр Хәйринең Г.Ибраһимов ис. Тел,
әдәбият һәм тарих институтында эшләгән еллары ..................... 16
**Хуҗин Ф.Ш.** Күпкырлы талант иясе ........................................ 19
**Шәйхелисламов З.Р.** Гыйлем мәгарәсенең Әнвәре –
милләт хадиме Хәйри ........................................ 27
**Ямалтдинова С.Т.** Р.Фәхретдин мирасын –
мәктәп укучыларына ........................................ 32

## Мәкаләләр

**Әхмәтҗанов М.И.** Әнвәр Хәйринең татар язма
мирасына кагылышлы хезмәтләре ........................................ 37
**Байбулатова Л.Ф**. Ризаэтдин Фәхретдин мирасын
кайтаруда Әнвәр Хәйринең роле ........................................ 41
**Гыйлметдинов Д.Р.** Совет мәгърифәтчеләре һәм ислам
терминологиясе (татар дини мирасын барлауда
Э.Хәйринең роле) ........................................ 46
**Загидуллин А.З.** Некоторые аспекты комплектования
«Коллекции татарской эмиграции» из фонда
отдела рукописей и редких книг Национальной
библиотеки Республики Татарстан ........................................ 51
**Заһидуллин И.К.** 1905 елда мөселманнарның
Казан губернасыннан хөкүмәткә юллаган петицияләрендә
җәдитчеләр һәм кадимчеләр карашларының чагылышы .......... 55
**Мөстәкыймов И.А.** «Гали хан»мы, «Илһам хан»мы,
«Әдһәм хан»мы? ........................................ 68

**Сәлахова Э.К.** Беренче Бөтендөнья сугышы фронтларыннан язылган татар солдатлары хатларын өйрәнү тәҗрибәсе һәм проблемалар ........................ 73
**Тагиров И.Р.** Отзыв о монографии Анвара Хайри «Новое в переводе на татарский и русский языки повествования Ибн Фадлана о путешествии в Булгарское государство» ........................ 80
**Таҗиева Л.К.** Олпат галимнең мөһим хезмәте ........................ 83
**Мәхмүтова А.Х.** Бәзәкә авылының барлыкка килүе: чыганаклар һәм фаразлар ........................ 88
**Нурхәмәтова Ә.Р.** Әнвәр Хәйринең «Шәһри Бану – Шәрбән кыйссасы» әсәре буенча иҗади эш ........................ 97
**Харрасова Р.Ф.** Узган чорлар шигъриятен шәрехләү проблемасы ........................ 99
**Хәйретдинов А.Г.** Муса Җаруллаһ Бигиевнең куен дәфтәрләре ........................ 107
**Шәфигуллина Р.Ф.** Милли мәгариф һәм тәрбия күзлегеннән Каюм Насыйри мирасы ........................ 111

## Ә.Хәйри язмалары һәм хезмәтләренең библиографик күрсәткече

**Хәйри Ә.** Тәрҗемәи хәлем ........................ 117
**Хәйри Ә.** Хатирәләр яңарганда. Ничек итеп мин 466 төркемнең кияве булып киттем… ........................ 124
**Хәйри Ә.** Төрки-татар кулъязмасы ........................ 135

Әнвәр Хәйринең тәрҗемәи хәлендә һәм эшчәнлегендә игътибарга лаек вакыйгалар ........................ 142
Әнвәр Хәйринең басылган хезмәтләре ........................ 145
Әнвәр Хәйри турында мәкаләләр һәм аңа багышланган башка язмалар ........................ 173

## Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары Г.А. Нигъмәтуллинаның «Ә.Хәйри укулары»нда катнашучыларга сәламләү сүзе

Без бүген Әнвәр Хәйрине – күпкырлы эшчәнлеге, фәнни хезмәтләре белән танылган галимне зур хөрмәт белән искә алабыз.

Әнвәр Хәйри халык белән аның үз телендә сөйләшә торган шәхес, чын мәгънәсендә халык галиме иде.

Борынгы чыганаклар белән эшләүче тәҗрибәле белгеч буларак, ул татар мәгърифәтчеләренең бик күп әсәрләрен тәрҗемә итеп халыкка җиткерде. Милли тарихыбызга караган иң борынгы һәм иң беренче язма чыганак булып торучы – 922 елда Идел буе Болгар дәүләтенә Әхмәд Ибне Фадланның сәяхәтнамәсен хәзерге татар һәм рус телләренә тәрҗемә итеп, фәнни эшкәртеп бастырган китабы бүген республика китапханәләрендә кызыксынып укылучы китаплар рәтендә.

Татар халкының күп гасырлык рухи мирасын кайтарып бирүдән кала Ә.Хәйри татар милли мәгарифен үстерүдәге хезмәтләре, әхлакый һәм рухи тәрбия мәсьәләләренә багышланган язмалары, сәнгать өлкәсенә караган тәнкыйть мәкаләләре белән дә еш басылып чыга иде.

Бүгенге очрашу бу зур шәхесне искә алу булып, аның фәнни һәм әдәби мирасын барларга тагын бер өлеш кертсен иде.

# Истәлекләр

УДК 929=512.145"19/20"(470.41)

**Ф.Г. Гатина**

## ТАРИХЫБЫЗ, МӘДӘНИЯТЕБЕЗ КҮРКЕ – ЯКТАШЫБЫЗ ГАЛИМ ӘНВӘР АГА ХӘЙРИ

*«Галимнәрнең максатлары югары,*
*хезмәтләре авыр һәм изге.*
*Алар өчен Аллаһы Тәгалә*
*ризалыгын өмет итеп һәм халык*
*файдасын да күздә тотып*
*эш йөртү беренче максатта булыр.*
*Шуның өчен болар һәр вакытта*
*хөрмәтле һәм күркәм затлар исәпләнә».*

Ризаэддин Фәхретдин.

*Аннотация.* Истәлек-язмада Аксубай районында туып-үскән Әнвәр Хәйринең туган ягы белән хезмәттәшлеге, 2014 елда Аксубайда аның «Әхмәд Ибне Фадланның 921–922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе» китабын тәкъдир итү кичәсе уздыру турында бәян ителә.

*Ачкыч сүзләр:* Аксубай районы, Ә. Хәйри, китап укучылар, якташлар, мирас.

Аксубай төбәге дөньяга талантлы шәхесләрне күп бүләк иткән як. Танылган шагыйрь Хәсән Туфан, мәгърифәтчеләр Г.Гафуров-Чыгтай, Нәҗип Думави, журналист, публицист, шагыйрь Газиз Кашапов, галим, ислам дине белгече Әнвәр Хәйри, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Роза Туфитуллова, язучы, журналист, психология фәннәре кандидаты Хөсәен Вәлиәхмәтов, танылган язучы Нәбирә Гыйматдинова, язучы Рушания Низамова, яшь драматург Илгиз Зәйниев, авыл хуҗалыгы фәннәре докторы Нәҗип Бакиров,

медицина фәннәре докторы Луиза Фазлыева, Якуп Ибраһимов, төрле өлкәләрдә казанышларга ирешкән профессорлар: Рәис Беляев, Мансур Абдрахманов, Ильдус Зиннуров, Әскәр Хәйруллин һ.б. тарихыбыз, әдәбиятыбыз, мәдәниятебез күгендә якты йолдыз булып балкып яналар.

Үзеннән соң килер буыннарга зур хәзинә – тарихи, әдәби мирас калдырып, Аксубайның данын еракларга танытучы Әнвәр ага Хәйри шуларның берсе.

Әнвәр ага да кайда гына йөрмәсен, туган ягын сагынып яши. Якташларының:

– Читтә йөргәндә, туган авыл сагындырамы, искә төшәме? – дигән соравына, ул болай дип җавап бирде: «Туган як, туган авыл, туган төбәк күзгә күренмәс сихри җепләр белән мәңгелеккә бәйләп куелган: чит илләргә чыгасыңмы, төрле илләрдә, зур шәһәрләрдә, зур залларда чыгыш ясыйсыңмы, табигатькә чыгасыңмы – үз ягың, үз чишмәң суының тәме, яланаяк йөгергән балачак сукмаклары, дус малайлар белән балык тоткан инеш буйлары, учаклар ягып, төн кунып атлар көткән болыннар искә төшә».

Әнвәр ага язлар җитү белән ап-ак чәчәккә күмелеп утыручы бакчаларын, туган авылының Шәрбән елгасы буендагы сандугачлы бөдрә талларын, балыклы инешләрен бернәрсәгә дә алыштыргысыз икәнен аңлап, туган ягын сагынып яши. Һәр кайтуында туганнар, урындагы җитәкчеләр белән күрешеп, сагынуларын баса иде. Олыгайган саен сагыну көче арта гына бара, кайткан саен, мәрхүмнәрнең каберләрен барлый; туганнар, авылдашлар белән күрешеп, аралашып, туган як һавасын сулап, чишмә суларын эчеп, илһамланып, көч алып китә иде. Бигрәк тә авыл Сабантуйларын ярата, район Сабантуеның мөхтәрәм кунагы була. Кайткан саен китапханәгә кереп чыга, буш кул белән керми, үзенең шәхси китапханәсеннән китаплар бүләк итеп калдыра.

2014 елда Аксубайда «Тылсымлы ачкыч тапкан галим» исеме астында Әнвәр аганың «Әхмәд Ибне Фадланның 921–922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе» китабын тәкъдир итү кичәсе оештырылды. Язучы һәм китап укучы арасында, китапны дөрес итеп тиешле укучыга җиткерүдә иң мөһим роль уйнаучы арадашчы хезмәтен башкаручылар – китапханәчеләр. Үзәк китапханә хезмәткәрләре көче белән, кичәгә килүчеләрнең күңелен җәлеп итәрлек итеп, фойеда «Мул җимешле иҗат» исемендә китап күргәзмәсе оештырылды. Күргәзмәдә галимнең иҗат мирасы – ба-

сылып чыккан китаплары һәм аның иҗат юлына багышланган мәкаләләр тупланган папкалар урын алган иде.

Район күләмендә, китапханәләр, мәгариф системасы, музейлар белән үткәрелгән бу чарада миңа сценарий авторы һәм алып баручы буларак катнашу, галим белән якыннан аралашу бәхете насыйп булды. Укучылар, укытучылар, китапханәчеләр җыелган зур залда сәхнә түрендә галим – Әнвәр ага. Казаннан чакырылган мөхтәрәм кунаклар арасында халык шагыйре, ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитет рәисе Рәзил Вәлиев, Татарстан язучылар союзы рәисе Рәфис Корбан, ТР мәдәният министры урынбасары Гүзәл Нигъмәтуллина, танылган язучы, якташыбыз Нәбирә Гыйматдинова һ.б. катнашты. Алар үз чыгышларында Әнвәр аганың сирәк галим, фидакарь хезмәт иясе икәнен тагын бер кат дәлилләделәр. Аксубай районы башлыгы Камил Гилманов үз чыгышында: «Мәдәниятне үстерүгә һәм тарихны өйрәнүгә керткән өлешегез бәяләп бетергесез. Сез башкарып чыккан эшләрне хәтта дистәләгән галим дә башкара алмас иде. Без Сезнең белән горурланабыз. Сез Аксубайны данлы итәсез», – диде.

Әнвәр ага үзе башкарган эше турындагы фикерләре белән уртаклашып, бу эшкә 1995 елда алынуы, ничек итеп өч телдә глоссарий төзүе турында сөйләде. Лена апа Таҗиеваны иң яраткан остазым, киңәшчем, диеп атады, хезмәттәшләре, киңәшчеләре – Җ.Тәрҗеманов, Ф.Хуҗин һәм башкаларга рәхмәтле булуын әйтте.

Без – якташлары бу очрашуны зур дулкынлану белән көтеп, сокландыргыч фәнни хезмәт авторына горурланып утырдык. Сораулар биреп алҗытсак та, галимнең гаҗәеп зур хезмәт башкарганын, якташыбызның бөеклеген дә күрсәтә алдык бугай. Һәркемнең күңеленә – үзе зур галим, үзе гади, тыйнак, ихлас, үзе фидакарь булып кереп калды ул.

Без аксубайлылар – якташыбыз, галим Әнвәр аганың бай иҗади мирасына сокланабыз, аның исеме белән горурланабыз. Әнвәр ага аксубайлыларга, Аксубай районының Шәрбән, Карасу, Мокшы, Сөнчәле авыллары тарихын барлап кайтаруда, татар халкының күп гасырлык рухи мирасын кайтарып бирүдә чиксез күп көч куйды.

Без, китапханәчеләр, үз чиратыбызда, галимнең иҗатына багышланган һәр язманы бөртекләп җыеп, аның иҗатын тагын да ныклап өйрәнеп, аның мирасын киң катлау укучыга җиткерүдә, армый-талмый хезмәт итәрбез.

## ӘДӘБИЯТ


1. Гыйлемханов Р. Моны Әнвәр генә булдыра ала иде: [ТФАндә танылган галим, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Әнвәр Хәйринең «Әхмәд ибне Фадланның 921–922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе» дигән китабын тәкъдим итү булды] // Мәдәни җомга. 2013. 29 март (№ 13). 4 б.

2. Әнвәр Хәйри: [некролог] / Татарстан язучылар берлеге: [танылган галим, исламият белгече, язучы, тәрҗемәче Әнвәр Хәйри (2.12.1947–20.07.2014)] // Мәдәни җомга. 2014. 25 июль (№ 29). 4 б.

3. Закирова Г. «Сәяхәтнамә» кайтты: [танылган галим, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Әнвәр Хәйринең «Әхмәд ибне Фадланның 921–922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе» дигән китабы тур.] // Мәгърифәт = Просвещение. 2013. 5 апрель (№ 14). 6 б.

4. Зәкиев М. Ибне Фадланның сәяхәтнамәсе турында Әнвәр Хәйри: [Ә.Хәйринең хезмәте тур.] // Фән һәм тел = Наука и язык. 2013. № 1–2. 119–123 б.

5. Кашапова С. Галимнең гомер китабы: күренекле шәхесләребез / Н. Каштанов; рәссам Э.Зарипов эше // Мәдәни җомга. 2014. 5 сентябрь. № 35. 14 б.

6. Макарова О. Анвар Хайри – в Аксубаево: встречи. (В Аксубаевском районном Доме культуры состоялся творческий вечер ученого и писателя Анвара Хайри в честь 65-летия и презентация его книги «Повествование о путешествии Ахмеда Ибн Фадлана, написанное во время поездки в 921–922 годах в Булгарское государство») // Сельская новь. 2014. 22 января. (№4).

7. Макарова О. Такие рождаются раз в сто лет: память // Сельская новь. 2014. 25 июля.

8. Макарова О. Ученый, историк, воспитатель: знай наших! // Сельская новь. 2013. 16 января.

9. Макарова Ольга. Якташыбызның иҗат кичәсе: очрашу // Авыл таңнары. 2014. 22 гыйнвар (№4).

10. Ногманов Р. Дәүләт бүләгенә лаек хезмәт: [Әнвәр Хәйринең «Әхмәд ибне Фадланның 921–922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе» дигән китабы тур.] // Мәдәни җомга. 2013. 29 ноябрь (№ 48). 16 б.

11. Сафина Т. Заманыбыз каһарманы // Мәйдан=Арена. 2012. №12. 22–31 б.

12. Сафина Т. Искитәрлек шәхес // Мәгърифәт=Просвещение. 2012. 30 ноябрь (№48). 2–3 б.

13. Сафина Т. Киңкырлы галим: [галим, язучы һәм тәрҗемәче Әнвәр Хәйри тур.] // Ватаным Татарстан. 2012. 11 сентябрь (№ 179). 7 б.

14. Хайруллин Анвар Назипович [Некролог] / Гилманов К.К., Хамидуллин Ю.Г., Муратшин Р.Х. и др. // Сельская новь. 2014. 23 июля.

15. Хәйри Ә. Төрки–татар кулъязмасы // Идел. 2014. №4. 54–57 б.
16. Хәйри Ә. «Таш йөзә башлаганчы...»: [Россия һәм Татарстан тарихы] // Мәйдан. 2012. № 12. 32–43 б.
17. Хәйри Ә. Болгар иле, яки Багдад хәлифәсе әл-Моксадир илчелегенең Идел болгарлары иленә баруы турында // Мәйдан. 2012. № 12. 44–81 б.
18. Хәйри Ә. Рамазан...: [Рамазан ае турында] // Чын мирас. 2012. № 5–6.
19. Хәйри Ә. Шәһри Бану-Шәрбән кыйссасы // Мәйдан. 2010. № 12. 133–137 б.
20. Хәйри Ә. Язучының бурычы – күңелләргә иман нуры салу: [Г.Тукай исем. дәүләт бүләгенә кандидатлар. Язучы Нәбирә Гыйматдинова иҗаты тур.] // Мәдәни җомга. 2013. 12 апрель (№ 15). 8 б.
21. Хуҗин Ф. Сирәк галим // Мәйдан=Арена. 2012. №12. 84–99 б.
22. Хушлашу: [Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, галим, язучы, тәрҗемәче, публицист Әнвәр Хәйри вафат (2.12.1947–20.07.2014) ] // Ватаным Татарстан. 2014. 23 июль. № 106. 6 б.
23. Ямалтдинова С. Милләт мәшһүр адәмнәре белән мәртәбәле // Мәдәни җомга. 2014. 19 декабрь. №50. 14 б.

**Ф.Г. Гатина**

## Наш земляк ученый Анвар Хайри – известный представитель нашей истории и культуры

*Аннотация.* В публикации повествуется о сотрудничестве Анвара Хайри со своей малой Родиной, рассказывается о проведенной в 2014 г. в Аксубаево презентации его книги «Повествование о путешествии Ибн Фадлана, написанное во время поездки в 921–922 годах в Булгарское государство».

*Ключевые слова:* Аксубаевский район, А. Хайри, читатели, земляки, наследие.

**F.G. Gatina**

## Our fellow countryman the scientist Anwar Hayri is a well-known representative of our history and culture

*Annotation.* The publication describes the cooperation Anwar Hayri with your homeland, outlines about held in 2014 in Aksubaevo the presentation of his book «Narrative of the travel of Ibn Fadlan during your trip in the Bulgar state in 921–922 years».

*Keywords*: Aksubaevsky district, A. Hayri, readers, countrymen, legacy.

**Автор турында мәгълүмат**

**Гатина Фәһимә Гариф кызы** – Аксубай үзәк китапханәсенең халыкка китапханә хезмәте күрсәтү бүлеге мөдире (шәһәр тибындагы Аксубай бистәсе).

**Гатина Фахима Гарифовна** – заведующая отделом по оказанию населению библиотечных услуг Аксубаевской центральной библиотеки (поселок городского типа Аксубаево).

**Gatina Fakhima Garifovna** – Head of Department of library services to population, Aksubaevsky Central Library (Aksubaevo).

УДК 37=512.145"19/20"(470.41)

**Д.Г. Гыймранова**

# ӘНВӘР ХӘЙРИ – ОСТАЗ ҺӘМ ТӘРБИЯЧЕ

*Аннотация.* Мәкаләдә Әнвәр Хәйринең Р.Фәхретдин мемориаль музеена даими рәвештә ярдәм итеп торуы хакында бәян ителә. Галимнең мирасын тирәнтен өйрәнеп китаплар бастыруы, халык белән эшләү алымнары турында языла.

*Ачкыч сүзләр:* Ризаэддин Фәхретдин, Әнвәр Хәйри, музей, нәсыйхәт, кульязма, китап.

«Әнвәр Хәйри синең өчен кем ул?» дип сорасалар, минем өчен Әнвәр абый бик якын кеше, иң беренче чиратта, остаз һәм тәрбияче булуын билгеләп үтәр идем.

Р.Фәхретдиннең туган авылында урнашкан музеена җитәкче итеп билгеләнгән вакытта никадәр җаваплы эшкә алынуымны белсәм дә, галимнең иҗади мирасының тирәнлеген исәпләп бетерә алмаганмын. Музейда эшли башлаганда Р.Фәхретдиннең тормыш һәм иҗат юлына багышланган берничә мәкаләдән кала иркен мәгълүмат та, аның хезмәтләренең тәрҗемәләре дә юк иде. Авылдагы кульязма мирасны барлаган вакытта кулыма ике күн белән төпләнгән, шактый таушалган борынгы китаплар килеп керде. 2000 еллар башында республиканың Милли музее методик үзәк буларак галимнәр белән очрашулар, гыйльми утырышлар оештыра иде. Авылда аларны укый белә торган галим булмаганлыктан чираттагы очрашуга әлеге ике китапны алып барып, аларны кайдан, ничек табуым, әмма аларга тиешле бәяләмә бирә алмаганлыгымны билгеләп чыгыш ясадым. Шул вакытта Әнвәр Хәйри китапларны кулына алып аз гына караштырды да, алар турында киң мәгълүмат әйтеп салды. Музейда кульязма, искечә язылган китапларның күплеген исәптә тотып мин Милли китапханәдә сирәк кульязмалар бүлегендә хезмәт куйган Әнвәр Хәйри белән тыгыз бәйләнешкә кердем. Хәтер төпкелендә тирәнрәк казынсаң, бу галим белән беренче очрашу 1989 елның кышында Кичүчат авылы мәктәбендә Р.Фәхретдиннең тууына 130 ел тулу уңаеннан уздырылган авылдашлар очрашуында булган икән. Ихлас күңелдән, гади халыкка аңлаешлы итеп олуг

галимнең мирасын кайтару кирәклеге турында чыгыш ясаган иде ул. Бүгенгедәй хәтердә әлеге очрашу...

Әнвәр Хәйри Р.Фәхретдиннең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнергә, аның мирасын тәрҗемә кылырга алынган галимнәрнең берсе буларак музейның олы ярдәмчесе иде. Музейга килгән кунаклар галимнең нәсыйхәтләрен, тәрбияви хезмәтләрен турыдан-туры миннән сораганлыктан, бер дә аптырамыйча, мин Әнвәр абыйдан (ул вакытта ул абыем кебек якын иде) аларны кичектергесез тәрҗемә итеп халыкка ирештерү кирәклеген әйтеп эшне тизләтүне сорадым. Ниһаять, «Идел» журналында Р.Фәхретдин хезмәтләренең кисәк-кисәк тәрҗемәләре дөнья күрде. Әнвәр абый озак та көттермичә Р.Фәхретдиннең «Нәсыйхәт»ләрен китап итеп бастырды. Халык арасында тиз арада таралып беткәнлектән китаплар кат-кат басмага бирелде. Меңәрләгән тираж белән чыккан китапларның кереш өлешендә Әнвәр Хәйри Р.Фәхретдиннең күпкырлы эшчәнлегенә, аның мирасына тулы күзәтү ясап укытучыларга, ата-аналарга аңлатмалар язып, әлеге китапларны укып халык тәрбия алсын иде дигән өметләрен баглаган иде.

Ә.Хәйри олуг галим, тәрбияче Р.Фәхретдиннең мирасын халык өйрәнсен, укып белсен өчен республиканың төрле районнарына чыгып даими рәвештә халык белән очрашулар оештыра иде. Татарстан республикасының төрле почмакларында махсус укытучылар өчен оештырыла торган «Р.Фәхреддин педагогик укулар»ын гамәлгә кую аның зур тырышлыгы белән башкарылды. Хөкүмәт тарафыннан бирелә торган «Р.Фәхреддин премиясе»н тапшыру, шулай ук, Әнвәр абыйның тормышка ашкан зур хыялы. Р.Фәхретдиннең мирасын өйрәнеп укучыга җиткерүдә куйган хезмәтләре өчен Әнвәр Хәйри 2011 елда әлеге премиянең беренче лауреаты булды.

Музей ачылуда үзенең дә зур тырышлыгы кергәнлектән, Ә.Хәйри музей эшчәнлегенә мөмкинлекләрдән чыгып һәрвакыт ярдәм итергә ашкынып тора иде. Журналистларны чакырып фильм эшләргә, публикацияләр чыгарырга, китаплар бастырырга, фондларны тупларга, Р.Фәхретдиннең туганнарын барларга, галимнәр белән очрашулар оештырырга, ул һәрвакыт үзенең киңәшләре белән ярдәм итә иде. Галимнең тууына 150 ел тулу уңаеннан туганнар очрашуы үткәргәндә, республикакүләм музей хезмәткәрләре семинары оештырганда үзе килеп кунакларны каршы алу аның өчен зур мәртәбә иде. Якты йөзе, шат күнеле, шаян, ярдәмчел, гади һәм кешелекле булуы белән күпләрне таң калдыра иде ул.

Р.Фәхретдиннең тууына 155 ел тулу уңаеннан музейда Ә.Хәйринең ярдәме белән башкарырга дип планлаштырылган эшләр бисап: Бөтенрәсәй күләмендә конференция үткәрергә, «Сәләт» лагерында тәрбияләнүче яшүсмерләр өчен «Кичүчат–2014» фестивален оештырырга, галимнең гаилә фотоальбомын гыйльми каталог форматында эшләп бастырырга, туганнар очрашуын үткәрергә һ.б. бик күп планнар. Әмма июль аеның соңгы көннәрендә бик аяныч хәбәр килеп ирешкәч, әлеге эшләрне ничек итеп тормышка ашырырга, әллә инде кирәк тә түгелме дигән уйлар биләп алды күңелне. Башланган эшне ташларга һич тә ярамый, Әнвәр абый алай яратмый. Планлаштырылган һәрбер чараны үткәргән вакытта яннан күренмичә генә ярдәм итеп тора сыман тоела иде ул миңа. Барысы да уңышлы гына тормышка ашырылды. «Гаилә кечкенә бер дәүләттер» дип аталган фотоальбом Әнвәр абыйның гыйльми күзәтүе астында бергәләп эшләнгән соңгы китап булып басылып чыкты. Ә алда без аның белән Р.Фәхретдиннең юбилее уңаеннан гына түгел, ә киләчәккә төзегән планнар да юк түгел, башкарып чыгарга насыйп булсын.

Чынлыкта исә, «Әнвәр Хәйри минем остазым, тәрбиячем», – дип әйтергә теләүчеләр еш очрый. Аның белән даими рәвештә семинарларда, очрашуларда катнашканлыктан, халык Әнвәр абыйны үз иткәнен, гыйлем әһеле булуына карамастан, гадилеге белән халык мәхәббәтен яулаганлыгын мин шәхсән үзем күрә идем. Очрашулар вакытында Әнвәр абый белән фотога төшергә теләүчеләр чиратка тезелә торган иде. Озак еллар дәвамында укып-өйрәнеп белемен тирәнәйткән, шул ук вакытта, туплаган гыйлемен киң катлам кешеләренә киңәшләр биреп таратырга омтылуы игътибарга лаек. Аны якыннан белгән галимнәргә, янында эшләгән хезмәткәрләргә, укытучыларга, укучыларга, аларның ата-аналарына, гомумән, аның белән аралашкан һәр кешегә Әнвәр Хәйри – үрнәк галим, остаз һәм тәрбияче иде.

**Д.Г. Гимранова**

## Анвар Хайри – педагог, наставник

*Аннотация.* В статье пишется о постоянной научно-методической помощи Анвара Хайри мемориальному музею Р.Фахреддина. Излагается материал о работе Анвара Хайри с рукописями ученого-просветителя Р.Фахреддина и о переиздании изученного материала.

*Ключевые слова:* Ризаэддин Фахреддин, Анвар Хайри, музей, наставления, рукописи, книга.

**D.G. Gimranova**

**Anvar Hayri is teacher**

*Annotation.* In the article written about the permanent scientifically-methodical help of Anvar Hayri to the memorial museum of Riza'ddin Fakhreddin. Material is expounded about working as of Anvar Hayri with the manuscripts of scientist-enlightener R.Fakhreddin and about reediting of the studied material.

*Keywords:* Riza'ddin Fakhreddin, Anvar Hayri, museum, discipling, manuscripts, book.

**Автор турында мәгълүмат**

**Гыйматранова Диләрә Габделкави кызы** – филология фәннәре кандидаты, Ризаэддин Фәхреддин мемориаль музее директоры (Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Кичүчат авылы); e-mail: gimranova.dilyara@yandex.ru

**Гимранова Диляра Габделкавиевна** – кандидат филологических наук, директор мемориального музея Ризаэддина Фахреддина (Республика Татарстан, Альметьевский район, с.Кичучатово).

**Gimranova Dilyara Gabdlkavievna** – candidate of philological sciences, Director of memorial museum of Riza'ddin Fakhreddin (Republic of Татарстан, Al'met'evsk region, v.Kichuchatovo).

УДК 929=512.145"1974/1991"(470.41)

**Ф.М. Солтанов**

# ӘНВӘР ХӘЙРИНЕҢ Г.ИБРАҺИМОВ ис. ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ТАРИХ ИНСТИТУТЫНДА ЭШЛӘГӘН ЕЛЛАРЫ

*Аннотация.* Язмада Әнвәр Хәйринең 1974–1991 елларда Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм тарих институтының иҗтимагый фикер тарихы бүлегендә фәнни хезмәткәр булып эшләгән вакыттагы фәнни эшчәнлеге шәрехләнә.

*Ачкыч сүзләр:* татар иҗтимагый фикер тарихы, Әнвәр Хәйри, Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм тарих институты, татар кулъязмалары, чыганаклар.

Без Әнвәр Хәйри белән, ул – кече фәнни хезмәткәр, мин – аспирант буларак, фәнгә 1974 елда килдек һәм унҗиде ел дәвамында бер бүлмәдә утырып эшләдек. Остазыбыз фәлсәфә фәннәре докторы Яхъя ага Абдуллин Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында туплаган һәм тора-бара бүлеккә әверелгән иҗтимагый фикер тарихы төркеменең әле беренче адымнарын гына ясый башлаган чагы иде. Советлар илендә хөкем сөргән идеология нигезендә татарның бик күп зыялы затларына – Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдинов, Г.Курсави, М.Бигиев, Садри һәм Һади Максудилар һәм башка шундый күренекле шәхесләргә – «буржуаз милләтче» тамгасы сугылып, аларның фәлсәфи, тарихи һәм мәдәни мирасларын өйрәнү тыелган һәм хәтта исемнәрен дә уңай яктан телгә алырга да ярамаган чор иде бу. Ләкин, ничек кенә булмасын, хөр фикерле татар галимнәре халкыбызның чынбарлык үткәнен өйрәнүне туктатмыйлар һәм әкренләп кенә булса да милләт хәтерен яңартырга омтылалар. Әнвәр Хәйринең «Татар иҗтимагый фикер тарихында Ш.Мәрҗанинең урыны» (1974), «Р.Фәхретдиновның кулъязма мирасы татар иҗтимагый фикер тарихын өйрәнүдә чыганак буларак» (1985), «Курсави һәм Мәрҗани мирасларында традиционализмны тәнкыйтьләү» (1987) кебек рус телендә басылып чыккан беренче мәкаләләре моңа ачык мисал булып торалар. Шушы юнәлештәге эзләнүләре Әнвәрне тагын да җитдирәк эшкә – Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар»

(Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр) исемле хезмәтен татарчага тәрҗемә итүгә алынырга этәрә.

Ике томнан торган «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» әсәре халкыбызның борынгы заманнардан алып XIX йөзнең икенче яртысына кадәр булган тарихын, мәдәният һәм иҗтимагый фикер тарихын өйрәнүдә хаклы рәвештә кыйммәтле чыганаклардан санала. Татар телен камил белгән, гарәп-фарсы алынмаларыннан нык хәбәрдар булган һәм бигрәк тә борынгы төрки кулъязмаларны укуда гаять тә тәҗрибәле Әнвәр, илдәге сәяси үзенчәлекләрдән чыгып, әлеге хезмәтнең кыскартылган вариантын бер китап итеп 1989 елда Татарстан китап нәшриятында бастырып чыгаруга ирешә. Иҗтимагый һәм гуманитар фәннәр өлкәсендә тикшеренүләр алып барган галимнәр, тәрҗемәләрнең камиллегеннән тыш, басманың комментарийларына аеруча игътибар итәләр. Ә мондый чыганакка аңлатмалар бирү үзе бер мөстәкыйль фәнни хезмәт язуга тиң. Бу китапның дөнья күрүе татар фәнен үстерү юлында зур һәм мөһим вакыйга булды.

Ризаэтдин Фәхретдинов мирасын барлауда Әнвәр шулай ук бик кирәкле һәм кыю эш башкарды. Ташкент, Бохара, Ленинград, Мәскәү, Оренбург,Уфа шәһәрләрендәге архив һәм китапханәләрдә эзләнүләр алып барулары нәтиҗәсендә, ул бай материал туплый алды һәм аларның күчерелмәләрен Казанга алдыртуга ирешә. Әлеге мирасны халыкка таныту йөзеннән Әнвәр Р.Фәхретдиновның күп кенә хезмәтләрен нәшер итте, һәм яшь буынны әхлаклы итеп тәрбияләүдә алар бүгенгесе көндә киң кулланылыш табалар.

Әнвәр Хәйри чын мәгънәсендә бик күпләргә гыйльми консультант булды, һәркемгә дә ярдәм итәргә тырышты, берәүне дә кире борып җибәрмәде. Минем үземә дә фәнни хезмәтләремне язганда аның булышлыгы байтак тиде. Ул коллективның җаны иде, һәр кичәдә моңлы итеп җыр сузды, халыкчан мәзәкләр сөйләп күңелне күтәрде, яшәргә дәрт өстәде. Милләт өчен янып яшәде ул. Татар милли хәрәкәте кузгалгач та, Әнвәр аның алгы сафында булды, милли мәгариф комитеты эшен җәелдереп җибәрүдә зур көч куйды.

Тормыш бер урында гына тормый. Кече фәнни хезмәткәр буларак иҗат юлын башлаган Әнвәр соңга таба танылган галим Әнвәр Хәйригә әйләнде, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе дигән мактаулы исемгә лаек булды, киң җәмәгатьчелеккә танылды. Әмма ачы язмыш, барыбызны да олы кайгыга салып, аны арабыздан ва-

кытсыз алып китте... Хәзер инде аның үзенең мирасын барларга чират җитте...

Озак еллар, кулга-кул тотышып, бер бүлектә эшләгән Яхъя ага Абдуллин, Әбрар ага Кәримуллин, Рашат Әмирханов, Фәридә Гаффар, Тәфкил Камал, Әнвәр Хәйри кебек миллэтпәрвәр хезмәттәшләрем арабызда юк инде. Аларның җылы карашлары, зыялылыклары, акыллы киңәшләре, дустанә эчкерсез мөнәсәбәтләре бүгенге тонык дөньяда миңа бик тә җитеп бетмиләр! Алар гел истә, алар сагындыра...

**Ф.М. Султанов**

## Научно-исследовательская деятельность Анвара Хайри в период работы в Институте языка, литературы и истории им. Г.Ибрагимова

*Аннотация.* В публикации освещается научно-исследовательская деятельность Анвара Хайри в отделе истории общественной мысли Института языка, литературы и истории им. Г.Ибрагимова в 1974 – 1991 годах.

*Ключевые слова:* история татарской общественной мысли, Анвар Хайри, Институт языка, литературы и истории им.Г.Ибрагимова, татарские рукописи, источники.

**F.M. Sultanov**

## Research activities of Anwar Khairi during his work at G. Ibragimov Institute of language, literature and history

*Annotation.* The publication highlights the research activities of Khairi Anwar in the period from 1974 to 1991 years in the Department of history of social thought at G. Ibragimov Institute of language, literature and history.

*Keywords*: the history of Tatar social thought, Anwar Khairi, G. Ibragimov Institute of language, literature and history, Tatar manuscripts, sources.

**Автор турында мәгълүмат**

**Солтанов Фәрит Мирза улы** – фәлсәфә фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең аспирантура бүлеге мөдире (Казан шәһәре).

**Султанов Фарит Мирзович** – доктор философских наук, заведующий отделом аспирантуры Академии наук Республики Татарстан (г.Казань).

**Sultanov Farit Mirzovich** – doctor of philosophical sciences, Head of Department of postgraduate of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan (Kazan).

УДК 929=512.145"19/20"(470.41)

**Ф.Ш. Хуҗин**

# КҮПКЫРЛЫ ТАЛАНТ ИЯСЕ

*Аннотация.* Мәкаләдә Ә. Хәйринең XVIII–XIX гасыр татар иҗтимагый фикере тарихын өйрәнүгә керткән өлеше югары бәяләнә. Советлар чорында укучыларга бөтенләй диярлек билгеле булмаган Г. Курсави, Ш.Мәрҗани, Р. Фәхретдин, К. Насыйри, З. Камали, М. Бигиев хезмәтләрен хәзерге әдәби телгә күчереп, кирәкле аңлатмалар белән фәнни әйләнешкә кертеп җибәрүе галим эшчәнлегенең иң зур казанышы иде. Х гасырда Болгарга килгән атаклы гарәп сәяхәтчесе Ибн Фадлан язмаларын ул турыдан-туры гарәпчәдән татар теленә тәрҗемә итеп бастырып чыгарды.

*Ачкыч сүзләр:* Ә.Н. Хәйри (Хәйруллин) – татар иҗтимагый фикер тарихы һәм ислам дине белгече, тәрҗемәче, тарихи чыганакларны өйрәнүче, фәнне популярлаштыручы.

Татар тарихын, аерым алганда, иҗтимагый фикер тарихын өйрәнүне – мин биредә проблеманың историографик аспектын күз алдында тотам – күренекле галимебез Әнвәр Нәҗип улы Хәйри хезмәтләреннән башка күз алдына да китереп булмый.

Бер карасаң, кандидатлык диссертациясе яклап, гыйльми дәрәҗәгә дә ия булмады, доцент та, профессор да түгел иде, икенче яктан карасаң, – берничә йөз фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләр, китаплар авторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, Кол Гали исемендәге Халыкара бүләк иясе... Шунысын да ассызыклап әйтергә кирәктер – хезмәтләре, күпчелек галимнәрнекеннән аермалы буларак, киң катлам җәмәгатьчелек тарафыннан күтәп алынып, кызыксынып, авторына ихлас күңелдән рәхмәт хисләре әйтеп укылдылар һәм әле дә укылалар. Сәбәбе нәрсәдә?

Сәбәпләре төрле, минемчә. Беренче чиратта, әлбәттә, Әнвәр Хәйринең кырык биш елга сузылган иҗат тормышы дәверендә бары тик халыкка кирәк булган, ул көткән, моңа кадәр фәндә бөтенләй өйрәнелмәгән, советлар идеологиясе күзлегеннән караганда өйрәнелергә дә тиеш булмаган, үзгәртеп корулар чоры башлангач кына актуальләшеп киткән темалар өстендә генә эшләведер дип уйлыйм.

Икенче сәбәпне мин Әнвәр Хәйринең коеп куйган тарихчы-галим генә булмыйча, үзе өйрәнә торган мәгърифәтче галимнәребез кебек үк, белгәннәрен, кечкенә булса да ачышларын төрле юллар белән – газета-журналларда мәкаләләр бастырып, радио-теле-видение аша чыгышлар ясап, мәктәпләрдә укучылар-укытучылар белән очрашып, студентларга лекцияләр укып, кыскасы, булдыра алганча популяр формада халыкка җиткерә белүендә, һәрдаим шуңа омтылуында күрәм.

Популярлыгының тагын бер сәбәбе, һичшиксез, аның шәхси сыйфатлары иде: матур, төрле сурәтләү чараларына, бигрәк тә юморга бай язма һәм сөйләм теле, кешеләр белән мөгалләмәдә олыны олы, кечене кече итеп ихлас була белү, аудиториянең игътибарын бик тиз яулап алырга сәләтле матур тембрлы көр тавышы, киенүдә элеккеге татар зыялыларына гына хас ыспайлык... Башкалардан өстенлеге исә гарәп телендә яисә гарәп графикасында язылган борынгы кульязмаларны җиңел укый белүендә иде.

Без Әнвәр Хәйри белән Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында 1974 елда эшли башладык. Әнвәрне әле оешып кына килә торган иҗтимагый фикер тарихы бүлегенә гыйльми хезмәткәр итеп кабул иткәннәр иде. Биредә ул 17 елдан артык эшләде һәм үзен чын галим, Ислам динен һәм Шәрыкъ мәдәниятен тирән аңлаучы олы белгеч итеп күрсәтте. Институтта эшли башлагач аңа «Габденнасыйр Курсави һәм Шиһабетдин Мәрҗани әсәрләрендә дини тәгълиматны һәм суфичылыкны рациональ тәнкыйть итүнең төп принциплары» дигән катлаулы темага кандидатлык диссертациясе һәм монография язуны тапшырдылар. Чыганаклар башлыча гарәп телендә генә булуга карамастан, бу авыр һәм четерекле эшне (дини тәгълимәтне тәнкыйть итү?!) ул уңышлы башкарып чыкты [Хайруллин, 1979]. Әмма шул ук вакытта гарәп, фарсы, төрек телләрендә теләсә кайсы чорда язылган һәм басылган теләсә нинди кульязма, ташбасма һәм башка чыганаклар белән иркен эш итә ала торган яшь һәм талантлы галимнең һәр мәсьәләгә башкаларга бәйсез һәм еш кына заман рухына туры килеп бетми торган үз фикере формалашкан иде инде.

Онытмыйк: татар иҗтимагый фикер тарихын өйрәнү безнең Институтта әле үзгәртеп корулар, хөр фикерлелек турында уйларга да ярамаган, марксизм-ленинизм идеологиясе гөрләп чәчәк аткан Бреж-

нев заманнарында башланды. Бүлек җитәкчесе дә, Әнвәр сүзләре белән әйткәндә, «ата коммунист» Яхъя абый Абдуллин иде. Бу шартларда, әлбәттә, халкыбызның атаклы дин әһелләре, бөтен мөселман дөньясында танылган дин галимнәре һәм аларның хезмәтләре турында объектив, дөрес фикер әйтү мөмкин булмаган эш иде. Ә коммунист җитәкчеләребез теләгәнчә, Курсави, Мәрҗани тәгълиматләрен бозып күрсәтү, иҗтимагый тормышыбызга булган карашларын кирәксә дә, кирәкмәсә дә тәнкыйть утына тоту Әнвәр Хәйринең кулыннан килә торган эш түгел иде. Намусы рөхсәт итмәде.

Шөкер, иҗтимагый фикер тарихы бүлегендә Әнвәр Хәйринең күңеленә хуш килгән яңа эш табыла: аңа Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбәр фи әхвәли Казан вә Болгар» исемле ике томлык хезмәтен хәзерге татар әдәби теленә күчереп, басмага әзерләү эше йөкләнә. XIX йөз татар дөньясында милли тарихыбызны фән буларак калыплаштыруда, аякка бастыруда тәүге адым сыйфатында кабул ителгән әлеге мәшһүр хезмәт, бер гасырдан артыграк вакыт үткәч, 1989 елда, Болгар илендә ислам диненең рәсми рәвештә кабул ителүенә 1100 ел (һиҗри буенча) тулган көннәрдә басылып чыга [Мәрҗани, 1989]. Китапның Әнвәр Хәйри тарафыннан язылган (һәм автордаш сыйфатында Я. Абдуллин исеме дә куелган) күләмле «Кереш» өлешендә Ш. Мәрҗани иҗаты бүгенге көн таләпләре яктылыгында, бөтенләй яңача тикшерелә, атаклы дин әһеленең, олуг галимнең татар иҗтимагый фикер тарихында тоткан урыны объектив рәвештә калку итеп күрсәтелә. Минемчә, Әнвәр Хәйринең нәкъ менә шушы хезмәте советлар хакимияте чорында сирәк-мирәк кенә телгә алына һәм әкренләп онытылып бара торган Шиһабетдин Мәрҗани исемен яңадан татар дөньясына кайтаруда хәлиткеч роль уйнады.

Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшләгән елларда Әнвәр Хәйри халкыбызның тагын бер күренекле фикер иясе – мәгърифәтче, тарихчы, журналист, педагог һәм дин галиме Ризаэддин Фәхретдиннең бай иҗаты белән ныклап кызыксына башлый, аның Уфада, СССР Фәннәр академиясенең Башкортостан филиалы Тарих, тел һәм әдәбият архивында сакла624ан 40 томлык кульязмалар тупланмасын битен-биткә диярлек өйрәнеп кайта. Әле тагын Диния Нәзарәте архивында табып алган (ул заманнарда бу архивка сирәк кешеләрне генә кертә торганнар иде әле) 16 томлык кульязма мирасын шул ук Фәннәр академиясе фондына тапшырып, аларны юкка

чыгудан саклап кала. 1970–1980 нче елларда Әнвәр Хәйри XVIII–XIX һәм XX йөз башы татар мәдәниятендә, иҗтимагый фикер тарихында тирән эз калдырган шәхесләр иҗатына һәм дә мәктәп-мәдрәсәләр, мәгариф–мәгърифәт тарихына караган чыганакларны барлау максатында Мәскәү, Ленинград, Ташкент, Бохара, Оренбург архивларында, китапханәләрнең кульязма бүлекләрендә эзләнүләр алып бара. Галимнең үзе тапкан яңа чыганаклар нигезендә язылган мәкаләләре бер-бер артлы газета-журнал битләрендә, фәнни җыентыкларда дөнья күрә. Минем карашка, «Галимнең кульязма мирасы» [Хәйруллин, 1984], «Рукописное наследие Р. Фахретдинова как источник по истории татарской общественной мысли» [Хайруллин, 1985], «Ш. Марджани и Р. Фахретдинов» [Хайруллин, 1990], «Риза Фәхреддиннең «Болгар һәм Казан төрекләре» дигән әсәрендә татар халкының килеп чыгышына бәйле фикерләр» [Хәйри, 1992] исемле мәкаләләре тикшерелә торган проблемаларның яңача куелуы җәһәтеннән кызыклы.

1993 елда Татарстан китап нәшрияты киң катлау укучылар хөкеменә Әнвәр Хәйринең тагын бер хезмәтен тәкъдим итә. Бу – Ризаэддин Фәхретдиннең әлегә кадәр матбугатта басылмыйча кульязма рәвешендә сакланган һәм Әнвәр әфәнденең саллы гына «Кереш сүз»е белән ачылган «Болгар вә Казан төрекләре» дигән тарихи әсәре [Фәхреддинев, 1993]. Әлеге әсәр фәнни комментарийлары белән 1997 елда, башлыча чит илләрдә яшәүче татарлар мәнфәгатен күз алдында тотып, латин шрифтында да дөнья күрде. Шулай итеп, Әнвәр Хәйринең фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә Ризаэддин Фәхретдин исеме дә мәшһүр татар тарихчыларының элгәреләре арасында үзенең лаеклы урынын тапты.

Әнвәр Хәйри сүзләре белән әйтсәк, Р. Фәхретдинов дингә «Әдәп, Әхлак, Шәфкать, Мөрәүвәт, Изгелек, Итагатьлелек, Кешелеклелек, Намус, Сафлык, Пакьлек, Гаделлек, Яхшылык һәм башка бик күп күркәм төшенчәләрне-сыйфатларны эченә алган һәм барлык бозык эшләрдән тыелып, яхшы эшләр генә эшләргә өндәгән кануннар тупланмасы итеп карый». Атаклы галимнең нәкъ менә шул принциплардан чыгып язылган, тәрбия, әдәп-әхлак мәсьәләләренә һәм дә мөселман дөньясында, татар тормышында хатын-кызларның роле проблемасына багышланган күп санлы китаплары, табигый ки, Ә. Хәйринең игътибарыннан читтә калмады, бәлки, аның тырышлыгы

белән яңадан халыкка кайтарылды. Р. Фәхретдиннең бүген дә актуальлелеген җуймаган «Балаларга нәсыйхәт», «Гакыйдә. Ислам дине. Әдәп вә әхлак дәресләре», «Гаилә. Тәрбияле ана. Тәрбияле хатын», «Адәбе тәгълим (Укыту кагыйдәләре)» һәм башка исемдәге китаплары 2000 нче еллар башында бер-бер артлы, икешәр-өчәр мәртәбә нәшер ителделәр һәм, күз ачып йомганчы дигәндәй, китап киштәләреннән юкка чыга бардылар. Россия ислам институты шәкертләре, мәдрәсә мөгаллимнәре, урта мәктәп укытучылары һәм ата-аналар бу китаплардан бүген дә бик теләп файдаланалар.

Галимнең фәнни-тикшеренү диапозоны гаять киң иде. Бу сүзләрне раслап, аның тарафтан тәрҗемә ителгән Габденнасыйр Курсавиның аерым фәлсәфи язмаларын, К. Насыйриның «Фәвакиһел-җолласа фил-әдәбият» исемле энциклопедик хезмәтен, Зыя Камалинең «Фәлсәфәи игътикадия» (Инану фәлсәфәсе), Муса Бигиевның, әл-Кардавиның, Габделвахид Сөләйманның һәм башка галимнәрнең дини вә фәлсәфи китапларын күрсәтеп үтәргә кирәктер.

Әнвәр Хәйрине мин күренекле дин белгече дип тә атар идем. 1980 еллар урталарында башланган үзгәртеп корулар заманында ул Ислам динен тирәнтен өйрәнеп, аны халык арасында курыкмыйча пропагандалаучы беренче татар галиме булды. Коръәннең иң күп укыла торган 57 сүрәсен үзенчә тәрҗемә итеп, аларны вакытлы матбугатта бастырып, радио аша халыкка җиткерү чараларын күрде. 1996 елда басылып чыккан һәм хәзерге фән күзлегеннән язылган «Ислам дине бәйрәмнәре» дигән китабы исә берничә көн эчендә халык арасында таралып бетте [Хәйри, 1996].

Әнвәр Хәйри үзе эшләгән Тел, әдәбият һәм тарих институтында иҗтимагый фикер тарихы бүлеге нигезендә Исламны өйрәнү бүлеген ачарга тырышып йөрүчеләрнең берсе иде. Яңа бүлекнең эш юнәлешләрен билгеләп, үзе булдыра алганча фәнни концепциясен дә язып, бүлекне ачуда ярдәм сорап Мәскәүгә академик Камил Вәлиев янына да барып кайтты ул, Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты галимнәре белән киңәште, фәнни конференцияләрдә, вакытлы матбугатта әлеге фикерне кат-кат күтәреп чыкты. Нәтиҗәдә бу бүлек ачылды, дөресрәге аның исеме «Иҗтимагый фикер тарихы һәм исламны өйрәнү бүлеге» итеп үзгәртелде. Ул Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани

исемендәге Тарих институтында бүгенге көндә дә уңышлы гына эшләп килә.

Соңгы бер-ике дистә ел эчендә Әнвәр Хәйри атаклы сәяхәтче, 922 елда Болгар иленә килгән Багдад илчелеге сәркатибе Әхмәт ибн Фадланның «Рисалә»сен гарәп теленнән турыдан-туры татарчага тәрҗемә итү һәм шул хезмәткә фәнни комментарийлар язу белән мәшгуль булды. Аның бу язмага мөрәҗәгать итүе элегрәк рус галимнәре тарафыннан тәрҗемә ителгән тексттагы төгәлсезлекләр белән бәйле иде. Искиткеч тырышлык, тарих һәм филология өлкәсендә тирән белем таләп иткән күп еллык хезмәтнең нәтиҗәсе куанычлы булды: 2013 елда татар һәм рус телләрендә дөнья күргән, фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан уңай бәяләнгән фундаменталь хезмәт (гомуми күләме 1043 бит, карагыз: [Хайри, 2013; Хәйри, 2013]) беренче президентыбыз М. Шәймиев тәкъдиме белән болгарларның ислам динен кабул итүгә багышланган «Истәлек билгесе» музей-күргәзмә комплексы экспозициясенә алынды.

## ӘДӘБИЯТ

1. Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар. (Казан һәм богар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр) / Китапны тәрҗемә итүче һәм төзүче Ә.Н. Хәйруллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 415 б.

2. Фәхреддинев Ризаэддин. Болгар вә Казан төрекләре / Китапны тәрҗемә итүче һәм төзүче Ә.Н. Хәйруллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 287 б.

3. Хайри А. Повествование о путешествии Ахмеда Ибн Фадлана, написанное во время поездки в 921–922 годах в Булгарское государство (новое в переводе на русский язык и научных комментариях) / Науч. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань: Изд-во «Слово», 2013. 512 с., илл.

4. Хайруллин А.Н. Место Г. Курсави в истории общественной мысли // Из истории татарской общественной мысли. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 1979. С. 72–78.

5. Хайруллин А.Н. Рукописное наследие Р. Фахретдинова как источник по истории татарской общественной мысли // Проблемы преемственности в татарской общественной мысли. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 1985. С. 73–84.

6. Хайруллин А.Н. Ш. Марджани и Р. Фахретдинов // Марджани: ученый, мыслитель, просветитель. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 1990. С. 57–62.

7. Хәйри Ә. Галимнең кулъязма мирасы // Казан утлары. 1984. № 1. 157–162 бб.

8. Хәйри Ә. Риза Фәхреддиннең «Болгар һәм Казан төрекләре» дигән әсәрендә татар халкының килеп чыгышына бәйле фикерләр // Мирас. 1992. № 3. 74–77 б.

9. Хәйри Ә. Ислам дине бәйрәмнәре. Казан: «Заман» нәшр., 1996. 72 б.

10. Хәйри Ә.Н. Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...» китабы // Шигабутдин Марджани: наследие и современность. Ш. Мәрҗани: мирасы һәм хәзерге заман. Материалы Международ. науч. конф. Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2008. 178–199 б.

11. Хәйри Ә. Әхмәд Ибне Фадланның 921–922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе (татар теленә яңача тәрҗемә һәм фәнни аңлатмалар) / Фәнни мөхәррир Ф. Хуҗин. Казан: «Сүз» нәшр., 2013. 536 б.

**Ф.Ш. Хузин**

## Многосторонний талант

*Аннотация.* В статье высоко оценивается вклад А. Хайри в изучение истории татарской общественной мысли XVIII–XIX вв. Перевод на современный литературный татарский язык богословско-философских и исторических трудов Г. Курсави, Ш. Марджани, К. Насыри, Р. Фахреддина, З. Камали, М. Бигиева, ввод их с соответствующими комментариями в научный оборот – одно из самых значительных достижений в многогранной деятельности ученого. Он осуществил новый перевод, прямо с арабского на татарский, «Записок» («Рисале») знаменитого арабского путешественника Ибн Фадлана, побывавшего в составе Багдадского посольства в Булгарском государстве.

*Ключевые слова:* А.Н. Хайри (Хайруллин) как историк татарской общественной мысли и исламовед, переводчик, источниковед, популяризатор науки.

**F.Sh. Khuzin**

## Multilateral talent

*Annotation.* In article A. Hayri’s contribution to studying of history of the Tatar social thought of the XVIII–XIX centuries is highly appreciated. The translation into modern literary Tatar language of theological and philosophical and historical works of G. Kursavi, Sh. Marjani, K. Nasyri, R. Fakhreddin, Z. Kamali, M. Bigiev, their introduction with the corresponding comments in a scientific sphere – one of the most considerable achievements in multilateral

activity of the scientist. He made a new translate, directly from Arab on Tatar, «Notes» («Risale») of the well-known Arab traveler Ibn Fadlan, visited consisting of the Baghdad embassy in Bolgare.

*Keywords:* A.N. Hayri (Khayrullin) as historian of the Tatar social thought and the person studying islam, translator, the person studying sources, popular writer of science.

**Автор турында мәгълүмат**

**Хуҗин Фаяз Шәрип улы** – тарих фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, Татарстан Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков ис. Археология институты директоры урынбасары (Казан шәһәре); e-mail: khuzinfayaz@mail.ru

**Хузин Фаяз Шарипович** – доктор исторических наук, член-корреспондент АН РТ, зам. директора Института археологии им. А.Х. Халикова АН РТ (г.Казань).

**Khuzin Fayaz Sharipovich** – doctor of historical sciences, Corresponding Member of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Deputy director of A.Kh. Khalikov Institute of archeology of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan (Kazan).

УДК 929:930

**З.Р. Шәйхелисламов**

# ГЫЙЛЕМ МӘГАРӘСЕНЕҢ ӘНВӘРЕ[1] – МИЛЛӘТ ХАДИМЕ ХӘЙРИ

*Аннотация.* Мәкаләдә тарихчы, кульязмалар белгече Ә.Хәйринең кыскача тормыш юлы, борынгы басма һәм кульязма чыганаклар буенча фәнни хезмәтләре, үткәндәге мирасны халыкка җиткерүдәге роле яктыртыла.

*Ачкыч сүзләр:* милли хәтер, мәгърифәт, халыкка хезмәт.

Мәгълүм булганча, укымышлылары, галимнәре булмаган халык милләт булып сакланып кала алмый, аның дәүләте дә булмый. Татар халкы күп гасырлар дәвамында нинди генә авыр сынаулар узса да, юкка чыкмады, чөнки аның милли хәтерне яңартып торучы, дөрес юл күрсәтүче, гыйлемне киләчәк буыннарга тапшырырдай галимнәре булды. Сүзем шундый галимнәребезнең берсе мәрхүм Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (1999), Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре (1991, 2008), Кол Гали исемендәге Халыкара премия лауреаты (1994), Халыкара мәгълүматлаштыру академиясе академигы, Санкт-Петербургтагы Петр I исемендәге Фәннәр һәм Сәнгатьләр академиясе мөхбир-әгъзасы, тәрҗемәче, публицист, язучы, галим Әнвәр Нәҗип улы Хәйри турында.

Ул сугыштан соң илнең җимереклек, мохтаҗлык кичергән чорында туган буын вәкиле. Ил кичергәнне ул да кичерә, тормышның авыр йөге аның җилкәләренә дә төшә. Татарстанның Аксубай районы борынгы Шәрбән (Шәһри Бану) авылында сигезенче бала булып дөньяга килгән Әнвәргә колхозда ат көтүе көтәргә, урман кисәргә, тракторчы һәм комбайнчы ярдәмчесе булырга, Казан мехкомбинатында тире сыгарга, төнге каравылда торырга һәм башка бик күп төрле эшләрне башкарырга туры килә. Әнвәр Хәйри «тормыш университетлар»ын шул тәртиптә уза. Ләкин шунысын әйтергә кирәк, фән дөньясына юнәлеш бирүче алшартлар аның гаиләсендә үк була. Әти-әнисе гади колхозчылар гына булсалар да, өйдә күптөрле китап тоталар, гарәп, латин, кириллицада язылган

[1] Әнвәре – якты нуры.

әсәрләрне укыйлар, шәрехләп бирәләр. Әнвәрне бигрәк тә серле гарәп язуы, гарәп теле кызыксындыра. Мәктәптә уку елларында мәгълүм сәбәпләр аркасында моның өчен күп җәфалар күрсә дә, гарәп теленә мәхәббәте аны 1967 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга китерә. Кем белә, Колбай-Мораса урта мәктәбен тәмамлаган егет шул авылдан чыккан «татар театрының атасы» талантлы артист, драматург, режиссер Габдулла Кариев (чын исеме Миңлебай Хәйруллин) эзеннән китсә, бәлки атаклы артист та булган булыр иде. Яшьлегендә, мөгаен, хыяллангандыр да, юкка гына 1966 елда Казан театр училищесының актерлар бүлегендә укырга кермәгән бит! Кариев кебек оста көрәшче дә булган булыр иде. Ходай Тәгалә аңа буйсынны, алыптай таза гәүдәне дә җәлләмәгән. Дин юлыннан китсә дә Кариев кебек «карый» (Коръәнне яттан укый алучы) булыр иде. Ник дисәң, Миңлебай Хәйруллин Җаекта (Уральскида) мәдрәсәдә укыганда ук Коръәнне яттан белгән. Шуның өчен аны «Габдулла карый» дип йөрткәннәр. Соңыннан шушы псевдоним аның фамилиясе булып китә.

Әгәр теләсә, Әнвәр җырчы булып та китә алыр иде. Табигать тарафыннан аңа моң, мәкам, ачык дикция мулдан бирелгән. Артистлык сәләте аның йөрәгенә салынган. Хәер, үкенергә урын юк, бу сәләт аның кызына – мәшһүр яшь җырчы Айгөл Хәйригә күчкән. Айгөл татар халык җырларын милли үзенчәлекләрен саклап, мелизмнар белән баетып башкаруы белән тиз арада тамашачыларның мәхәббәтен яулады. Әмма, нәрсә генә фаразласак та, Әнвәр әфәнде язмышын үзе хәл итә, балачак хыялына хыянәт итмичә, бердәнбер дөрес юлны сайлый. Университетта уку елларында гарәп теле укытучысы Лена ханым Таҗиева, фарсы теле белгече Мостафа Ногман аны борынгы кулъязма чыганаклар белән эш итәргә, аларның эчке, яшерен серләренә төшенергә өйрәтәләр. Әнвәр Хәйри беренче курста ук студентларның фәнни түгәрәгенә йөри, фәнни конкурсларда катнаша, аның беренче фәнни язмалары басыла башлый. 1974 елда аны Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының иҗтимагый фикер тарихы бүлегенә эшкә алалар. Менә шушында аның университетта алган белеме бик тә кирәк булып чыга. Ул Габденнасыйр Курсавиның һәм Шиһабетдин Мәрҗанинең кулъязма әсәрләрен өйрәнә, алардагы рационалистик фәлсәфәне ачыклау омтылышы ясый. Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле ике томлык тарихи хезмәтен хәзерге әдәби телгә

тәрҗемә итә. Катлаулы гыйльми телдә язылган бу хезмәтнең текстын эшләү белем һәм эрудиция таләп итә. Ни аяныч, әзер хезмәт чын тарихыбызны яктырткан фикерләрдән арындырылып, нык кына кыскартылып, 1989 елда бер том күләмендә басылып чыга. Шуңа карамастан, ул бүген дә дөнья фәне тарихында лаеклы урын тота. Болардан тыш, Әнвәр әфәнде мәгърифәтче К.Насыйри, Р.Фәхретдин, Зыя Камали, М.Бигиев, Г.Ибраһимов әсәрләрен өйрәнеп, аңлатма һәм искәрмәләр язып, хәзерге укучы аңларлык әдәби телгә күчереп бастырды. Бигрәк тә ул беренчеләрдән булып энциклопедик галим Ризаэтдин Фәхретдиннең иҗат мирасын өйрәнүгә күп көч салды. Аның Уфада саклanучы 40 томлык кулъязмаларын өйрәнеп чыкты, байтак әсәрләрен кулдан күчереп Казанга алып кайтты. Шулар нигезендә Р.Фәхретдиннең 57 хезмәтен басмага хәзерләп, 24 китаптан торганын бастырып та чыгарды. Болардан тыш, Р.Фәхретдиннең «Ислам» белешмә-сүзлек китабында, «Татар календаре»нда 29, төрле журналларда 61, газеталарда 66 хезмәтен бастырды. Соңгы елларда Татарстан радиосыннан Р.Фәхретдиннең әхлак тәрбиясе буенча язылган 8 китабы хакында 450 тапшыру эшләп халыкка радиодәресләр аша җиткерде. Аның иҗатын яктырткан 25 ләп фәнни мәкалә язып дөньяга чыгарды. Югарыда телгә алынганнар өстенә Р.Фәхретдиннең фәнни, дини, тарихи, этнографик, фәлсәфи, педагогик, психологик, язучылык, халыкара эшчәнлекләре турында, аңа багышлап 50 радиотапшыру эшләде. Җыеп әйткәндә, Әнвәр Хәйри «Татарстан» һәм «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясендәге чыгышлары белән фәнне халыкка якынайтты, ягъни, популярлаштыруга зур өлеш кертте. Ислам диненә мөнәсәбәт уңай якка үзгәрә башлагач, халыкның дини әдәбиятка булган зур ихтыяҗын канәгатьләндерүдә дә Әнвәрнең хезмәтләре бик вакытлы булды. Мәсәлән, ул 1990–91 елларда «Казан утлары» журналында Коръәннең 57 сүрәсен татарчага тәрҗемә итеп бастырды. 1996 елда «Ислам дине бәйрәмнәре» исемле китабы басылып чыкты. Болардан башка да узган гасыр башында иҗат иткән татар галимнәренең бүген дә актуаль хезмәтләрен сайлап алып, халыкка аңлаешлы әдәби телгә күчереп дөньяга чыгарды. Әнвәр әфәнде менә шулай озак еллар дәвамында үзенең газиз халкына, милләтенә хезмәт итте. Аның мөгаллим, оста педагог икәнен дә әйтергә кирәк. Университетны тәмамлаганнан соң ул Казан шәһәрендәге 80 нче урта мәктәптә, Казан дәүләт педагогия институтында, КДУда, Авыл хуҗалыгы институтында, Медицина институтында, укытучылар

йортында, фәнни китапханәдә, гуманитар көллияттә халык медицинасы, гарәп теле һәм язуы укыта. Соңгы елларда Әнвәр Хәйри Татарстан Милли китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә әйдәп баручы фәнни хезмәткәр булып эшләде. 60 яшьлек юбилее алдыннан гарәп сәяхәтчесе Ибне Фадланның Болгарга сәяхәте турындагы язмаларны гарәпчәдән турыдан-туры татарчага тәрҗемә итеп китапны басмага хәзерләп бетергән иде. Һәм ул «Әхмәд Ибне Фадланның 921–922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе» исеме белән Казанда 2013 елда 536 бит күләмендә басылып чыкты.

83 китапны дөньяга чыгарган һәм 800 ләп мәкалә язган галимнең барлык эшчәнлеген бер чыгышта яктырту һич мөмкин түгел. Ә шулай да Әнвәрнең эти-әнисе, бабалары зыялы булган. Юри генә исем-фамилиясенә игътибар итегез әле: Әнвәр – гарәпчә бик нурлы, якты, Нәҗип улы (Нәҗип – тәрбияле нәселдән булган кеше дигән сүз). Хәйри, Хәйрулла – Алланың игелекле кешесе мәгънәсендә. Исеме җисеменә туры килә, кылган гамәлләре милләт хадиме икәнлеген раслап торалар.

## ӘДӘБИЯТ

1. Хәйри Ә.Н. Әхмәд ибне Фадланның 921–922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе (татар теленә яңача тәрҗемә һәм фәнни аңлатмалар). Казан, 2013. 536 б.

2. Хәйруллин Ә.Н. Кереш сүз // Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Казан, 1989. 5–37 б.

**З.Р. Шайхисламов**

## Луч пещеры знаний – слуга нации Хайри

*Аннотация.* В статье освещается жизненный и творческий путь историка, текстолога, переводчика А.Хайри, дается обзор его научных трудов по истории духовной культуры татар, ислама в Поволжье. Также рассказывается об А.Хайри как о блистательном педагоге, его активной пропагандистской деятельности на страницах СМИ, радио, телевидении.

*Ключевые слова:* национальная память, просвещение, служение народу.

**Z.R. Shaikhislamov**

**Ray cave of the knowledge –a servant of the nation Hairy**

*Annotation.* The article highlights the life and career of the historian, textual, translator A.Hayri. In this article author give some review to his scientific works on the history of the spiritual culture of the Tatars and the position of Islam in the Volga region. Also it describes about A.Hayri as a brilliant teacher, about his active advocacy in the media, radio and television.

*Keywords:* national memory, education, service to the people.

**Автор турында мәгълүмат**

**Шәйхелисламов Заһир Рәхмәтулла улы** – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, ЯһММҮнең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре (Казан шәһәре).

**Шайхисламов Загир Рахматуллович** – кандидат филологических наук, ведущий научный сотрудник ЦПиМН ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова АН РТ (г.Казань).

**Shaikhislamov Zagir Rakhmatullovich** – candidate of philological sciences, leading researcher of the Centre of Written and Musical Heritage of G. Ibragimov Insitute of Language, Literature and Art of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan (Казаn).

УДК 37=512.145"20"(470.41)

**С.Т. Ямалтдинова**

# Р.ФӘХРЕТДИН МИРАСЫН – МӘКТӘП УКУЧЫЛАРЫНА

*Аннотация.* Истәлек-язмада сүз соңгы 10 елда галим Әнвәр Хәйринең Керкәле авылы урта мәктәбе укучыларына һәм укытучыларына Р.Фәхретдин мирасын пропагандалавы хакында бара.

*Ачкыч сүзләр:* Әнвәр Хәйри, Р.Фәхретдин, Керкәле авылы урта мәктәбе, әхлак тәрбиясе.

*«Галимнәрнең максатлары югары,*
*хезмәтләре авыр һәм изге...*
*Шуның өчен болар һәр вакытта*
*хөрмәтле һәм күркәм затлар исәпләнә».*

Р.Фәхретдин.

Кичүчатта бөек галим, якташыбыз Ризаэтдин Фәхретдиннең тууына 155 ел тулуга багышланган «Туганнарның кадерен белик...» дип исемләнгән чарага Рәсәйнең төрле почмакларында яшәүче якын туганнары, галимнең мирасын халыкка җиткерүче галимнәр, язучылар, җитәкчеләр, укытучылар килгән иде. Анда Рөстәм абый Фәхретдинов: «Күренекле галим Әнвәр Хәйри иң беренчеләрдән булып Р.Фәхретдин хезмәтләрен бүгенге укучыга аңлаешлы телдә бастырып чыгарды. Гарәп графикасында, иске татар телендә язылган бу хезмәтләрне тәрҗемә итүгә Әнвәр абый бик күп көчен салды. Кызганычка каршы, ул арабыздан иртә китеп барды. Бик зур рәхмәт Әнвәр абыйга. Аның бастырган китапларын яңадан да чыгарасы иде», – дигән теләкләрен җиткерде.

Рөстәм абыйның фикерен куәтләп, Атлас Муратаев (Нурҗамал абыстайның якын туганы): «Әнвәр абый Риза бабайның эшләрен кайтаруда бик зур эш эшләде. Урыны җәннәттә булсын!», – дип, алга таба да Р.Фәхретдин китапларының, бигрәк тә «Тәрбияле бала», «Тәрбияле ана», «Гаилә» һ.б. әдәп-әхлак темасына караган хезмәтләренең тагын бастырылуын теләде.

Очрашуда чыгыш ясаучыларның фикерен куәтләп, галим мирасын өйрәнүдә безгә зур ярдәм күрсәткән Әнвәр абый Хәйри белән хезмәттәшлегебез хакында язарга булдым.

Р.Фәхретдин хезмәтләре китап булып басылып чыкканчы ук, Татарстан дәүләт радиосының «Балкыш» тапшыруында Әнвәр абый аларны халыкка җиткерде. Гадилә Нургали алып барган бу радиотапшыруларның аудио һәм кульъязмаларын ветеран укытучы Галия апа Рәхимова район-шәһәр мәктәпләренә таратты. Бу язмаларны укучылар мәктәптә тыңлап, хәтердә калганнарын иҗади эш дәфтәрләренә язып барды. 1993 елдан башлап тыңлап-язып кына барсак, 2001 елдан мәктәбебездә үз «Балкыш»ыбызны башлап җибәрдек. «Балкыш» әдәби-әхлакый тапшырулары белән без район-шәһәр мәктәпләрендә, Әлмәт районы Тайсуган урта мәктәбендә дә булдык. 2004 елга кадәр мәктәбебезнең 40 укучысы дәүләт радиосының «Балкыш» тапшыруында әдәп-әхлак темасына турыдан-туры эфирда чыгыш ясады. Казандагы «Балкыш» радиотапшыруының 10 еллык юбилеенда катнашып, эшчәнлегебез хакында сөйләдек. Галия апа Рәхимова һәрвакыт безнең ярдәмчебез булды.

2008 елда безнең мәктәптә Р.Фәхретдин мирасын өйрәнүгә багышланган «Мәңге җуелмас мирас» дигән район күләмендәге беренче укучылар фәнни-гамәли конференциясе узды. Бер укучыбыз галим Әнвәр Хәйри, икенчесе – якташыбыз академик Индус Таһиров, тагын берсе журналист Гадилә Нургали булып чыгыш ясады. Шунда берсе: «Апа, бу галимнәрнең үзләрен күрәсе иде!» – дип куйды. Телефоннан бер сөйләшүдә Әнвәр абыйга бу хакта әйттем. Ул һич авырсынмыйча очрашуга килергә ризалык бирде. 2009 елның 16 феврале – укучылар, ата-аналар, тирә-күрше мәктәп укучылары, укытучылары өчен дә зур бәйрәм булды. Беренче мәртәбә гап-гади авыл мәктәбенә хезмәтләре белән халыкка танылган, чын галим килсен әле! Үзенең чыгышын Әнвәр абый дога укып башлады. Үзе булып чыгыш ясаган укучыга шатланып, «коллега» дип дәшеп, аралашып алды. Әнвәр абый Р.Фәхретдин хезмәтләрен архивлардан ничек эзләп тапканын, аларның нинди аяныч хәлдә булуын һәм мәгърифәтченең үзе, гаиләсе, эшчәнлеге хакында бик күп мәгълүмат бирде. Һәр укучыда Р.Фәхретдиннең «Тәрбияле бала», «Шәкертлек әдәпләре» һ.б. хезмәтләреннән алынган тезислар дәфтәрен күргәч, гаҗәпләнеп калды. «Балаларга нәсыйхәт» китабының һәр укучыда булуын белгәч, аларга үзенең изге теләкләрен язып, култамгасын куйды. Мәктәбебез «Балкыш»ын карагач, үзенең изге теләкләрен язып калдырды: «Керкәле мәктәбенең «Балкыш» студиясе эшчәнлегенә

мин сокланып утырдым. Сөбханалла! Бөек галим, мәгърифәтченең нәкъ менә шундый талантлы балалар үстерә торган уңдырышлы туфрактан үсеп чыгуының сәбәбен мин бүген аңладым. Бу кадәр матур табигатьле, чиста күңелле, ихлас һәм булдыклы укучылар тәрбияләүче мәктәп һәм аның данлы укытучылар коллективы булган авыл һәм тирә-ягы, чыннан да, илһам чыганагы икәнлегенә инандым. Бу яктан Ризаэтдин Фәхретдиннең дәвамчылары киләчәктә күпләп чыгуын теләп: Әнвәр Хәйри. 16.02.2009 ел». Шул көннән башлап Әнвәр абый безнең мәктәптән аерылмады. Ул мәктәпкә килгән саен, укучыларга тормыш дәресләре бирде. Ихлас күңелдән йөргән галимне укучылар да үз күрде, аңлады, якын итте, рәхәтләнеп аралашты.

Әнвәр абый: «Галия апа – бу төбәкнең тере легендасы, әле дә халыкны агарту, аның рухын чистарту һәм күңелен даими баету, халкыбызның күп гасырлар дәвамында яшәү рәвеше булган югары әхлак кануннарын һәм Иманыбызны яңадан торгызу өстендә армый-талмый эшләүче чын Халык укытучысы, чын мәгърифәтче ул», – дип безнең остазыбызның эшенә югары бәя бирде.

Мәктәбебездә республика күләмендә «Җәмит Рәхимов уку-лары»н үткәрергә тәкъдим итүче һәм башлап җибәрүче дә Әнвәр абый булды. Ул: «Мондый конференцияләр укучыларның фәнгә, туган якларына кызыксынуларын арттырыр, милләт горурлыгы булырдай шәхесләр тәрбияләр. Киләчәктә укулар дәвамлы булсын, Россия күләмендә үткәрелсен иде. Төбәгегездән чыккан күренекле шәхесләрнең, галим, язучы һәм башка һөнәр ияләренең барысының да эшчәнлеген яктырткан фәнни-эзләнү эшләре күбрәк булсын иде», – дигән иде.

Әнвәр абый безнең эшләгән эшләребезне күреп, бәяләп, дөрес юлда икәнебезне аңлатты. Алай гына да түгел, һәр укучы башкарган эшкә сокланып, аңа чын күңелдән шатланып, акыллы киңәшләре белән яңадан-яңа уңышларга дәртләндереп торды.

«Бары тик эш дәвамлы булганда гына нәтиҗәсе була», – дигән Р.Фәхретдин.Үзем Р.Фәхретдингә әнисе ягыннан 6 нчы буын туган тиешле, бүгенге көндә танылган мәгърифәтче киңәше белән Ситдыйк мулла тарафыннан ачылган кызлар мәдрәсәсе нигезендә утырган Керкәле мәктәбендә 37 ел татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшлим. Мәктәбебездә Р.Фәхретдинварисларын тәрбияли алуыма шатланам. Чөнки укучыларым Р.Фәхретдин мирасын өйрәнүгә багышланган һәм башка төрле республика,

Россиякүләм чараларда, бәйге-конференцияләрдә актив катнашып, җиңүләр яулый. Мәсәлән, Р.Фәхретдиннең тууына 150 ел тулуга багышланган республикакүләм бәйгедә 8 нче сыйныф укучысы Н.Нигъмәтуллина җиңүче, 2014 елда «Р.Фәхретдиннең иҗади мирасын өйрәнү буенча иң яхшы фәнни эш» Бөтенроссия бәйгесендә Л.Нигъмәтуллина лауреат булды. Олуг мәгърифәтче Р.Фәхретдин мирасын пропагандалауда, мәктәпнең «Балкыш» әдәби – әхлакый тапшыруларын оештыруда актив катнашканы өчен 15 укучыбызга «Мәгариф» журналы «Рәхмәт хаты» тапшырды.

Күренекле галимнәрнең берсе булган Әнвәр абый белән аралашу һәм 10 ел дәвамында аннан бик файдалы, кирәкле мәгълүматлар ишетү бәхете һәркемгә дә эләкмидер. Галим белән очрашулардан соң һәр укучының үз фикерләрен иҗади эш дәфтәренә теркәп баруы, атна саен үткәрелүче «Балкыш» тапшырулары, ата-аналар арасында Р.Фәхретдин хезмәтләрен өйрәнү буенча уза торган фәнни-гамәли конференцияләр – Әнвәр абый белән бергә эшләвебезнең матур нәтиҗәсе. Үзенең көчен һәм вакытын кызганмыйча, Казан кадәр ерак араларны якын итеп, ни өчен безне үз күргән соң Әнвәр абый? Чөнки ул һәркемгә игътибарлы, ихтирамлы, ярдәмчел, олы җанлы һәм изге күңелле Кеше, чын зыялы галим иде. Остазыбызның рухы шат булсын!

Туганнар очрашуында эшләребез турында берничә сүз әйткәч, Римма Ратникованың әнисе Лена апа (авылдашым, мин – Түбән Чыршылы кызы): «Әнвәр Хәйри – ул минем беренче укытучым. Казанда гарәп графикасына өйрәнергә курслар ачылгач, мин аңардан сабак алдым», – диде.

Бер килүендә Әнвәр абый: «Без – галимнәр, бу китапларны чыгарабыз да, әмма Р.Фәхретдин хезмәтләрен, киңәшләрен тормышта кулланучы-үтәүчеләр күп булсын иде. Карагыз сез аның «Әхлак гыйлеме» сериясендә язылган хезмәтләрен! Һәрберсе дә яшәү дәреслеге бит алар, шул хезмәтләр нигезендә гамәл кылучылар күбәйсен иде!» – диде.

Ышанам: галимнәрнең хезмәтләре, халыкка җиткерергә теләгән уй-фикерләре, киләчәк турындагы якты хыяллары һичшиксез яшь буынны алгы көннәргә озата барыр, милләтебезне саклап калырдай мәшһүр адәмнәре белән баетыр.

**С.Т. Ямалтдинова**

## Наследие Р.Фәхретдина – учащимся школ

*Аннотация.* В воспоминании речь идет о деятельности Анвара Хайри по пропаганде наследия Р.Фахретдина среди учащихся Керкалинской средней общеобразовательной школы.

*Ключевые слова:* Анвар Хайри, Р.Фахретдин, Керкалинская средняя общеобразовательная школа, нравственное воспитание.

**S.T. Yamaltdinova**

## The legacy of R. Fakhretdin to school students

*Annotation.* In memory it is talking about the activities of Anwar Khairi on spreading the legacy of R. Fakhretdin among students of the Kerkalinskaya secondary school.

*Keywords:* Anwar Khairi, R. Fakhretdin, Kerkalinskaya secondary school, moral education.

**Автор турында мәгълүмат**

**Ямалтдинова Сөгъдә Таһир кызы –** Татарстан Республикасының Лениногорск районы Керкәле төп белем бирү мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Ямалтдинова Сагда Тагировна –** учитель татарского языка и литературы Каркалинской основной общеобразовательной школы Лениногорского района Республики Татарстан.

**Yamaltdinova Sagda Tagirovna** – the teacher of the Tatar language and literature of the Kerkalinskaya secondary school of the Leninogorsk district of the Republic of Tatarstan.

# Мәкаләләр

УДК 013=512.145"18"

**М.И. Әхмәтҗанов**

## ӘНВӘР ХӘЙРИНЕҢ ТАТАР ЯЗМА МИРАСЫНА КАГЫЛЫШЛЫ ХЕЗМӘТЛӘРЕ

*Аннотация.* Мәкаләдә сүз Әнвәр Хәйринең XIX гасыр татар медицина белгечләре тарафыннан язылган хезмәтләрне халыкка җиткерү юлындагы эшчәнлеге, аларны кириллицага күчереп «Мирас» журналында бастырып чыгару турында бара.

*Ачкыч сүзләр:* татар язма мирасы, халык медицинасы, Әнвәр Хәйри.

Әнвәр Хәйринең татар мирасына кагылышлы хезмәтләреннән беренчесе итеп, аның тарихчы галим Шиһабетдин Мәрҗани әсәрләрен халыкка җиткерүдәге өлешен искә алырга кирәк.

Узган гасырның 80 нче еллар ахырына таба Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының иҗтимагый фикер тарихы бүлегендә профессор Я.Г.Абдуллин җитәкчелегендә Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле ике томлык тарихи хезмәтен – аның телен һәм графикасын бүгенге татар укучысына җиткерүдә хәрәкәт башланды. Бу өлкәдә әле безнең фәнни хезмәткәрләребезнең эш тәҗрибәсе булмаса да, әлеге хәзерлек тырышлык белән алып барылды. Ш.Мәрҗанинең бу ике томлыгын тәрҗемә итеп матбугатка хәзерләү бурычы Әнвәр Хәйригә йөкләнде. Ул бу эшне Я.Г.Абдуллин җитәкчелегендә башкарып чыкты һәм китап 1989 елда 50 меңлек данә күләмендә халыкка таралып китте [Мәрҗани Шиһабетдин]. Китапны хәзерләүдә, әлбәттә, кайбер кимчелекләр дә бар иде. Ләкин алар китапка булган ихтыяҗга зыян салырлык

дәрәҗәдә түгел иде. Ниһаять, татар халкы үзенең кадерле мирасы белән кабаттан таныша алды.

Әнвәр Хәйринең мирас мәсьәләсендә икенче әһәмиятле хезмәте, аның Казанда 1991 елдан чыга башлаган «Мирас» журналының беренче саныннан башлап, татар медицинасының язма үрнәкләрен халыкка җиткерү юлындагы эшчәнлеге булды. Ул шул елда басылып чыккан беренче санда XVIII–XIX гасыр чикләрендә яшәгән Габделвахид мөфти бине Сөләйманның 1816 елның 2 февралендә язып төгәлләгән «Төрле авырулардан дәвалау чаралары» исемле кулъязма хезмәтен хәзерге татар әдәби теленә әйләндереп «Мирас»ның 1991 елда басылып чыккан сәхифәләрендә татар милләтенә җиткерде [Габделвахид мөфти ибне Сөләйман]. Габделвахид мөфти бине Сөләйман (1786–1862, 4 август) язган кулъязманы Әнвәр Хәйри Уфа шәһәрендәге Н.Крупская исемендәге Республика фәнни китапханәсенең кулъязмалар бүлегендә табып күчереп алган була.

Әлеге дәва кулланмасы чыганакларын мөфти хәзрәтләргә иске язмалар аркылы белеп, үзе тәртипкә китереп иҗат иткән булган. Бу әсәр татар медицинасы тарихында беренче дөнья күргән әсәр, милли әсәр дип саналырга мөмкин.

Моннан соң Әнвәр Хәйри, әлеге юнәлештәге эшен дәвам итеп, «Мирас» журналы саннарында Мөсәгыйдь бине Мостафа Йортыши дигән икенче бер медицина белгечебезнең 1824 елдагы кулъязма китапка теркәлгән «Тыйбб китабы»ның «Ашау-эчү белән дәвалану чаралары» бүлекчәсен нәшер итте [Мөсәгыйдь бине Мостафа Йортыши]. Әнвәр Хәйри бу авторның әлеге медицина китабы текстын «Мирас» журналының 1992 елда басылган №4–12 һәм 1993 елда нәшер ителгән 2, 3, 4 саннарында укучыларга җиткерде.

Әнвәр Хәйри бу ике автордан тыш Низаметдин дигән авторның «Тыйбб китабы»нда «Мирас» журналының 1992 елдагы №3 санында бастыруга хәзерләп биреп, хезмәте шул вакытта дөнья күрде [Низаметдин].

Бу сериядән хезмәт язган янә бер Мөхәммәд-Хәсән бине Хөсәен дигән авторның хезмәтен дә табып, Әнвәр Хәйри әлеге дүртенче авторның да хезмәтен татар халкына кайтарды [Мөхәммәд-Хәсән бине Хөсәен].

Бу авторларны табып, аларның хезмәтләрен матбугат өчен хәзерләп бастыру дәрәҗәсенә җиткерү Әнвәрнең зур файдалы эше булды. Аның бастырган табышлары татар медицина әдәбиятының

таралыш зонасын һәм структур төзелешен ачыклау юлында әһәмиятле документлар булып торалар. Тик кызганыч, дүрт авторның берсенең генә әсәре кульязмасының кайда саклану урыны күрсәтелгән, калган өчесенең кайдан табылуы да һәм төп чыганакның кайда саклануы да күрсәтелми. Хәер, бу жанр чыганакларының сан хисабы XIX йөз башларында татар медицинасы өстендә эшләүчеләрнең саны ишле булган дигән сүзгә дәлилдер. Чөнки безнең тарафтан шушы темага бәйләнешле булган кульязма табышларыбыз халкыбызда бай, язма медицина хәзинәләре сакланган булуга көчле дәлилләр алар. Бу өлкәдә эшләүче фәнни хезмәтләргә менә дигән язма чыганаклар белән эшләү мөмкинлеге ачылган.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Габделвахид мөфти ибне Сөләйман. Төрле авырулардан дәвалау чаралары // Мирас. 1991. №1. 87–92 б.

2. Мәрҗани Шиһабетдин. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 415 б.

3. Мөсәгыйдь бине Мостафа Йортыши. Ашау-эчү белән дәвалану чаралары // Мирас. 1992. №4–12; 1993. №2–4.

4. Мөхәммәд-Хәсән бине Хөсәен. Тыйбб китабы // Мирас. 1993. №5, 6.

5. Низаметдин. Тыйбб китабы // Мирас. 1992. №3. 98–99 б.

**М.И. Ахметзянов**

## Труды Анвара Хайри, имеющие отношение к татарскому письменному наследию

*Аннотация.* Статья посвящена деятельности Анвара Хайри по переводу на современный татарский язык трудов татарских специалистов по медицине XIX столетия и публикации этих материалов в журнале «Мирас».

*Ключевые слова:* татарское письменное наследие, народная медицина, Анвар Хайри.

**M.I. Akhmetzyanov**

## Anwar Hayri's works concerning the Tatar written heritage

*Annotation.* The article is devoted to Anwar Hayri's activities for the translation into modern Tatar language of works of the Tatar experts in medicine of the XIX century and the publication of these materials in the «Miras» magazine.

*Keywords:* Tatar written heritage, traditional medicine, Anwar Hayri.

**Автор турында мәгълүмат**

**Әхмәтҗанов Марсель Ибраһим улы –** филология фәннәре докторы, Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш гыйльми хезмәткәре, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (Казан шәһәре).

**Ахметзянов Марсель Ибрагимович** – доктор филологических наук, главный научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г.Ибрагимова АН РТ, заслуженный деятель науки РТ (г.Казань).

**Akhmetzyanov Marsel Ibragimovich** – doctor of philological sciences, Chief researcher of G. Ibragimov Insitute of Language, Literature and Art of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Honored Scientist of the Republic of Tatarstan (Kazan).

УДК 303.446.4

**Л.Ф. Байбулатова**

# РИЗАЭТДИН ФӘХРЕТДИН МИРАСЫН КАЙТАРУДА ӘНВӘР ХӘЙРИНЕҢ РОЛЕ

*Аннотация.* Мәкаләдә Әнвәр Нәҗип улы Хәйринең галим, дин эшлеклесе Ризаэтдин Фәхретдин мирасын барлауда һәм халыкка кайтаруда тоткан урыны күрсәтелә. Әнвәр Хәйри галимнең дини, тарихи, тәрбияви хезмәтләрен хәзерге телгә күчереп һәм бастырып, беренчедән, татар галимнәренең мирасын кайтаруда зур роль уйнады, икенчедән, Риза Фәхретдин әсәрләрен киң катлам укучыларга танытты.

*Ачкыч сүзләр:* Әнвәр Хәйри, Ризаэтдин Фәхретдин, Болгар вә Казан төрекләре, мирас.

Әнвәр Нәҗип улы Хәйри үзенең фәнни эшчәнлегенең бер өлешен Ризаэтдин Фәхретдин мирасы белән бәйләгәне барыбызга да билгеле. Аның мирасын өйрәнү, кайтару юлында ул беренчеләр сафында булган, дөресрәге, Риза казый тормышы, эшчәнлеге белән кызыксынучылар күп булса да, аның хезмәтләрен гарәп имлясыннан кириллицага күчереп бастырып чыгару – Әнвәр Нәҗипович башлап җибәргән эш. Аның иң беренче тәрҗемәсе «Болгар һәм Казан төрекләре» исемле китап 1993 елда басылып чыга, соңрак 2000 еллар башыннан алып Әнвәр Нәҗип улы Ризаэтдин Фәхретдиннең «Гыйльме әхлак» сериясеннән китаплар тәрҗемә итеп чыгара башлый. Башта алар «Идел» һәм «Мәгариф» журналларында кисәк-кисәк басылып чыксалар, алга таба берничә китап формасында дөнья күрделәр. Шулай итеп Ризаэтдин Фәхретдиннең балалар, ата-аналар, укучылар өчен язылган төрле «Нәсыйхәт»ләре: Нәсыйхәт: Әхлак гыйлеменнән дәреслек-кулланма: 1 нче, 2 нче, 3 нче китап (Казан, 2004); Нәсыйхәт: әхлак гыйлеменнән (Казан, 2005); Балаларга нәсыйхәт. (Казан, 2006. Бу китап эченә Ризаэтдин Фәхретдиннең «Тәрбияле бала», «Әһле гыяль», ир балаларны тәрбияләр өчен «Нәсыйхәт 1», кыз балаларны әхлакый тәрбияләр өчен «Нәсыйхәт 2», ата-аналарны әхлакый тәрбияләр өчен «Нәсыйхәт 3», «Шәкертлек әдәпләре» әсәрләре кергән), шулай ук «Гакыйдә», «Ислам дине» «Әдәп вә әхлак дәресләре» (Казан, 2006); «Адабе тәгълим (укыту кагыйдәләре)» (Казан, 2006); «Гаилә», «Тәрбияле ана», «Тәрбияле хатын» (Казан, 2006); «Ислам дине –

нинди дин?» (Казан, 2009) китаплары, «Гаилә» киң катлам укучыларга иреште.

Әлбәттә, бу китапларны да әзерләү өчен Әнвәр Нәҗип улыннан зур осталык соралды, аларны эшләп чыгару өчен гарәп графикасын, гарәп-фарсы алынмаларын белергә кирәк, хәзерге татар теленә күчергәндә мәктәп балаларына, аларның ата-аналарына аңлаешлы стиль белән язарга кирәклеген онытмаска кирәк. Ризаэтдин Фәхретдин теле белгечләр өчен никадәр җиңел булса да, хәзерге укучылар өчен язма тел формасы катлаулырак.

Ризаэтдин Фәхретдиннең әхлак, тәрбия, гаиләдәге мөнәсәбәтләр турында язылган хезмәтләр һәрбер кешенең өстәл китаплары булырга тиеш дип саный иде Әнвәр Нәҗип улы. Аның фикеренчә, бу китапларның хәзерге вакытта әһәмияте бик зур, чөнки Риза Фәхретдин бу хезмәтләрендә халкыбызның күп гасырлар дәвамында яшәп килгән тәрбия чараларын, гаиләнең гореф-гадәтләрен, гомумән алганда халык педагогикасы ядкәрләрен туплаган, шуңа күрә алар хәзерге вакытта халыкка хезмәт итәргә, буыннан-буынга күчеп сакланырга тиешләр [Фәхреддин, 2006, 18 б.].

Ләкин Әнвәр Нәҗип улы киң катлам укучыларын Ризаэтдин Фәхретдин белән аның тарихи хезмәтләре аша таныштыра башлый. Һәм таныштыруы гади укучыларга гына түгел, хәтта белгечләргә дә табуы авыр булган галимнең кулъязма әсәрләре белән бәйле.

Риза казый эшчәнлеге белән шөгыльләнүчеләргә билгеле, аның кульязмалары хәзерге вакытта Уфа гыйльми үзәгенең фәнни архивында саклана, алар ике өлештән тора, беренчесендә 40 данә эш, икенчесендә 16 данә эш тупланган. Алар арасында төрле хатлар, шәҗәрәләр, документлар, эпиграфик материаллар, шигъри һәм язма әсәрләр, шул исәптән галимнең сакланып калган фәнни хезмәтләре дә бар. Мәсәлән, «Асар»ның 3 һәм 4 нче томнары, «Юаныч», «Ислам дине»нең берничә варианты, мәшһүр Акчуриннарга багышланган рисалә, «Болгар вә Казан төрекләре» кульязмасы. Нәкь менә шул хезмәткә туктап каласы килә.

Югарыда әйтелгәнчә, 1993 елда Татарстан китап нәшриятында Ризаэтдин Фәхретдиннең «Болгар вә Казан төрекләре» исемле хезмәте дөнья күрә. Китапны әзерләгән кеше – Әнвәр Нәҗип улы Хәйри. Бу әсәр белән Әнвәр Хәйри 1979 елда ук Диния Нәзарәтендә таныша һәм беренче өлешен фотога төшереп ала [Хәйри, 2007, 25 б.]. Ләкин белгечләр әйтүенчә, Риза казыйның Диния Нәзарәтендә саклана торган архивы Уфа фәнни үзәгенең архивына 1963 һәм 1966

елларда тапшырылган [Харисов, 1988, с.79]. Күрәсең, Нәзарәттә «Болгар вә Казан төрекләре» әсәренең копиясе булган, ләкин бу турыда Әнвәр Хәйри берни язмаган, һәм бу факт уйга калдыра, бәлки Диния Нәзарәтендә Риза казыйның башка кульязмалары да әле дә саклана.

1980 нче елларда Әнвәр Нәҗип улы Уфа фәнни үзәгенең архивында Риза казый мирасын тирәнрәк өйрәнә һәм шуның нәтиҗәсе буларак аның «Рукописное наследие Р.Фахрутдинова как источник изучения истории татарской общественной мысли» исемле мәкаләсе басылып чыга [Хайруллин, 1985, с.73–84]. Архивта галим 40 томлык фондны өйрәнә һәм кабат «Болгар вә Казан төрекләре» белән кызыксына. Берничә елдан соң әлеге өйрәнүләрнең нәтиҗәсе китап формасында басылып чыга. 1993 елда чыккан китап «Болгар вә казан төрекләре» исеме йөртсә дә, анда шул кульязманың бер өлеше генә урын тапкан. Шулай ук анда «Асар», «Ислам дине», «Юаныч» һәм «Мәрҗани мәҗмүгасы»ннан өзекләр, Риза Фәхретдиннең Диния Нәзарәте архивын саклап калу өчен губерния комитетына язган хаты китерелә. Мәрҗани мәҗмугасыннан башка хезмәтләр басылмаган килеш кульязма формасында саклаланалар иде, шуңа күрә Әнвәр Нәҗипович аларның да копияләрен булдыра алган дигән фараз туа. Соңрак Әнвәр Хәйри эшкәртүендә «Ислам дине» китабының басылып чыгуы шул фаразның дөреслеккә туры килгәнен раслый.

Ләкин ничек кенә булмасын, әлеге китапның чыгуы Ризаэтдин Фәхретдин мирасын барлауда, халыкка кайтаруда беренче һәм әһәмиятле тәҗрибә иде. Әлбәттә, Әнвәр Нәҗипович зур күләмле, 559 биттән торган «Болгар вә Казан төрекләре» кульязмасын тулысынча бер китапта бастырып чыгара алмаган, шулай ук югарыда искә алынган хезмәтләр дә зур күләмле, шуңа күрә ул Риза Фәхретдин хезмәтләреннән төркиләрнең тарихын, мәдәният тарихында эз калдырган шәхесләрнең тормышын, мәгариф тарихын, рухи мәдәният тарихын, дин, әхлак мәсьәләләрен өйрәнү өчен өзекләр сайлап китап туплаган. Әнвәр Хәйринең бу хезмәте 90 нчы еллар башында да әһәмиятле иде, хәзер дә әһәмиятен югалтмаган, чөнки Риза казыйның ул кульязмалары («Асар»дан башка) әлегә кадәр басылмаган. Ә аларның фәнни әһәмияте бәхәссез, беренчедән, аларда беренче кул чыганаклардан җыеп алынган мәгълүмат бик күп, икенчедән бу әсәрләр татар тарихы историографиясенең шул вакыттагы торышын күрсәтәләр. Мәсәлән, «Болгар вә Казан тө-

рекләре» хезмәтен алсак, анда халкыбызның тарихы борынгы төркиләрдән алып совет хакимлеге урнашуына кадәр күрсәтелгән. Борынгы төрки чор буенча чыганаклар булмаса да, Касыйм ханлыгы документлары, шулай ук 118 кабер ташъязмасы, әлегә кадәр дә тарихчыларга билгеле булмаган «Татархания» исемле кульязма турында мәгълүматлар бар. Шулай ук Идел-Урал буйларында ислам дине, Диния Нәзарәте турында аерым бер бүлек бар. Бу бүлек үзе аерым бер китапка тиң һәм аның әһәмияте Риза казыйның Нәзарәт архивындагы документларыннан файдалануында, кайбер вакыйгаларда аның шәхсән катнашуында чагыла. «Юаныч» китабына килсәк, ул шулай ук зур күләмле ике томлы хезмәт, хәзерге вакытта аның беренче томы югалган, икенчесендә ислам дөньясы, халкыбызның мәдәнияте тарихы урын алган.

Шулай итеп, бу китапның Риза Фәхретдиннең берничә хезмәтеннән туплануы очраклы түгел. Әнвәр Нәҗипович галимнең төрле темалар белән шөгыльләнүен, хезмәтләрендә фактологик чыганакларның булуын, аларны барлау һәм кайтару кирәклеген күрсәткән, шуңа күрә үзенең китабын беренче тәҗрибә дип юкка гына атамаган. Шунысын да әйтеп узарга кирәк, 2007 елда Ризаэтдин Фәхретдин педагогик укуларының 3-нче кисәге басылып чыкты. Шунда Әнвәр Нәҗипович мәкаләсендә аның «Болгар вә Казан төрекләренең» икенче тулыландырылган басмасын әзерләве турында язылган [Хәйри, 2007, 16 б.]. Ул басманы һичшиксез чыгарырга кирәк, чөнки анда беренче басмага керми калган Риза Фәхретдин әсәрләреннән өзекләр булырга мөмкин. Бу китап яңадан басылып чыкса, Әнвәр Нәҗип улы Хәйринең киләчәктә Ризаэтдин Фәхретдиннең күп томлы әсәрләре дөнья күрү өметенә туры киләчәк.

## ӘДӘБИЯТ


1. Хайруллин А. Рукописное наследие Р.Фахрутдинова как источник изучения истории татарской общественной мысли // Проблема преемственности в татарской общественной мысли. Казань, 1985. С.73–84.

2. Хәйри Әнвәр. Ризаэддин Фәхреддин – тарихчы // Мәшһүр мәгърифәтче-галим, педагог Ризаэддин Фәхреддин мирасын укыту-тәрбия процессында файдалану. III кисәк. Казан, 2007.

3. Фәхреддин Р. Гаилә. Тәрбияле ана. Тәрбияле хатын. Казан, 2006.

4. Харисов А.И. Коллекция рукописей Ризаитдина Фахретдинова в Научном архиве БФ АН СССР // Творчество Ризы Фахретдинова. Материалы исследования. Уфа, 1988.

**Л.Ф. Байбулатова**

## Роль Анвара Хайри в возвращении творческого наследия Ризаэтдина Фахретдина

*Аннотация.* В статье показана роль А.Н. Хайруллина в изучении и возвращении широкому кругу читателей наследия ученого и религиозного деятеля Ризаэтдина Фахретдина. Анвар Хайри сыграл большую роль в популяризации трудов Р.Фахретдина, переведя их с арабской графики на современный татарский язык, и оказал большое значение на процесс изучения развития татарской исторической мысли начала XX в.

*Ключевые слова:* Анвар Хайри, Ризаэтдин Фахретдин, Булгарские и Казанские тюрки, наследие.

**L.F. Baybulatova**

## Anwar Hayri's role in return of a creative heritage of Rizaetdin Fakhretdin

*Annotation.* A.N. Khayrullin's role in studying and return to a wide range of readers of heritage of the scientist and religious figure Rizaetdin Fakhretdin is shown in article. Anwar Hayri played a big role promoting of works of R. Fakhretdin, having transferred them from the Arab graphics on modern Tatar language, and rendered great value on process of studying of development Tatar historical the beginnings of the XX century.

*Keywords:* Anwar Hayri, Rizaetdin Fakhretdin, Bulgar and Kazan Turkic peoples, heritage.

**Автор турында мәгълүмат**

**Байбулатова Лилия Фәрит кызы** – тарих фәннәре кандидаты, ТФАның Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты М.Г. Госманов исемендәге Алтын Урда һәм татар ханлыкларын өйрәнү үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре (Казан шәһәре); e-mail: bayli77@mail.ru

**Байбулатова Лилия Фаритовна** – кандидат исторических наук, старший научный сотрудник Центра исследований Золотой Орды и татарских ханств им. М.А. Усманова Института истории им. Ш.Марджани АН РТ (г.Казань).

**Baybulatova Liliya Faritovna** – candidate of historical sciences, senior researcher, Usmanov Center for Research on the Golden Horde and Tatar Khanates, Sh.Marjani Institute of History, Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan (Kazan).

УДК 908

**Д.Р. Гыйлметдинов**

# СОВЕТ МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘРЕ ҺӘМ ИСЛАМ ТЕРМИНОЛОГИЯСЕ (ТАТАР ДИНИ МИРАСЫН БАРЛАУДА ӘНВӘР ХӘЙРИНЕҢ РОЛЕ)

*Аннотация.* Үзенең берничә проекты белән Ә. Хәйри татарлар тарихына үтеп кергән. Татарларның бүгенге яшәешен аңлата торган иң мөһим хезмәте – Шиһабетдин Мәрҗанинең ике томлык «Мөстәфадәл-әхбар»ның 1989 елда кыскартып басылган тәрҗемәсе. Әсәрнең татар теленә бердәнбер күчермәсе тиражының зурлыгы (50 мең данә) белән Мәрҗанинең «визит карточкасына», зур шәхеснең «символы» буларак таралыш алган. Бөек Мәрҗанинең совет заманында басылган бердәнбер хезмәте укучыларга ни рәвештә тәкъдим ителгәнен бу мәкаләбездә тикшерербез.

*Ачкыч сүзләр:* Ә. Хәйри, Мәрҗани, «Мөстәфадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» , татар дини әсәрләре, биографик сүзлекләр.

Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» әсәре татар мәдәниятендә бик мөһим урын биләп тора. Тарих фәненең методологиясе өлкәсендә маһир булган Йосыф әфәнде Акчура аны төрки халыклар арасында ике «беренче кулдан» язган тарихи әсәрләрнең (Риза Фәхретдинның «Асары» белән бергә) берсе буларак кабул иткән [Акчура, 2011, с. 615]. Шундый ук мактаулы сүзләрне бүгенге көнбатыш галимнәре дә әйтә. Мәсәлән, Натан Спаннаус аны татар социаль тарихын яктырткан өч әсәрләр исемлегенә керткән [Spannaus, 2011, 51–52 pp.]. Безнең уебызча, бу әсәр татар мәдәниятенең нигез ташы, татар традицион тормышының беренче энциклопедиясе буларак хезмәт итә. Риза Фәхретдин һәм Мөрад Рәмзи аның методологиясен дәвам иткәннәр. Әлеге әсәр шәхси карашлардан да азат түгел. Н. Спаннаус бу әсәрдә, «Асардан» аермалы буларак, документаль чыганакларны тәкъдим итүгә караганда тасвирлауга, авторның үз сүзләренә күбрәк урын бирелә, дип яза [Spannaus, 2011, 52 p.]. Географик яктан әсәр Казан төбәге мөселманнарының тормышына багышланган. Аның өйрәнү предметы – бөек шәхесләр һәм алар калдырган мирас. Идеологик яктан Ш.Мәрҗани ястү намазының мәҗбүри булуына

басым ясый – дини бәхәсләргә текстта шактый урын бирелә. Әсәрнең тагын бер үзенчәлеген атап үтү зарур. Китап Ш.Мәрҗанинең шәхси дини позициясеннән тыш, авторның «танышбелешләр түгәрәген» ача. Билгеле булганча, Ш.Мәрҗани нәселе олуг ислам дине галимнәренә барып тоташа – аның әтисе Бохарада татардан булган иң танылган дүрт кеше исемлегендә. Шуңа күрә бу «хрестоматиянең» асылында Мәрҗанинең туганлык һәм дуслык җепләре ята. Әлбәттә, автор бу чылбырларны нык киңәйткән, әмма җыю методикасы шул ук калган.

Фактологик яктан «Мәрҗанинең тарихы» бик бай. Монда бик күп исемнәр һәм географик «нисбәләр» (чәчмә (нарратив) вариантсхемага әйләндерү теләгеннән тыелып булмый). Әмма аны сүзлек яки монография дип атау дөрес булмас. Мин аны Ш. Мәрҗани шикелле кызыксынучан шәхес тарафыннан социаль (гөләмалар арасындагы) хәтер катламын (имеш-мимешләр белән бергә) истә тотып эшләнгән, нечкәлекләргә бирелмичә язылган Казан тирәсендәге «Исламның Юл Күрсәткече» дип атар идем.

Дини тематика, гарәп һәм фарсы телләрендәге хатлар һәм фәтвалар, гарәпчә касыйдәләр һәм пунктуация юклыгы текстны тулаем алганда аңларга комачаулый. Шул сәбәпле хезмәтнең икенче, дини-фактологик томы әлегә кадәр тулы рәвештә кириллицада басылганы юк.

Китапның 1989 елгы тәрҗемәсендә анда куелган мәсьәләләр нинди рәвештә чагылыш тапкан? Заманча татар теленә күчерү оригинал текстның күп сыйфатлары югалуга, шул исәптән конкрет тарихи мохиттән аерылуга, кеше белән бәйләнешнең юкка чыгуына, ягъни «Хуҗа Насреддин маҗаралары»на охшап китүгә сәбәп булган. Мәзәкләр, көлкеле вакыйгалар тәрҗемәдә сакланган, әмма алар анекдот кебек яңгырый. Совет редакторлары китапның төзелешен дә үзгәрткән. Мәрҗанинең системасы Казан төбәгендәге мәчетләрнең тарихына нигезләнгән булса, яңа вариантта ул дәүләт структурасына, рәсми иерархиягә таяна. Әлбәттә, мондый методология күпчелек танылган татар галимнәренең биографияләрен тәрҗемә басмасына кертергә ирек бирмәгән. Аларның кыска биографияләре кертелгән, әмма бу мәгълүмат шәхеснең зурлыгын, аның дәрәҗәсен тоярга мөмкинлек бирми. Кайсыберләренең «тәрҗемәи хәлләре» берничә урында очрый – мәчетнең имамы буларак һәм зыялы шәхес буларак бирелә. Мәчет тарихында зур

роль уйнамаган кеше дә кызыклы, уникаль шәхес буларак барыбер тасвирлана. Алар өчен Мәрҗани махсус бүлек төзи – «Мөһим соңгы голәмалар һәм Казан һәм Болгарга бәйләнеше булган затлар». Димәк, Мәрҗани өчен мәчетләр төп объект булса да, өйрәнелә торган предмет буларак алгы планда – күренекле мөселманнар.

Социаль инкыйлаб бөтен сфераларның гадиләшүенә китергән. Совет чорында дини күзаллауларга зур игътибар бирелмәгән. Шуның белән бергә автор-редакторлар кайбер авылларның тарихын (Мазарбаш, Түнтәр), кайбер чит галимнәр белән мөнәсәбәтләрен (Мөхетдин ибне Габделкадыйр әл-Җилани, Сирхинди һ.б.) күрсәтүдән гаҗиз калганнар. Бу фактлар – совет чоры күзаллавын күрсәтүче билгеләр. Алар Мәрҗанинең шәхси тирәнлеген, үзенчәлеген, ролен күрсәтми. Шуңа күрә китап Мәрҗаниның кайбер мәсьәләләргә карата фикерен белергә мөмкинлек бирсә дә, аны файдалану мөмкинлеге бик чикле. Бу – 1980 еллар чынбарлыгының чагылышы.... Кызганыч, без шушы халәттән әллә нинди зур дәрәҗәләргә менә алмадык. Чынбарлык бүген бөтенләй башка осталыкны таләп итә...

Инде галимебезнең эшен бәяләүгә күчик. Безнең уебызча, Ә. Хәйри дини терминологияне яхшы белгән шәхес. Аның тәрҗемәләрен башка текстологлар белән чагыштырып карыйк. Бу чагыштырудан дини текстларда исемнәрне аеру, аларны тану һәм аңлау дәрәҗәсендә күзәтеп була. Кайбер танылган совет галимнәре «гомумән» дип тәрҗемә ителә торган «галә-л-гомум» сүзен әсәр исеме буларак кабул иткән. Икенче мәшһүр остазыбыз «тулысынча, ахыргача» дип тәрҗемә ителә торган «галә-л-итлакъ» сүзенә дөрес тәрҗемәсен таба алмаган. Бу совет чоры галимнәренең гарәп телен аңламауларын күрсәтә. Гарәп теле белгече Ә. Хәйри тарафыннан тәрҗемә ителгән әсәрләр шушы ягы белән бик көчле. Әлбәттә, без анализлаган әсәр кайбер хаталардан азат түгел, әмма берничә очрактан тыш (мәсәлән, «Фаризед-даим» «өзлексез уйлау» дип һәм «Шарх Гавамил» «эшләр аңлатмасы» дип тәрҗемә итүдән башка) барлык дини әсәрләрнең гарәпчә исемнәре дөрес билгеләнгән һәм тәрҗемә ителгән. Әйтергә кирәк, төп текстта бернинди билгеләр (куштырнаклар, нокталар, сызыклар) юк. Шуңа күрә еш кына китапның исемен аеру бик авыр. Бер мисал: «...Фарсый әл-гыйбара улан тәракиб мансурия инкяр мансубтыр сахиб тәрҗемә...» дигән гыйбарәсен «биографиянең хуҗасы фарсы теленең алга таба

таралышын туктаткан» дип тәрҗемә итү хата булмас [Мәрҗани, 1900, 296 с.]. Әмма шулай аңлау дөреслеккә туры килми, моны аңлар өчен тәҗрибә һәм фәнни караш таләп ителә. Андый сыйфатка Әнвәр абый ия булган. Ул бу җөмләне дөрес итеп «Фарсы телендәге «Тәракыйбе Мансурия» китабы аңа нисбәтләнә» [Мәрҗани, 1989, 212 б.] дип тәрҗемә иткән. Ягъни аның (беренче мөфтинең этисенең) исеме Мансур булганлыктан алга таба барган сүзне ул «инкяр» түгел, ә «аңар» дип тәрҗемә иткән (гарәп «н» һәм «к» бергә «ң» хәрефен тәшкил итә) – шулай итеп контексттан чыга торган «фарсы теле алга таба үсешен туктаткан» урынына иҗат белән бәйле булган дөрес мәгънә чыккан. Әлбәттә, шундый осталыкка, тәҗрибәгә ия булу өчен ниндидер эчке тойгы, дини әсәрләрнең исемнәрен белү таләп ителә. Совет заманы кешесендә шундый сыйфат булуына шаккатасың.

Ә. Хәйри һәм Я. Абдуллин редакциясендәге «Мөстәфадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» әсәренең 3–4 тапкыр кыскартылган варианты «Мәрҗани әсәре» булудан туктамады. Тик ул «җанлылыгын», конкрет-тарихи шартлары белән бәйләнешен югалткан. Ягъни бу тәрҗемә 1980 елларның «татарлашкан» фәнни хезмәте. Бүгенге укучыны бу мәшһүр хезмәтнең тулы тексты белән таныштыру өлкәсендә без, галимнәр, соңарабыз...

**ӘДӘБИЯТ**


1. Акчура Й. Гыйлем һәм тарих // Акчура Й. Сайланма әсәрләр. – Казан, 2011. – 594–623 б.

2. Мәрҗани Ш. Мөстәфад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болган (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан, 1989. 415 б.

3. Мәрҗани Ш. Әл-кыйсем әл-сани мин әл-китаб «Мөстәфад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» (Вторая часть книги «Источники по истории Казани и Булгара»). – Казан, 1900.

4. Spannaus N. Rizaéddin Fäxreddin and the Social History of the Muslim Communities of the Russian Empire (Ризаэддин Фахретдин и социальная история мусульманских общин Российской империи) // Ab imperio. 2011. No.4. P. 51–57.

**Д.Р. Гильмутдинов**

## Советские просветители и исламская терминология (роль Анвара Хайри в изучении татарского религиозного наследия)

*Аннотация.* Анвар Хайри вошел в татарскую историю благодаря успешности нескольких своих источниковедческих проектов. Для современных татар самым важным можно считать издание сокращенной версии двухтомного историко-теологического труда «Мустафад аль-ахбар» («Источники по истории Казани и Булгара»). Единственность переложения этой работы на современный язык, вкупе с огромным тиражом (50 тысяч экземпляров), сделала перевод А. Хайри «визитной карточкой» или «олицетворением» крупной личности. В каком же виде предстал Марджани советскому читателю, мы объясним в предлагаемом очерке.

*Ключевые слова:* А. Хайри, Марджани, «Мустафад аль-ахбар», татарские религиозные сочинения, биографический словарь.

**D.R. Gil’mutdinov**

## Soviet ‘enlighteners’ and islamic terminology (tatar’s religious heritage and Anwar Khairi’s role in it’s promotion and studying)

*Annotation.* The scientific activity and interpretation of classic tatar biographical dictionaries by Anwar Khairi made him part of the tatar history. Among this sources for nowadays tatars the most important is the short edition of two volume book «Mustafad al-akhbar fi akhvali Kazan va Bulghar». Being the only interpretation of this fundamental work into present-day languages and the amount of printed books (50 thousand) this 1989$^{th}$ year edition is the only work, that demonstrates the marvelousness of the figure of Marjani. How much does this exemplar reflect the original work? We’ll try to find the answer in this essay.

*Keywords:* A. Khairi, Marjani, «Mustafad al-akhbar», tatar religious sources, biographical dictionary.

**Автор турында мәгълүмат**

**Гыйлметдинов Данияр Рөстәм улы** – тарих фәннәре кандидаты, ТФАнең Исламны өйрәнү үзәгенең чыганакларны өйрәнү бүлеге җитәкчесе (Казан шәһәре); email: ascoldan@gmail.com

**Гильмутдинов Данияр Рустамович** – кандидат исторических наук, заведующий отделом источниковедения Центра исламоведческих исследований АН РТ (г. Казань).

**Gil’mutdinov Daniiar Rustamovich** – candidate of historical sciences, Chief of Department of source studying of Center of Islamic Studies of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan (Kazan).

УДК 025

**А.З. Загидуллин**

# НЕКОТОРЫЕ АСПЕКТЫ КОМПЛЕКТОВАНИЯ «КОЛЛЕКЦИИ ТАТАРСКОЙ ЭМИГРАЦИИ» ИЗ ФОНДА ОТДЕЛА РУКОПИСЕЙ И РЕДКИХ КНИГ НАЦИОНАЛЬНОЙ БИБЛИОТЕКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

*Аннотация.* В статье описывается «Коллекция татарской эмиграции» из фонда отдела рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан. Перечисляются хранящиеся в коллекции книги, газеты, журналы и рукописные материалы.

*Ключевые слова:* библиотечные фонды, источниковедение, книжные коллекции, татарские эммигранты, история татар.

Так исторически сложилось, что много наших соотечественников-татар живут за пределами России. Татарские общины есть в США, Финляндии, Турции, Китае, Японии и в других странах. Где бы татары не жили, они издавали и продолжают издавать книги, газеты и журналы. «Коллекция татарской эмиграции», хранящаяся в отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан, включает газеты, журналы, рукописные и печатные книги, архивные документы, фото- и аудиоматериалы, созданные нашими соотечественниками, проживавшими и проживающими за пределами исторической родины.

Поводом к рождению идеи о создании такого фонда послужила проведенная в 2010 году презентация книг о татаро-японских связях, переданных в дар Библиотеке доктором социологических наук, преподавателем японского языка и японоведения Института востоковедения К(П)ФУ Ларисой Усмановой. Участники презентации увидели выставку «Возвращенные имена», на которой были представлены газеты, журналы и книги, изданные на татарском языке татарскими эмигрантами и хранящиеся сегодня в фондах Национальной библиотеки. И в конце 2014 года было принято решение о создании этой коллекции.

Сегодня в коллекции татарской эмиграции много уникальных документов. Это и номера газеты «Милли байрак», которая выпускалась в Мукдене с 1935 по 1945 гг. Решение о создании газеты

было принято в феврале 1935 г. в Мукдене (Маньчжурия) на первом объединительном съезде тюрко-татар Дальнего Востока. В течение всех 10 лет редакционный состав газеты был следующим: редактор – **Ибрагим Девлет-Кильди,** основной автор статей – **Рукия Мухамедиш**, издатель – **Сельман Аити**. В коллекции хранится 84 номера оригинальных экземпляров газеты с 1935 по 1941 гг. Вместе с электронными копиями подборка газеты составляет 151 номер. Это единственный на сегодняшний день самый полный комплект газеты в Казани.

Также в коллекции есть журнал «Милли юл» – «Яңа милли юл», который выпускался в Берлине с 1928 г. Редактором журнала был известный татарский писатель, политический и общественный деятель Гаяз Исхакый. Почти за 11 лет существования журнала увидели свет 136 номеров. Из них в библиотеке хранятся 74 номера журнала (с электронными копиями) с 1930 по 1939 гг.

Особое место в фонде занимают книги и периодические издания татарских эмигрантов, в которых бережно сохраняется наследие Тукая. Это книги, изданные нашими соотечественниками в Финляндии и Китае, отдельные номера газеты «Милли байрак» (Мукден) и журналов «Яңа Милли юл» (Берлин), «Казан» (Турция), которые посвящены поэту. Из этих изданий видно, что Тукай был и остается объединяющим духовным маяком для всех татар, где бы они не жили.

Проживая в Турции, татары также создавали национальные организации, выпускали газеты, журналы, книги. Одной из ярких страниц истории татар в Турции стало издание журнала «Казан», который публиковался с 1970 г. в Стамбуле. Журнал «Казан» издавался один раз в три месяца, последний его номер вышел в 1980 г. В отделе рукописей и редких книг хранится 44 экземпляра журнала за 1970–1980 гг.

Начиная с конца XIX в. много татар стало переселяться в Китай, а затем в Японию и Корею. Постепенно у них возникли и различные национальные, политические и общественные организации, стали функционировать мечети и учебные заведения. В 1920-е гг. эмигранты стали издавать газеты, журналы и книги. Одним из первых периодических изданий стал журнал «Ерак Шәрык», который в 1920–1922 гг. выпускало татарское общество Харбина. В коллекции хранится 14 номеров журнала за 1921 г. Журнал выпускался под редакцией Г. Ахмади, Х. Габдуша и Р. Рахмати.

Ценными также являются книги, изданные татарскими эмигрантами в Японии в организованной в Токио типографии «Матбагаи Исламия». Это книги Г. Ибраһимова «Татар нәһүе», «Татарча сарыф» (1935 г.), А. Максуди «Җәмагәт» (1930 г.), «Руза, зәкәт вә хаҗ» (1931 г.), Г. Таиба «Холясател-мәсаил вә мөһиммәтел-дәлаил» (1938), сборники стихов Максуда Файзрахмана (1931–1934 гг.), а также другие издания. Всего в фонде присутствует 13 книг, изданных в Токио.

Общественно-политический журнал «Азат Ватан» издавался в Мюнхене (Германии) в 1952–1953 гг. под редакцией А. Файзуллина, М. Карими, Г. Исхакый и других. В редком фонде есть три номера журнала, изданные в эти годы. В коллекции присутствуют произведения Г. Исхакый, изданные в Берлине (Германия): пьесы «Дулкын эчендә» (1937 г.), «Жан Баевич» (1939 г.), рассказы «Көз» (1938 г.), «Өйгә таба» (1938 г.).

Членами правления Общества культуры тюрко-татар города Шанхай выпускались рукописные газеты. Два экземпляра газеты под названием «Берлек» («Единство») от 15 октября 1935 г. хранятся в отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки. Один экземпляр был передан Р. Салиахметом в 1993 г., а второй – профессором Калифорнийского университета США Айшой Азаде-Рорлих в 2010 г. Проживающая в США большая диаспора татарских эмигрантов выпускала свои произведения и сборники стихов, некоторые из них были переданы в фонды коллекции. Например, сборники стихов Ахмеда Гарая, перевод на татарский язык поэм Эмили Дикинсон, различные статьи о жизни татарских эмигрантов Америки.

Создание этого уникального фонда не было бы возможным без помощи наших соотечественников: Равиля Салиахмета, Халиды Дауш, Рокыи и Даяна Сафа, Айши Рорлих (США), Надира Давлета, Матина Токъала, Ахмета Языджыоглу (Турция), Ларисы Усмановой (Япония), Мунира Ерзина (Китай-Казахстан) и многих других. Мы выражаем им свою благодарность и надеемся, что в дальнейшем при помощи наших соотечественников фонд будет пополняться.

**А.Җ. Заһидуллин**

**Татарстан Республикасы Милли китапханәсе Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге фондында саклаучы «Татар мөһаҗирләре коллекциясе»н туплауның кайбер аспектлары**

*Аннотация.* Мәкаләдә Татарстан Республикасы Милли китапханәсе Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклаучы «Татар мөһаҗирләре коллекциясе» бәян ителә. Коллекциядә саклаучы китаплар, газета-журналлар, кулъязма материаллар турында сөйләнелә.

*Ачкыч сүзләр:* китапханә фондлары, китап коллекцияләре, чыганакларны өйрәнү фәне, татар мөһаҗирләре, татар тарихы.

**A.Z. Zagidullin**

**Some aspects of the acquisition «Collections Tatar emigration» from fund of manuscripts and rare books of the National Library of the Republic of Tatarstan**

*Annotation.* The article describes the «Collection Tatar emigration» from the fund department of manuscripts and rare books of the National Library of the Republic of Tatarstan. Lists are stored in a collection of books, newspapers, magazines and manuscripts.

*Keywords:* library collections, source, book collection, Tatar emigrants, the history of the Tatars.

**Автор турында мәгълүмат**

**Заһидуллин Айрат Җиһангир улы** – Татарстан Республикасы Милли китапханәсе Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире (Казан шәһәре); e-mail: A.Zagidullin@tatar.ru

**Загидуллин Айрат Зигангирович** – заведующий отделом рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан (г.Казань).

**Zagidullin Ayrat Zigangirovich** – Head of Department of manuscripts and rare books of the National Library of the Republic of Tatarstan (Kazan).

УДК 329.1/6

**И.К. Заһидуллин**

# 1905 ЕЛДА МӨСЕЛМАННАРНЫҢ КАЗАН ГУБЕРНАСЫННАН ХӨКҮМӘТКӘ ЮЛЛАГАН ПЕТИЦИЯЛӘРЕНДӘ ҖӘДИТЧЕЛӘР ҺӘМ КАДИМЧЕЛӘР КАРАШЛАРЫНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ*

*Аннотация.* Мәкаләдә 1905 елда мөселманнарның хөкүмәткә юллаган күмәк гаризаларында кадимчеләрнең һәм җәдитчеләрнең фикерләрен аерып карау методикасы тәкъдим ителә.

*Ачкыч сүзләр:* Җәдитчеләр, кадимчеләр, либераллар, социалист-революционерлар, петицияләр.

Җәдитчеләр һәм кадимчеләр арасында үзара һәм халык массаларына йогынты ясау максатында идеологик көрәш-бәхәснең кискенләшүе Беренче рус инкыйлабы елларына туры килә. Бигрәк тә татар вакытлы матбугаты оешу һәм газета-журналларның күпчелеге җәдитчеләр кулында туплануы каршылыкны көчәйтеп җибәрә һәм аларга үз фикерләрен пропагандалау өлкәсендә өстенлекләр бирә.

Без, гадәттә, кадимчеләр дип элекке традицияләрне саклаучы һәм яңалыкны кабул итмәүчеләрне атыйбыз. Алар сәяси планда монархияне яклаучылар, нинди дә булса кискен үзгәрешләргә каршы як булып чыга. Бу кешеләр татар иҗтимагый тормышында аерым бер урын тоткан кадимче муллалар төркеменә туры килеп тора сыман. Илдә зур тизлек алган сәяси партияләр төзелеше, сәясәтнең йогынтысы көчәю, Дәүләт Думасына сайлаулар татар җәмгыятьләрендә иҗтимагый вазифа башкаручыларның, төбәк лидерларының сәяси яктан үзбилгеләнүләрен таләп итә.

Галимҗан Ибраһимов «Татарлар арасында революцион хәрәкәтләр» исемле хезмәтендә XX гасыр башында татарлар арасында формалашкан берничә сәяси агымны атый. Сүз социал-демократлар, социалист-революционерлар (эсерлар, «татар социалистлары» яки «таңчылар»), милли буржуазия яки «Иттифак әл-мөс-

---

* Мәкалә 14–11–16003/15 (а/р) номерлы РГНФ гранты чикләрендә башкарылды.

лимин» партиясе (кадетлар) һәм карагруһлар турында бара [Ибраһимов, 1984, 212–435 б.]. Чыннан да, илдәге демократик үзгәрешләр иҗтимагый мәйданда төрле юнәлештәге сәяси ориентир тоткан шәхесләргә сүз әйтү мөмкинлеге бирә. Бер үк вакытта, бу сәяси һәм иҗтимагый барышта татар халкының төп өлеше – авыл игенчеләре катнашмый диярлек, аерым очракларда алар үзләренең мәхәллә яки авыл җәмгыяте лидерларын тыңлап, алар белән килешкәннәр.

1905 елгы яңарышны берничә этапка бүлеп карарга мөмкин. Шуның беренче һәм барлык социаль катламнарга зур йогынты ясаганы – 1905 елның августын кертеп, «Иттифак әл-мөслимин» партиясе оешканчы булган вакыт – Идел буе һәм Урал төбәгендә көн итүче мөселманнар арасында киң җәелгән петицияләр бирү хәрәкәте була. Императорның «Дәүләттә идарә тәртибен камилләштерүгә юнәлтү» («О предначертаниях к усовершенствованию государственного порядка») исемле 1904 ел 12 декабрь Указы ил халкына хакимиятнең киң масштаблы реформаларга үткәрергә әзер булуын белдерә. Указ киләчәктә барлык ватандашлар да кануннар һәм мәхкамә алдында тигез хәлгә куелачагына, шәһәр һәм земство үзидарә оешмалары өстәмә хокукларга ия булачагына ышандыра, эшчеләрнең хәлен исәпкә алган гадел кануннар мәҗмугасын әзерләү, дәүләт һәм конфессияләр мөнәсәбәтләре өлкәсендә халыкларның нинди дин тотуларына һәм кайсы төбәктә яшәүләренә карап эшләнгән һәм аларны кимсеткән кануннарны юкка чыгару, матбугат һәм сүз ирege өлкәсендә бертөрле хокуклар бирү хакында игълан итә.

Николай II нең 1905 ел 18 февраль рескрипты Россиядә яшәүче һәркемгә, нинди социаль катлам вәкиле булуына һәм нинди дин тотуына карамастан, император исеменә дәүләт төзелешен һәм халыкларның тормышын яхшыртуны (!) күздә тоткан гаризалар, тәкъдимнәр җибәрүне сорап мөрәҗәгать бирергә рөхсәт итә. Әйтергә кирәк, моңарчы императорга теләсә кем гариза бирә алмаган, мондый кыю гамәл өчен кешеләрне мәхкамә җаваплылыгына тартканнар. Дөрес, мондый демократия уйнау, халыкларга императорга турыдан-туры мөрәҗәгать итү мөмкинлеге бик кыска гомерле булып чыга: 1905 елның 6 августында Россиядә Дәүләт Думасын оештыру турында канун дөнья күргәч тәмамлана.

Мөмкинлектән файдаланып, Идел-Урал төбәгендә яшәгән мөселманнар 500 дән артык петиция юллыйлар. Галимҗан Ибраһимов

шәрехләгән төрле сәяси агым вәкилләре нәкъ менә петицияләр бирү кампаниясе барышында формалаша башлый. Төгәлрәк әйтсәк, аның өчен шартлар туа – дин белән бәйле булган кимсетүләрне юкка чыгару турындагы күмәк гаризаларның эчтәлеген тикшерү һәм Санкт-Петербургка җибәрү өчен вәкилләр сайлау максатында хакимият рөхсәте белән уздырылган мәҗлесләрдә барча муллалар, байлар, битараф булмаган кешеләр катнашкан. Шунысы кызык, бер генә калада да, салада да ике аерым җыелыш ясап, бу төркемнәрнең аерым гаризалар бирүе күзәтелми. Димәк, татар мөселманнарның милли һәм дини хокукларны киңәйтү мәсьәләсендә җәдитчеләр дә, кадимчеләр дә бердәм хәрәкәт иткәннәр, Россиядәге «милли мәсьәлә» буенча либераллар белән монархия яклы кадимчеләрнең карашлары охшаш булган дигән фикер туа.

Киңрәк караганда, петиция бирүдәге хезмәттәшлек инде 1880 еллар ахыры – 1890 еллар башында җәдитчеләр һәм кадимчеләрнең Россия дәүләте мөселманнарга каршы алып барган сәясәткә каршы берләшүеннән, уртак протест чараларыннан – петицияләр бирүдән башланып китә. Мин алда атаячак 1905 елгы күмәк гаризаларда урын алган таләпләрнең күбесе шул елларда ук хөкүмәткә адреслана.

Мәҗлесләрдә петициянең соңгы вариантын раслаганда мөселманнар күпчелек тарафыннан кабул ителгән карар белән килешкәннәр, чөнки максат – гадел кануннар кабул итү һәм хөкүмәтнең дини-милли сәясәтен либераль якка үзгәртү була. Кадимчеләр дә, җәдитчеләр дә эчке үсешкә тискәре йогынты ясаучы тышкы көчләргә каршы берләшәләр.

Чыганакларны анализлау, Казан шәһәре татар җәмгыяте җыелышында 28 гыйнвар датасы белән кабул ителгән петиция тексты төрле сәяси ориентирлы шәхесләрнең үзара бәхәсләрен, фикер тартышын шәрехләргә, лидерлык өчен көрәшне күзалларга мөмкинлек бирә.

Петиция төзүгә багышланган мәҗлесләр башта сәүдәгәр Әхмәтҗан Сәйдәшев өендә, аннары Әхмәт бай Хөсәенев йортында дәвам иткән. Әйтергә кирәк, шәһәр байлары өйләрендә булган мәҗлесләрдә Гаяз Исхакый җитәкчелегендәге яшьләр үзләренә күрә «инкыйлаб» ясыйлар, моңарчы татарлар арасында «Казан губернаторы» дип дан алган сәүдәгәр Әхмәтҗан Сәйдәшевне кысрыклап, мәҗлестә рәислек итүне һәм инициативаны үз кулларына алалар. Бу хәл Казанда иҗтимагый мәйданга рус уку йортларында һәм чит

илдә төпле белем алган яңа буын төбәк лидерлары чыкканлыгы турында сөйли.

Шушы мәҗлесләрдә актив катнашкан Гаяз Исхакый истәлекләрендә бу вакыйгалар шактый тулы тасвирлана: «Хәзерләйн программалары гаять сабит *(даими)*. Безем динемезә докулынмасындан башка һичбер сәяси мәталиб юк иде вә падишаһә сәдакатьләр юлламадан гыйбарәт иде. Без кәнде сәяси программамызы каршы куйдык. Сәяси хокуклар алынмасыны иләри сөрдек. Вә һәйәткә рәис уларак адвокат Сәедгәрәй Алкинны, әгъзалыклара тәрәккыйпәрвәр әгъзалар тәклиф итдек. Мәҗлес аллак-юллак улды. Һичбер карарә багланмадан, икенче һәфтә Әхмәд бай Хөсәеневнең өйендә тупланмак өчен дагылды. Икенче мәҗлесдә тәрәккыйпәрвәрләр таләп иде. Без һәйәтең рәислегенә – Сәедгәрәй Алкинны, әгъзалыкка Йосыф Акчура бәйне кабул ителде. Вә анлара хәкүмәткә язылачак петицияне хәзерләмәйне төүзыйк итдек» [Исхаков, 2013, 398 б.].

Күмәкләп кабул ителгән гариза өч өлештән тора. 9 пункттан гыйбарәт беренче өлештә сүз илдә мөселманнарның дини хокукларын киңәйтү, ислам дине институтларының православие дине институтлары белән тигез хокуклы булуын тәэмин итү, шул исәптән, муллаларның хокукларын православие руханилары белән тигезләү, мөселман дини китапларына цензураны башка дини китапларны тикшергән кебек бертөрле итү, иң мөһиме – дини-мәдәни автономияне киңәйтү һәм ныгыту – хакимиятнең 1870–1890 еллардагы һөҗүме нәтиҗәсендә югалган позицияләрне кире кайтару; мөфтине һәм казыйларны руханилар арасыннан сайлап билгеләү, мәктәп-мәдрәсәләрне һәм уку-укыту эшләрен, никахлашу, аерылышуларны, мирас һәм милек бүлүне, мөселман руханиларын билгеләүне, мәчетләр төзүне, вакыфларга күзәтчелек итүне һ.б. дини тормыш белән бәйле булган гамәлләрнең барысын да Мәхкамәи шәргыя Ырынбургыяга тапшыру турында бара. Шулай ук 1891 елда мөселман руханилар вазифаларын алырга теләүчеләр өчен кертелгән мәҗбүри русча укый-яза белү турындагы канунны, ата-анасы махсус ташлап киткән яки табылган кечкенә балаларны, шул исәптән мөселманнар яшәгән торак пунктларында, христиан итеп яздыру тәртибен юкка чыгаруны, цензор тарафыннан Корьән текстларын төзәтү очракларын булдырмауны, мөселманлыкка кайткан татар керәшеннәренә дин иреге бирүне сорыйлар.

Казан татар җәмгыятенең петициясендә шушы 9 пункттан торган таләпләрне санап үткәннән соң, документта җәдитчеләр тара-

фыннан тәкъдим ителгән пунктлар урнаша. Алар Идел-Урал төбәгендә көн итүче мөселманнарга илдә яшәүче башка халыкларныкы кебек туган телләрендә газета-журналлар бастыру хокукын бирүне, шулай ук татар телендә укытыла торган дөньяви гомум белем һәм профессия бирүче мәктәпләр ачуны көн таләбе итеп күрсәтәләр [Загидуллин, 2015, с.54–59].

Инде дин һәм белем алу өлкәләренә кагылган тәкъдимнәрдән соң, үзләренең рус ватандашлары белән чагыштырганда кимсетелгән хәлдә булуларына мисал итеп Төркестанда христиан булмаган кешеләргә күчемсез милекне хосусыйлаштыруны тыю, сату-алуда һәм иҗтимагый эшләрдә кыенлыклар тудыруны китерәләр. Соңгысы гражданлык хокукларын киңәйтү белән бәйле таләп, ул Г.Исхакый җитәкчелегендәге яшьләр тәкъдиме белән кабул ителгән дип уйларга нигез бар.

Әлбәттә, өстәмә чыганаклар булмаганда петицияләрне кайсы очракта җәдитчеләр, кайсы очракта кадимчеләр язганын аеру мөмкин түгел. XX гасыр башында җәдитчелек фикеренең таралу урыны шәһәр җәмгыятьләре булуын исәпкә алып, без шәһәрләрдән килгән петицияләрне тәгаен җәдитчеләр төзегән документлар дип әйтә алабыз. Ләкин күпчелек күмәк гаризалар авыл җәмгыятьләрендә һәм мәхәлләләрдә төзелгән.

Казан мәҗлесләрендә депутатлар итеп сайланган сәүдәгәр Әхмәтҗан Сәйдәшев, адвокат Сәедгәрәй Алкин, Йосыф Акчура, мулла Габдулла Апанаев 1905 елның 23 мартында премьер-министр С.Ю.Виттега беренче петициянең дәвамы буларак тапшырган яңа гаризаны зур тизлек белән сәясәткә кереп баручы Казан җәдитчеләре төркеме тарафыннан төзелгән документ дип бәяләп була. Гариза тулысынча мөселманнарның гражданлык хокукларын анализлауга багышланган һәм хөкүмәт алдына милли һәм дини изүне туктату мәсьәләсен шактый кыю куя. Депутация 1870 елның 26 мартында кабул ителгән «Россиядә яшәүче инородецларга белем бирү буенча чаралар кагыйдәләре» исемле канунда кардәшләрен «инородец» дип атауны рәсми рәвештә уку-язу традицияләре булмаган халыклар белән янәшә кую һәм кимсетү дип бәяли. Алар дәүләтнең мөселманнарны җәберләүче милли сәясәтен шулай ук шәһәр думасы әгъзаларның 4/5 христианнардан торуында, юридик белемле дин кардәшләрен мәхкамәләргә присяжный поверенный итеп эчке эшләр министры рөхсәте белән билгеләнә алуда, башлангыч мәктәп укытучысының христиан балаларына дәрес бирергә хо-

кукы булмауда күрәләр. Аларның хатын-кыз гимназияләре һәм прогимназияләрендә попечительләр советы әгъзалары була алмауларын, Казан университеты студентларының, мөселман булу сәбәпле, стипендия белән тәэмин ителмәү очракларын, яңа мәктәпне фәкать үз хисапларына рус сыйныфы тотарга риза булган очракта ачулары хакында язалар. Беренче петициядәге кебек, матбугат иреге бирүне, мөселманнарга Төркестанда күчемсез милек сатып алырга рөхсәт итүне сорыйлар. Мөселманнарның башка халыклар кебек дәүләт тормышында катнашырга теләүләрен, моның төп шарты тигез хокуклылык икәнен хөкүмәтнең исенә төшерәләр [Загидуллин, 2015, с.60–63].

Татар социалистларының таләпләрен Г.Исхакый, имам Ибраһим Камалов, вак сәүдәгәр Мөхәммәтгариф Бадамшинның Чистай татар мещан җәмгыяте вәкилләре сыйфатында 1905 елның 31 мартында Министрлар комитеты рәисе белән очрашу вакытында тапшырган «гражданлык ихтыяҗлары» исемле гариза тексты буенча анализлый алабыз [Загидуллин, 2015а, 85–87]. Гомумән алганда, петиция кискен рухта язылган, императорга карата нииндидер яңгыравыклы мактау сүзләре һәм аңа берсүзсез буйсынулары хакында җөмләләр юк, алай гына да түгел, документ Россия хакимиятен татар халкының мәгариф, әдәбият һәм милли рухи үсешенә тискәре йогынты ясауда, аны мәдәни яктан артта калдыруда гаепли.

Куелган таләпләр буенча ул Казан депутациясенең икенче петициясе белән авазлаш (матбугат иреге, туган телдә укыта торган дөньяви һәм һөнәр бирүче уку йортлары ачу, Төркестанда мөселманнарга күчемсез милек сатып алырга рөхсәт итү, шәһәр үзидарәләренә сайлауларда, шулай ук адвокат, табиб, китап нәшер итүче һ.б. һөнәрләр буенча эшкә урнашканда дин кардәшләрен чикләүләрне юкка чыгару). «Татар социалистлары», мәктәп сәясәтенең мөселманнар арасында рус-татар мәктәпләренә һәм мәдрәсә каршында эшләүче рус сыйныфларына, Татар укытучылар мәктәпләренә шикләнүчән мөнәсәбәт тудыруын искәртеп, дәүләтнең урыслаштыру системасын юкка чыгаруны, мәктәптән тыш белем бирү системасын булдыру максатында җәмәгать китапханәләре һәм уку заллары, театрлар һәм лекцияләр, төрле союзлар һәм җәмгыятьләр оештырганда вакланып тикшерүне туктатырга, казахлар яшәгән җирләрдә татарларга төпләнеп яшәү мөмкинлеге бирүне, милли китаплар белән сату иткәндә хакимият күзәтүен туктату кирәклеген таләп итәләр.

Билгеле булганча, крестьян, авыл җәмгыятьләрендә хакимият белән арадашчы булган авыл старостасыннан тыш, җәмгыять приговор нигезендә авылдашлары арасыннан бер яки ике кеше килеп чыккан төрле мәшәкатьләр буенча йөрүче вәкилләр итеп сайланган. Гадәттә, аларның һич югы берсе русча яхшы сөйләшә һәм укый-яза белгән, авылда андый кеше булмаса, татарча укый-яза торган шәхесне билгеләгәннәр. Төбәкләрдә петиция бирү сүзләре таралгач, нәкъ менә шушы кешеләргә күмәк гариза җибәрүне йөкләгәннәр һәм чыгымнар өчен билгеле күләмдә җәмәгать акчасы биргәннәр. Кайбер очракларда махсус вәкилләр сайлаганнар. 1905 елга кадәр төзелгән күмәк гаризаларга авыл җәмгыяте вәкиленең гариза бирергә хокукын раслаган приговор да теркәлгән. Шушы юл белән авыл җәмгыяте законга каршы килә торган гамәл кылган өчен күмәк җаваплылыкны үз өстенә алган, ягъни гариза биргән вәкилнең үзен генә мәхкамә җаваплылыгына тартып булмаган: ул фәкать җәмгыять кушканны башкаручы ролен үтәгән.

Императорның һәркемгә гариза бирергә рөхсәте мондый приговорларны кирәксезгә чыгарган. Шул сәбәпле, күп кенә петицияләр вәкилләр исеменнән язылса да, аларга җәмгыять приговорлары теркәлмәгән. Аерым кешеләргә махсус бирелгән приговорларда кайсыбер очракларда нинди мәсьәләләр буенча гариза язарга кирәклеге әйтелгән. Ләкин еш кына бу эшне авыл җәмгыяте тулысы белән элекке вәкилләргә тапшырган. Шул сәбәпле, петиция бирүдә аларның шәхси элемтәләре һәм шәһәрләрдәге таныш писарьләре зур роль уйнаган. Соңгылары өчен мондый текстлар язу табыш чыганагы икәне яхшы билгеле. Шуңа күрә, әйтик, Казан губернасы авыл җәмгыятьләре вәкилләре тарафыннан төзелгән гаризалар 2–3 төрле оригиналдан тулысы белән яки бераз үзгәртеп язылган текстлардан гыйбарәт.

Әйтик, югарыда анализланган «1905 ел, 28 январь» датасы куелган Казан шәһәре җәмгыятенең петициясе тексты Казан губернасында март азагы – апрель башында төзелгән 4 гаризада [РДТА, 821 ф., 10 тасв., 15 эш, 48 –58, 300–317, 322–330 б.] чагылыш таба. Шуларның икесендә[2] аның тулы тексты бирелгән, берсендә 4-нче пункт (вакыфларны Мәхкамәи шәргыя Ырынбургыя күзәтчелегенә

---

[2] 27 кеше, шул исәптән берничә мулла кул куйган Мамадыш өязе Әсән-Елга һәм Иске-Юмья волосте мөселманнарының уртак петициясе һәм Чистай өязе Иске Әлмәт волостенең Яңа Әлмәт авылы җәмгыятенең күмәк гаризасы.

бирү турында)[3] төшереп калдырылган, тагын берсендә 6-нчы пунктны (мөселманлыккка кайткан татар-керәшеннәргә дин иреге бирү хакында) вәкилләр бераз үзгәртеп, өстәп язганнар[4].

Казан шәһәре җәмгыяте петициясенең югарыда санап үтелгән беренче өлешендәге пунктлар авыл җәмгыятьләренең күпчелек петицияләрендә урын алган дияргә була. Әлбәттә, һәр очракта да нәкъ менә шушы документны өлге итеп алып, аның тексты нигезендә эшләнгән дигән сүз түгел, ләкин мондый ихтимал хакыйкатькә якын тора.

Сүзебезне берничә мисал белән беркетәбез. Бер төркем күмәк гаризаларда һәр үтенечне бит уртасына рим саннары куеп бер үк почерк белән язганнар. Кульязма петицияләрне анализлау шундый нәтиҗә бирде: аларны Чистай өязе Иске Әлмәт волосте Кулбай Мораса авылы вәкиле Зыятдин Сәйфуллин күчереп язган. Авыл җәмгыяте 15 март көнне аңа петиция язу һәм аны авыл халкы исеменнән тиешле адреска җибәрү хокукы белән приговор биргән. Бер көн элек, 14 мартта, шул ук волостькә караган Корналы Әмзи авылы җәмгыяте авылдашлары Гата Галимовка һәм Спасс өязенең Матак волостенә караган Исәнбай Карамалы авыл җәмгыяте Мөхәммәтҗан Фәхретдиновка биргән приговорлар нигезендә, бу вәкилләргә текстларны Зыятдин Сәйфуллин күчергән. Ләкин документта З.Сәйфуллин үзе күчергәнен язып тормаган, җәмгыять вәкилләре дә кул куймаган. Фәкать петицияләргә беркетелгән приговорлар гына аларның вәкаләтен раслый [РДТА, 821 ф., 10 тасв., 15 эш, 296–299]. Баштарак күчерелгән берничә петициядә З.Сәйфуллин бу ялгышын кабатлый, әле кайберләрендә дата куярга оныткан. Күрәсең, бу эшләрне вәкилләр үзләре башкарырга тиеш булган, ләкин, эшне беткәнгә санап, почта бүлекчәсе аша хатларын императорга адреслаганнар. (Чынлыкта, крестьяннарның рәсми язу-сызу өлкәсендә тәҗрибәләре аз булу сәбәпле, мондый эшләр күчереп язучы арадашлыгында яки аның катнашында башкарылган. – *И.З.*). Әйтик, ул үзе вәкил буларак биргән гаризага кул куйган (ләкин кайсы губернадан икәнен язарга һәм датаны язарга оныткан, бу фактлар З. Сәйфуллинның күчереп язучы һөнәрен үзләштереп килүче генә булганына ишарәли, аның гаризасы императорның га-

---

[3] Чистай өязе Иске Әлмәт волостенең Яңа Әмзә авылы җәмгыятенең күмәк гаризасы.

[4] Чистай өязе Яңа Әлмәт авылы җәмгыятенең күмәк гаризасы.

ризалар кабул итү канцеляриясенә почта белән 26 мартта килеп җиткән) [РДТА, 821 ф., 10 тасв., 15 эш, 291–292 б.]. Писарь буларак күчереп язган башка петицияләргә ул үзенең исемен «күчереп язучы» дип теркәгән. Кайбер гаризаларда авыл вәкилләренең имзалары яки, язу белмәгәнлектән, алар өчен башка кеше имзасы бар.

Спасс өязенә кергән Урта Әлки (6 апрель) һәм Тяжбердино (3 апрель) авыл җәмгыятьләре үзләренең вәкилләренә биргән приговорларында килештерелгән күмәк гаризаның биш пункты китерелгән [РДТА, 821 ф., 10 тасв., 15 эш, 73–76, 79–80 б.]. Күрәбез, апрель ае башында Спасс өязенең кайбер авылларында З.Сайфуллин күчереп яза торган вариант үзенә күрә өлге функциясен үтәгән.

Безнең исәпләүләр буенча, З.Сәйфуллин тарафыннан март аеның икенче яртысында (10 апрельгә кадәр) Чистай һәм Спасс өязләрендәге авыл җәмгыятьләре өчен кимендә 9 гариза күчерелгән, 1 майда тагын берәү язылган. Апрель аенда аның тексты буенча күмәк гаризаларны күчереп язу белән З.Текиллов исемле кеше шөгыльләнгән, ул шушы ике өяз авыл җәмгыятьләре вәкилләренә кимендә 6 петиция күчергән.

Инде килеп, З.Фәйзуллин үзе биргән петициянең эчтәлеге белән танышып үтик. Фәкать аның гаризасы алты пункттан тора. Соңгы, 6-нчы пунктта мөселман авыл җәмгыятьләрендә көн күрүче һәм инде йөз елдан артык ислам кануннары буенча яшәгән татар керәшеннәрен шундагы мәхәлләләргә беркетү кирәклеге турында язылган. Башка гаризаларда бу пункт юк. Күрәсең, авыл җәмгыятьләре, үзләренең авылларында андый татар керәшеннәре булмауны исәп алып, күмәк гаризаларына бу пуктны кертмәгәннәр. Димәк, калган биш пунктны турыдан-туры үзләренең мәнфәгатьләрен яклый дип санаганнар!

Без бу күмәк гаризаны шартлы рәвештә «З.Фәйзуллин петицияләре» дип атап, эчтәлеге белән таныштырыйк. *Беренче итеп,* аларда мөселманнарның дин өлкәсенә караган эшләрен, губерна идарәләреннән алып, фәкать Мәхкамәи шәргыя Ырынбургыя карамагына бирү турында әйтелә, бу вәкаләтләр санап үтелә: муллалар сайлау, яңа приходлар ачу, мәчетләр һәм гыйбадәт йортлары төзү, аларга руханилар билгеләү, шулай ук мөселманнарга махсус уку йортларында белем бирү мәсьәләләре. Соңгысын Халык мәгарифе министрлыгыннан Мәхкамәи шәргыя Ырынбургыя карамагына тапшыру кирәклеге искәртелә. *Икенче пунктта* муллаларны бик

кирәкле булган дин фәннәрен өйрәнүгә кыенлык китереп, күп вакытны алучы мәҗбүри рәвештә рус телен һәм язуын белү таләбеннән азат итү кирәклеге әйтелә. Хәзер мулла билгеләгәндә, беренче чиратта, аларның русча белү-белмәүләре игътибарга алынуы, ә дини гыйлемнәр икенче итеп каралуы гайре табигый хәл булarak бәяләнә һәм бу күренешкә ризасызлык белдерелә.

*Өченче итеп,* барлык Русия мөселманнарының башлыгы булган мөфтине мөселманнар үзләре сайларга тиешлеге ассызыклана. *Дүртенчедән,* муллаларның җәмгыятьтә тоткан урыннарына туры килмәгән хәрби хезмәттән азат итү сорала. Элек солдат хезмәтендә булган муллаларны соңгы мобилизация (сүз рус-япон сугышына алынган руханилар турында бара. – *И.З.*) нәтиҗәсендә күп кенә приходларның мулласыз һәм остазсыз калулары, шул сәбәпле падишаһ һәм Ватан исәнлеге өчен гыйбадәт кыла торган җәмәгать намазларыннан мәхрүм булуларына басым ясала. *Бишенче итеп,* мөселманнарның шәригать буенча никах һәм аерылышуларны руханилар карамагында калдыру, аларны гомуми гражданлык кануннарына буйсындырмау әйтелә. Үтенечнең сәбәбе итеп соңгы «Гражданлык уложениесе» проектында бу мәсьәләләр дөньяви мәхкәмәләр карамагында булачак дип язылган булуы, мондый яңалыкның Коръәнгә һәм ислам дине кануннарына каршы килүе, проект расланган очракта, мөселманнар үз диннәре кагыйдәләреннән ваз кичәргә мәҗбүр ителәчәге искәртелә.

Җәдитчеләр һәм кадимчеләр тарафыннан төзелгән күмәк гаризаларның уртак яклары күп булу берничә сәбәп белән аңлатыла. Беренчедән, бүленеш шактый шартлы, кадимчеләр, яңарышка ияреп яки хакимиятнең яңа таләпләренә буйсынып, кайбер яңалыкларны кабул итәргә мәҗбүр булалар. Бигрәк тә инкыйлаб елларында мондый «күчешләр» еш күзәтелә.

Икенчедән, аерым сословие вәкилләренең гаризаларында чагылыш тапкан матди һәм социаль мәсьәләләргә кагылышлы күмәк гаризалар җәдитчеләр өчен дә, кадимчеләр өчен дә уртак әзерләнгән.

Өченчедән, 1905 елның 10–15 апрель көннәрендә Уфада, җәдитчеләр җитәкләгән Мәхкамәи шәргыя Ырынбургыяда уздырылган голәмәләр мәҗлесе тарафыннан әзерләнгән дини идарәнең яңа уставы проекты эшләнгәч, андагы кайбер фикерләр ике төркем тарафдарларының да гаризаларында чагылыш таба.

Дүртенчедән, төбәкләрдә язылган күпчелек гаризалар берберсенә охшаш, чөнки күчереп язылган.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: төгәл генә гариза язучыларның яки кул куючыларның кайсылары кадимче, кайсылары җәдитче икәнен аеру кыен. Шулай да, кадимчеләр тарафыннан язылган петицияләрнең эчтәлеген узган гасырның 90-нчы елларында хөкүмәт мөселманнар милли-мәдәни автономиясен җимерү ниятеннән кабул иткән карарларны юкка чыгаруны сорап язган үтенечләрнең яңа редакциясе тәшкил итә, дигән фикер әйтергә мөмкин. Яңалык буларак, аларда дини идарәнең һәм руханиларның хокукларын киңәйтү, дин иреге бирү мәсьәләләре күтәрелә. Кадимчеләрнең дөньяви белемнәре, бигрәк тә русча уку-яза белүләре чамалы булу сәбәпле, петицияләрендә, беренче чиратта, ислам диненә кагылышлы, шулай ук татар керәшеннәренә дин иреге бирү проблемалары чагылыш тапкан.

Бу үтенечләр җәдитчеләрнең петицияләрендә дә кабатлана. Ләкин, кадимчеләрдән аермалы буларак, җәдитчеләр милләтнең алгарышын тәэмин итүне кайгыртканнар, вакытлы матбугат булдыру, туган телдә укытып дөньяви гыйлем һәм һөнәрләр бирә торган уку йортлары ачу, шул рәвешле белемле яңа буын тәрбияләп, милләтне алга җибәрү турында хыялланганнар. Аларның күз уңыннан мөселманнарның рус җәмгыятендәге тормышы, гражданлык хокуклары турындагы катлаулы мәсьәләләр дә читтә калмаган. Казан татар җәмгыяте петициясе төзү мисалында күренгәнчә, мөселманнарның ил күләмендә гражданлык хокукларын якларга кирәклекне беренче булып татар социалистлары куйган, һәм аларның тәкъдимнәре инкыйлаб йогынтысында, җәдитче либераллар төзегән петицияләрдә чагылыш тапкан. Җәдитче-либераллар гаризаларында мөселманнарның гражданлык хокуклары (сүз иреге, җыеннар иреге, вөҗдан иреге) турында кайгырту әйдәп бара.

Ике як өчен дә уртак булган тагын ике сыйфатны атап китү мөһим. Беренчесе, җәдитчеләрнең канун алдында һәркемнең тигезлеге турында сөйләүләренең нигезендә Россиядә сословиеләрне юкка чыгару турындагы фикер ята. Чөнки канун алдында берәүләрнең өстенлекле булуы кешеләрне сословияләргә бүлүдән һәм гражданлык җәмгыяте булмаудан килеп чыккан. Бер үк вакытта, алар мөселман руханиларына православие дине руханилары кебек тигез хокуклар бирүне, шул исәптән армия хезмәтеннән азат итүне сорыйлар. Бу очракта сүз руханилар өчен аерым сословие өстенлекләрен саклап калу турында бара. Икенчедән, петицияләрдән ике төркем вәкилләренең

дә, гомумиләштереп әйтсәк, барлык гариза бирүчеләрнең дә хакимияткә карата оппозициядә торулары ачыклана.

## ӘДӘБИЯТ

1. Загидуллин И.К., Хамитбаева Н.С. «Татарские социалисты» в петиционной кампании мусульман России 1905 года // Из истории и культуры народов Среднего Поволжья. Казань, 2015. № 5. С.72–95.

2. Загидуллин И.К. Петиции мусульман Казани 1905 г. // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2015. №1/2. С.46–63.

3. Ибраһимов Г. Татарлар арасында революцион хәрәкәтләр // Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. 7 т. Тарихи хезмәтләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 241–435 б.

4. Исхаков М.Г. Тәрҗемәи хәлем // Исхаков М.Г. Әсәрләр. Унбиш томда. 14 т.: Хатлар һәм автобиографик язмалар (1902–1954). Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 363–405 б.

5. РДТА, 821 ф., 10 тасв., 15 эш.

**Кыскартылган сүзләр**

РДТА – Россия дәүләт тарих архивы.

**И.К. Загидуллин**

## Отражение взглядов джадидистов и традиционалистов в петициях мусульман, адресованных в 1905 г. из Казанской губернии правительству

*Аннотация.* В статье представлена методика определения принадлежности петиций джадидистам или традиционалистам, принимавшим участие в петиционной кампании мусульман Волго-Уральского региона 1905 года.

*Ключевые слова:* джадидист, кадимист, либералы, социалисты-революционеры, петиции.

**I.K. Zagidullin**

## To reflect the views of jadidists and traditionalists in the petitions of muslims, addressed in 1905 year from the Kazan province to the government

*Annotation.* The article presents a method of determining the accessories of petitions to jadidists or traditionalists who participated in company's petition of muslims of the Volga-Ural region in 1905 year.

*Keywords:* jadidist, kadimist, liberals, social-revolutionaries, the petitions.

**Автор турында мәгълүмат**

**Заһидуллин Илдус Котдус улы** – тарих фәннәре докторы, ТР ФА Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты яңа тарих бүлегенең мөдире (Казан шәһәре); e-mail: zagik63@mail.ru

**Загидуллин Ильдус Котдусович** – доктор исторических наук, заведующий отделом новой истории Института истории им. Ш.Марджани АН РТ (г.Казань).

**Zagidullin Ildus Kotdusovich** – the doctor of historical sciences, the head of the Department of modern history of Sh.Marjani Institute of History of AS RT (Kazan).

УДК 930.2

**И.А. Мөстәкыймов**

# «ГАЛИ ХАН»МЫ, «ИЛҺАМ ХАН»МЫ, «ӘДҺӘМ ХАН»МЫ?

*Аннотация.* Мәкаләдә XV гасырның соңгы чирегендә хөкем сөргән бер Казан ханының төрки һәм рус телләрендәге чыганакларда исеме язылышы вариантлары өйрәнелә. Мәсьәләне ачыклау өчен яңа чыганаклар җәлеп ителә.

*Ачкыч сүзләр:* Казан ханлыгы, чыганакларны өйрәнү фәне, төрки телләрендәге чыганаклар, татар тарихы.

Мәхмүтәк хан улы Ибраһим хан вафатыннан соң 1479–1484 һәм 1485–1487 елларда Казан тәхетен биләгән улының исеме рус чыганакларында *Алегам~Алехам~Аляхам~Алегем* дип китерелә[5]. Бу ханның исеме тарихи хезмәтләрдә дә төрлечә языла.

Озак вакыт ул исемнең татарча язылышы һәм әйтелеше хакында бәхәс барган иде: галимнәрнең бер өлеше «Алегам» исемен «Гали~Али» исеме һәм «хан» титулының кушып язылуыннан барлыкка килгән сүз дип тәгъбир итсә, тарихчыларның икенче өлеше ул ханның хакыйкый исеме «Илһам» дигән фикердә торды. Соңгы елларда икенче фикер өстенлек алды[6].

Чыннан да, безнең төбәктә төзелгән, XVII–XIX йөзләргә караган төрки-татар тарихнамәләрендә Ибраһим хан белән Мөхәммәд-Әмин хан хөкемдарлыгы арасында Казан тәхетен биләгән ханның исеме الهام خان «Илһам хан» дип күрсәтелә [Ivanics, Usmanov, 2002, S. 91; Рахим, 2008, 142, 144, 180 б.; Мустакимов, 2008, 154 б.; Мирастан, 2011, 91, 294 б.]. Мәсьәлә хәл ителгән шикелле.

Ләкин XVI йөз башында Мавәраэннәһердә үзбәк[7] хөкемдары Мөхәммәд-Шәйбани хан катнашында төзелгән «Тәварихы гөзидәи

---

[5] Кара: [Вельяминов-Зернов, 1863, 158–175 б.].

[6] Мәсәлән, бу язылыш Татар энциклопедясендә кабул ителде [Татарская, 2005, 555 б.].

[7] «Үзбәкләр» дип XIV гасырның икенче яртысында – XVI гасырда (кайбер очракларда соңрак та) фарсы һәм төрки чыганакларда Дәште Кыпчакта, аеруча Дәште Кыпчакның Көнчыгыш өлешендә яшәгән һәм Чыңгыз ханның олы улы Җүчы нәселеннән булган хөкемдарларның кулы астындагы күчмә төрки кабиләләрне атаганнар. Иранлы автор Фазлулла

носрәтнамә» исемле аноним тарихнамәдә (хроникада), Чыңгызыйларның нәсәпләрен тасвирлауга багышланган һәм фәндә шактый ышанычлы санала торган бүлектә, югарыда телгә алынган Казан хөкемдарының исеме ادهم خان «Әдһәм хан» дип күрсәтелгән [BL, Or. 3222, f. 73a; Таварих, 1969, 40 б.]. Өстәп түбәндәгеләрне дә әйтергә кирәк. Беренчедән, «Тәварихы гөзидәи носрәтнамә»не төзүче Илһам~Әдһәм ханның ватандашы булмаса да, замандашы булган. Икенчедән, бу тарихнамәне яздырган һәм язылуында катнашкан Мөхәммәд-Шәйбани хан белән Казан ханы Мөхәммәд-Әмин арасында шактый тыгыз мөнәсәбәтләр яшәп килгән[8]. Шуңа күрә Казан ханнарының исемнәре турындагы мәгълүматны Шәйбани хан турыдан-туры Илһам~Әдһәм ханның энесеннән – Мөхәммәд-Әмин ханнан ала алган[9].

Кайбер татар мөселман кулъязма догалыкларында Казандагы «хан мәчетенең эчендә» күмелгән «изгеләр» (вариант: «ханнар») арасында да Ибраһим ханнан соң Әдһәм хан исеменең очравы игътибарны җәлеп итә: «1) Габдулла хан; 2) Хәлил хан; 3) Ибраһим хан; 4) Әдһәм хан; 5) Габдеррахман хан; 6) Сахиб-Гәрәй хан; 7) Сафа-Гәрәй хан; 8) Үтәш хан; 9) Йад-Гәрәй хан; 10) Шәех Касыйм хан; 11) Шәех Раббани хан; берсенең исеме мәгълүм түгел».

Бу исемлекне без Совет чорына (якынча 1940–1970 елларга) караган ике кулъязмада очраттык [ТРМК КСКБ, 2076т, 1а кгз; 2077т, 7а кгз.]. Күрсәтелгән исемлек революциягә кадәрге Россиянең берәр татар басмаханәсендә дөнья күргән дини эчтәлекле бер китаптан алынганга охшый, фәкать әлегә ул китапның исемен

---

бине Рузбиһан Исфаһани XVI гасыр башында «Миһманнамәи Бохара» исемле әсәрендә үзбәкләргә өч кабиләнең нисбәт ителгәнен әйтә: «Шулардан [берсе] – шыбанилар, [Мөхәммәд-Шәйбани] хан хәзрәтләре боларның... хөкемдары. Икенче кабилә – казакълар… өченче кабилә – маңгытлар (нугайлар. – *И.М.*)...» [Фазлаллах, 1976, 62 б.].

[8] Бу турыда кара: [Мустакимов, 2013, С. 34].

[9] Мондый ихтималның зур булуын күздә тоткан очракта «Тәварихы гөзидә»дә Ибраһим хан балалары арасында өч затның гына күрсәтелүе аңлашылып бетми: «Бу Ибраһим ханның өч углы бар ирде, атлары Әдһәм хан, Мөхәммәд-Әмин хан, Габделлатыйф» [BL, Or. 3222, f. 73a]. Башка чыганаклардан Ибраһим ханның биш ир баласы – Фатыйма исемле хатыныннан Илһам~Әдһәм~Гали, Ходайкол, Мәлик-Таһир; Нурсолтан исемле хатыныннан Мөхәммәд-Әмин һәм Габделлатыйф исемле уллары булганы билгеле [Вельяминов-Зернов, 1863, С. 185–186; Худяков, 1991, С. 43].

ачыклый алмадык. Басма китапка исә бу исемлек Казан татарлары арасында таралган кулъязмалардан кергән булса кирәк. Күрәбез ки, Казан ханнарының шушы исемлегендә башка чыганакларда Казан хөкемдары буларак күрсәтелмәгән Габдулла хан бар[10]. Биредә беркайчан да хан булмаган, ләкин Казан халкы тарафыннан әүлия саналган Касыйм шәех һәм ниндидер Раббани шәехнең дә исемнәрен күрәбез. Аның каравы, Казанда хан булган Олуг Мөхәммәд, Мәхмүтәк, Мөхәммәд-Әмин, Мамык, Җангали, Шаһгали (боларның берничәсе Казанда җирләнгән дип уйланыла) телгә алынмаган. Берничә реаль ханның исеме бозып күрсәтелгән (Габделлатыйф урынына Габдеррахман, Үтәмеш-Гәрәй урынына Үтәш, Ядкяр урынына Йад-Гәрәй). Бу исемлектә телгә алынган шәхесләрнең кайберләре – Россиядә тоткынлыкта үлгән Илһам ~ Әдһәм хан һәм Габделлатыйф ханнар, Кырымда хан булган чагында үтерелгән Сахиб-Гәрәй хан, Мәскәүдә үлгән Үтәмеш-Гәрәй һәм Ядкяр ханнар һ.б. – Казанда җирләнмәгәннәр. Бәс, «хан мәчетендә күмелгән ханнар исемлеге» никадәр хаталы булуга карамастан, XVI гасыр башында төзелгән «Тәварихы гөзидәи носрәтнамә»дәге кебек үк, бу исемлектә дә «Әдһәм» язылышының кулланылуы дикъкатьне җәлеп итә.

Шулай итеп, «Илһам» укылышы һәм язылышы файдасына аның берничә җирле татар чыганагында очравы һәм русча «Алегам» әйтелеше белән аваздашлыгы булса, «Әдһәм» укылышының һәм язылышының файдасына аның Илһам~Әдһәм ханның мәгълүматлы замандашы – «Тәварихы гөзидәи носрәтнамә» авторы тарафыннан телгә алынуы һәм шушы «Тәварихы гөзидә» белән бәйләнеше булмаган бер соңрак заман татар чыганагында – «хан мәчетендә күмелгән ханнар исемлеге»ндә – кулланылуы сөйли.

Безгә калса, Мөхәммәд-Әмин хан алдыннан хакимлек иткән ханның исеме «Илһам» булырга тиеш. Моңа бер яктан Идел-Уралда XVII–XIX йөзләрдә төзелгән һәм башка Казан ханнарының исемнәрен һәм аларның тәхеттә эзлеклелеген шактый төгәл биргән тарихнамәләр, икенче яктан, XV йөзгә караган берничә рус чыганакларының бу ханның исемен бер рәвештәрәк бирүләре ишарә итә. Алай да, мәгълүм Казан ханы исеменә килгәндә, аның «Әдһәм»

[10] Бу шәхес «Дәфтәре Чыңгызнамә»дә һәм кайбер тәварих вә риваятьләрдә Аксак Тимер тарафыннан үтерелгән «Болгар ханы» буларак күрсәтелгән легендар (яки ярымлегендар) зат булса кирәк.

варианты «Илһам» исеменең бозылып әйтелүеннән яки укылуыннан килә, дип уйлыйбыз. Беренчедән, الهام خان«Илһам хан» язылышы XVII йөзгә караган һәм Казан ханлыгы хәлләреннән шактый хәбәрдар «Дәфтәре Чыңгызнамә» тарихнамәсендә кулланыла. Икенчедән, «Илһам» (الهام) һәм «Әдһәм» (ادهم) исемнәренең әйтелешендә / язылышында беркадәр аваздашлык / охшашлык бар, бу исә чыганакларны төзүче / күчерүчеләрне саташтыра алган.

## ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ ӘДӘБИЯТ


1. Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. Ч. 1. СПб., 1863.

2. Мирастан биш сәхифә / Төз. С. Гыйләҗетдинов. Казан, 2011.

3. Мустакимов И. Термин «Золотой престол» в Поволжье по данным арабографичных источников. (К вопросу о статусе г. Булгара на ордынском и постордынском пространстве) // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2008. № 1.

4. Мустакимов И.А. Еще раз о казанском ярлыке хана Сахиб-Гирея // Средневековые тюрко-татарские государства. Сб. статей. Вып. 5. Казань, 2013.

5. Рахим А. Новые списки татарских летописей // Гали Рәхим: Тарихи-биографик җыентык. Казан, 2008.

6. Таварих-и гузида-йи нусрат-наме // Материалы по истории казахских ханств XV–XVIII вв. Алма-Ата, 1969.

7. Татарская энциклопедия. Т. 2. Казань, 2005.

8. Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 2076т шифрлы кульязма.

9. Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 2077т шифрлы кульязма.

10. Фазлаллах ибн Рузбихан Исфахани. Михман-наме-йи Бухара (Записки бухарского гостя) / Перев., предисл. и примеч. Р.П.Джалиловой. М., 1976.

11. Худяков М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. М., 1991.

12. British Library, manuscript Or. 3222.

13. Ivanics M., Usmanov M.A. Das Buch der Dschingis-Legende (Daftar-i Čingiz-nāma). Szeged: Univ. of Szeged, 2002. [Bd.] I.


### Кыскартылган сүзләр

ТРМК КСКБ, 2076т – Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 2076т шифрлы кульязма.

ТРМК КСКБ, 2077т – Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 2077т шифрлы кульязма.

**И.А. Мустакимов**

**Али-хан, Ильгам-хан или Адгам-хан?**

*Аннотация.* В статье рассматриваются варианты написания имени одного из казанских ханов последней четверти XV в. в тюркоязычных и русских источниках. Для выяснения вопроса привлекаются новые источники.

*Ключевые слова:* Казанское ханство, источниковедение, тюркоязычные источники, история татар.

**I.A. Mustakimov**

**Ali khan, Ilham khan, or Adham khan?**

*Annotation.* The paper discusses options for writing the name of one of the Kazan khans the last quarter of 15th century in Turkic and Russian sources. The new sources to clarify the issue attracted.

*Keywords:* Kazan Khanate, source studies, Turkic sources, history of Tatars.

**Автор турында мәгълүмат**

**Мөстәкыймов Ильяс Альфред улы** – тарих фәннәре кандидаты, ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе архив документларын гыйльми файдалану һәм халыкара элемтәләр секторы мөдире (Казан шәһәре); e-mail: imus@rambler.ru

**Мустакимов Ильяс Альфредович** – кандидат исторических наук, заведующий сектором научного использования архивных документов и международных связей Главного архивного управления при Кабинете Министров РТ (г.Казань).

**Mustakimov Ilyas Alfredovich** – candidate of historical sciences, chief of the Department for archival documents publishing, exhibitions and exterior relations, General Archival Department under the Cabinet of Ministers of the Republic of Tatarstan (Kazan).

УДК 930

**Э.К. Сәлахова**

# БЕРЕНЧЕ БӨТЕНДӨНЬЯ СУГЫШЫ ФРОНТЛАРЫННАН ЯЗЫЛГАН ТАТАР СОЛДАТЛАРЫ ХАТЛАРЫН ӨЙРӘНҮ ТӘҖРИБӘСЕ ҺӘМ ПРОБЛЕМАЛАР

*Аннотация.* Беренче бөтендөнья сугышы фронтларыннан, хәрби госпитальләрдән язылган солдат хатлары, аларга туган җирләреннән килгән җавап хатлары, хәрби әсирләрнең хатлары мөһим һәм аз билгеле булган чыганаклардан исәпләнелә. Алар сугыш чынбарлыгын гади кеше күзләре белән күрергә мөмкинлек бирә. Әлеге тикшерү эше солдат хатларын анализлауга багышланган. Авторның төп игътибары бүгенге көндә фәнни әйләнешкә кермәгән гарәп графикасы белән язылган татарча хатларга бирелә.

*Ачкыч сүзләр:* Беренче бөтендөнья сугышы, тарихи чыганаклар, солдат хатлары, кульязмалар, тарихи чыганакларны анализлау.

Кешелек дөньясы тарихы күпсанлы сугышлардан тора, ил тарихының кайсы гына чорын алып карасаң да, бер кеше гомеренә хәтта берничә зур сугыш туры килгән. XX йөз башында гына да Россия империясе катнашында барган бер-бер артлы, хәтта ки, вакыты ягыннан бер-берсенә тоташып киткән сугышлар булган. Татар тарихында да аларның эзе тирән. Армиягә дип чыгып киткән татар кешесе бу сугышлар нәтиҗәсендә бер фронттан икенче фронтка килеп эләккән.

Еш кына сугыш тәмамлану белән белән аны оныту гадәте бар. Күп очракта аның аерым детальләре тикшерелми, ул максат итеп тә куелмый. Татар тарихына да тирән яра салган Беренче бөтендөнья сугышы шундый афәтләрдән була. Аның турында бары тик 100 ел узганнан соң, юбилей мөнәсәбәте илә генә телгә алдылар, конференцияләр узды, кайбер басмалар дөнья күрде [Татарский народ, 2014; Гилязов, Гатауллина, 2014; Габдрафикова, Абдуллин, 2015], ләкин бу сугышның татар җәмгыятендәге ролен аерым тикшерү таләп ителә. Татарлар тарафыннан «Зур сугыш», «Герман сугышы», «Аурупа сугышы» дип аталган бу вакыйганың кайтавазы хәзерге көннәргә кадәр сузыла. Бу сугышта күпме татар кешесенең язмышы хәл ителде, өзелгән гомерләрнең нәселе киселде. Бу афәтнең чынбарлыгын, аның татар җәмгыятенә китергән кайгы-

хәсрәтен, казаларын өйрәнү өчен төп чыганаклар булып XX йөз башында нәшер ителгән татар газеталары, татар солдатлары язган хатлар тора. Вакыйганы эчке яктан күрсәтүче тагын бер алыштыргысыз, гаять кыйммәтле чыганак – бәет һәм мөнәҗәтләр. Соңгылары «Татар халык иҗаты» томнарының бәетләр бүлегендә тупланган [Татар халык иҗаты, 1983]. Аталган беренче ике чыганак бу сугышны өйрәнүче хәзерге заман галим-тарихчыларына, кызганыч ки, «теш үтмәслек» чыганак булып кала бирә. Татарларның бу сугыштагы ролен, аларның кичереш-халәтләрен мондый чыганакларны өйрәнми, аларны анализламый, кулланмый ниндидер нәтиҗәләр ясау мөмкин түгел. Бу хилафлылыкны булдырмас өчен гарәп графикасындагы текстлар белән, шул исәптән, кульязма текстлар белән эш итүче әзерлекле тарихчы-галимнәр кытлыгы хәзерге көндә актуаль проблема булып кала бирә.

Татар газетлары сугышның башыннан ахырына кадәр вакыйгаларны яктырткан зур мәкаләләр биреп барган. Газета битләрендә аналитик мәкаләләр дә дөнья күргән. Алар нигезендә татар җәмгыятенең Беренче бөтендөнья сугышын ничек кабул итүе, бу шартлардагы яшәешенең тулы картинасын ачып бирү мөмкин.

Бу мәкаләдә тикшерү объекты буларак татар солдатларының фронт сызыгының төрле җирләреннән, госпитальдән язган хатлары, туганнарының җавап хатлары торганлыктан, игътибар эпистоляр җанрдагы чыганакларга биреләчәк.

Татар солдатларын бүгенге көнгә сакланып калган хатларының берничә төре бар: оригинал хатлар [КФУ, ФК, кульязма һәм сирәк китаплар бүлеге, 1613 т, 1637 т, 1672 т, 1701 т, 2435 т, 4425 т, 4772 т, 4840 т, 4876 т, 4907 т, 5666 т, 5670 т, 5832 т, 5833 т], жандармия фондларында сакланган татар хатларына цензор тасвирламалары [ТР МА, 1154 ф., 1 тасв., 238, 239, 338 эш]. Шулай ук хатларның кайбер өзекләре мөнәҗәт һәм бәетләрдә теркәлгән [Яурупа сугышы бәете, 1914; «Без плиндә..., 2014].

Беренче бөтендөнья сугышы солдат хатларының зур коллекциясе Казан университеты китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана. Анда иң зур өлешне урыс телендәге хатлар тәшкил итә [КФУ, ФК, КСКБ, 777 сакл. бер], шулай ук чуаш һәм татар телендәге хатлар саклана. Әсирләр тарафыннан язылган Аурупа телләрендәге хатлар да бар. Өйрәнелү ягыннан караганда, урыс телле хатларның шактый өлеше матбугатта басылды [Шарангина Н.А., 1998, Амерханова Э.И., 2014], чуаш телендәге

мондый хатлар бөтенләй дә өйрәнелмәгән. Татар телендә гарәп хәрефләре белән язылган хатларның биредә исәбе шактый, алар барысы да Казан дәүләт университетының археографик экспедициясе эшчәнлеге нәтиҗәсендә М.Госманов һәм А.Фәтхиев тарафыннан тупланган. Аларның берсенең дә тексты матбугатта басылганы юк, бары тик сугышның юбилее уңаеннан оештырылган конференция кысаларында бу проблемага йөз тоту күзәтелде [Салахова, 2014, с. 89–96].

Китапханәдә саклanучы татар телендәге солдат хатларының хәзерге вакытта төгәл санын әйтүе авыр, чөнки алар тасвирламада барысы да, вакыты күрсәтелмичә, солдат хатлары дип кенә бирелгән. Димәк, аларның чынлап та шушы чор хатлары икәнен ачыклау һәрберсен укып чыкканнан соң гына мөмкин булачак, аларның санын да шунда гына атап булачак. Хатлар папкаларга тупланган, төрле папкада хатлар саны төрле. Кайберләрендә бер номер астында бер хат бирелсә, башка очракта бер номер астында, хәтта кырыклап хат саклана. Шундый 14 ләп саклау берәмлеге бар. Күп текстларның саклану дәрәҗәсе начар: кәгазе ертылган, карасы тонык, почеркы шактый начар. Чөнки фронт сызыгында, сугыш барган вакытта кул астында булган карандаш, кәгазьне тез өстенә куеп язылган хатлар алар.

Татар солдатларының хатлары төрле размерда, язу каралары да төрле: шәмәхә, соры карандаш белән язылган күпчелекне тәшкил итә, шунлыктан, бу хатларның текстларын укуны кыенлаштыра, чөнки карандаш вакытлар үтү белән төсен югалта, ышкыла.

Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклanган хатлар, нигездә, госпитальләрдән, яуга керүне көтеп тору халәтендә торучылар, яудан исән-имин чыгучылар тарафыннан язылган, шулай ук аларга якыннары язган җавап хатлары саклана. Шунлыктан, хатларның эчтәлегендә «яудан исән чыга алырбызны, күрешмәсәк, бәхил булыгыз» кебек җөмләләр ята. Кайбер хатларда исән калуларына шөкер итү, Ходайга рәхмәт сүзләре язылган.

Хатларның текстын өйрәнүнең нәтиҗәсе буларак, татар халкының белемле, фикерле булуын ассызыклап китәргә кирәк. Солдатка гади крестьян алынганлыгын исәпкә алсак, хатларның эчтәлеге татар крестьянының белем дәрәҗәсе яхшы булуын күрсәтә, бу үз чиратында гади авыл мәдрәсәсенең белем бирү дәрәҗәсен билгеләүче фактор.

Традицион рәвештә татар хатлары озын-озак саналган исемнәргә сәламнәр җиткерү, аларның хәер-догасын сорау белән башланып китә, бу өлеш бер биттән дә ким булмый. Шунысы кызыклы, сәламнәр туган-тумачага гына юлланмый, барлык тирә-күршеләр, дуслар искә алына. Мәчет картларын, муллаларны аерым билгеләп үтү бар. Бу, әлбәттә, татар җәмгыятенең яшәү рәвешен, мәхәллә халкының үзара мөнәсәбәтен билгели торган бер дәлил булып тора.

Татар солдатлары хатларыннан аңлашылганча, үзләре яу кырында булса да, гади крестьянның уй-фикерләре авылы тарафында [КФУ, ФК, КСКБ, 1672 т]. Фронттан язган хатларда һава торышының начар булуы, суыклар килүе, уңышка зыян салыр дип борчылулар, кышка утын әзерли алу-алмаулары белән кызыксынулары – болар барысы да шуны раслый. Ирләрнең гаиләне туендыру урынына яу кырында булуларына җаннары әрнүе күренә. Алар сугышны язмыш сынавы итеп кабул итәләр, бу сынауны сабырлык белән үтәргә тырышалар. Татарга хас булган сабырлык төшенчәсе татар солдат хатларында төп сызык булып бара.

Сугыштан язылган хатларда эмоцияләргә урын юк, ачыктан-ачык сугышны бәяләү дигән нәрсә күренми. Чөнки солдат хатлары цензор тарафыннан тикшерелгән, эчтәлеге «яраксыз» дип табылган хатлар адресантына барып та җитмәгән, бу хәлне белгән солдатлар «хәл бүгенгә шөкер» дигән тыйнак төшенчәләрдән генә файдаланган.

Хатлардан аңлашылганча, еш кына хат-хәбәрләр адресантына барып ирешмәгән, бу сугыш шартларында почтаның эшчәнлеге белән дә, шул ук вакытта цензор иләге белән дә аңлатыла. Солдатларга туганнары җибәргән акчаларның килеп ирешмәве, юлда читләрнең кесәләренә керү, яисә таланып алынуы да языла. Акча белән булса да, читтәге туганының хәлен җиңеләйтергә тырышкан якыннарына «акча җибәрмәгез, аны монда куллану урыны да юк» дип җавап салалар.

Татар хатларының эчтәлеге фронт хәлләрен күзаллау, яуга керергә әзерлек хәлендә торган солдатларның режимын, солдатларның эмоциональ кичерешләрен, гомүмән, бу сугышны ничек кабул итүләрен, аның татар тормышындагы чираттагы бер афәт булуын ачып сала [КФУ, ФК, КСКБ, 1637 т]. Татар солдаты бу шартларда татар-мөселман җәмгыятенә хас булмаган гайре табигый

нәрсәләр белән күзгә-күз очраша. Урыс азыгы саналган, буш азык булган «кәбестә шулпасы»нан башлап дуңгыз итенә кадәр – барысы да татар солдаты тарафыннан бик авыр кабул ителгән. Татар солдатларын үлемнән бигрәк, үлеменнән соң җеназасыз җирләнү куркынычы хафага салган.

Солдатларның туганнары белән язышкан хатлары аша, сугыш чорында тылдагы тормыш хәлен күзалларга мөмкинлек бар. Солдат әнисе улына язган бер хатта тылдагы солдат балаларына, хатыннарына бирелгән пособие турында тулы мәгълүмат бирә [КФУ, ФК, КСКБ. 2435 т]. Шулай ук, тылдагы кешеләрнең сугышны күз алдына китерүе, аның яу кырындагы кеше карашы белән ни дәрәҗәдә туры килү-килмәве үзе бер кызыклы аспект булып тора.

Татар хатларының күбесе мөнәҗәт, бәет белән тәмамлана. «Язып сүз бетмәс, күреп сөйләшергә калсын» дип сүзне кыска тотарга мәҗбүр булган солдат үзенең хис-кичерешен, сагышын, кайгысын нәкъ менә халык иҗаты аша ачып сала. Хатта сүз белән сөйләнмәгән моментлар бәетләрдә, мөнәҗәтләрдә сөйләнә, көйләнә.

Татар солдатлары хатлары тарихи тикшерү объекты гына булмыйча, тел галимнәрен дә җәлеп итәрлек кыйммәтле чыганаклар. Аларда хәзерге телдән төшеп калган сүз-гыйбарәләр, диалектик үзенчәлекләр саклана.

Беренче бөтендөнья сугышы чорында язылган татар солдатлары хатларын комплекслы өйрәнү фәндә актуаль проблема булып тора, аларны тикшерү төрле өлкә галимнәренең бурычы, ләкин хәзерге көндә иң беренче бурыч булып аларны саклау, өйрәнү һәм бастыру тора. Сыйфатсыз кәгазьгә тонык кара белән моннан 100 ел элек язылган хатлар өчен вакыт дигән фактор хәлиткеч булырга мөмкин. Шуңа да аларны саклау, аларга реставрация ясау, тиз арада бастырып чыгару безгә аз билгеле сугышны төрле яктан тулы итеп ачу мөмкинлеген булдыра ала.

## ӘДӘБИЯТ


1. Амерханова Э.И. Издательские шаблоны писем солдат Первой мировой войны // Эхо веков. 2014. № 1–2. С.133–142.
2. «Без плиндә ятамыз читлектәге кош кебек...»: Беренче бөтендөнья сугышы бәетләре / Төз. Мәрданов Р.Ф. Казан: Милли китап, 2014. 119 б.
3. Гилязов И., Гатауллина Л. Российские солдаты-мусульмане в германском плену в годы Первой Мировой войны (1914–1920). Казань: Тат. кн. изд-во, 2014. 303 с.

4. Казан федераль университеты Фәнни китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге (КФУ, ФК, КСКБ). 777 сакл. бер.
5. КФУ, ФК, КСКБ. 1613 т.
6. КФУ, ФК, КСКБ. 1672 т.
7. КФУ, ФК, КСКБ. 1701 т.
8. КФУ, ФК, КСКБ. 2435 т.
9. КФУ, ФК, КСКБ. 4425 т.
10. КФУ, ФК, КСКБ. 4772 т.
11. КФУ, ФК, КСКБ. 4840 т.
12. КФУ, ФК, КСКБ. 4876 т.
13. КФУ, ФК, КСКБ. 4907 т.
14. КФУ, ФК, КСКБ. 5666 т.
15. КФУ, ФК, КСКБ. 5670 т.
16. КФУ, ФК, КСКБ. 5832 т.
17. КФУ, ФК, КСКБ. 5833 т.
18. КФУ, ФК, КСКБ.1637 т.
19. Салахова Э.К. Солдатские письма: источниковедческий анализ // Татарский народ и народы Поволжья в годы Первой мировой войны. Сборник материалов Всероссийской научной конференции с международным участием, приуроченной к 100-летию начала войны (Казань, 10–11 октября 2014 г.). Казань: Институт истории им. Ш.Марджани Академии наук Республики Татарстан, 2014. С. 89–96.
20. Татар халык иҗаты. Бәетләр. Казан, 1983. 390 б.
21. Татарстан Республикасы Милли архивы (ТР МА). 1154 ф., 1 тасв., 238, 239, 338 эш.
22. Шарангина Н.А. «Солдаты смотрят на войну как на огромное несчастье»: солдатские письма с фронтов Первой мировой войны // Гасырлар авазы = Эхо веков. 1998. № 3–4. С. 177–184.
23. Яурупа сугышы бәете. Казан: Кәримовлар матбагасы, 1914. 16 б.

**Э.К. Салахова**

## Проблемы и опыт изучения писем татарских солдат с фронтов Первой мировой войны

*Аннотация.* Солдатские письма, написанные с фронтов Первой мировой войны и из военных госпиталей, письма, отправленные им на фронт с Родины, письма военнопленных, являются одним из важнейших и малоизвестных источников, которые дают возможность увидеть истинное лицо и реалии войны глазами простых людей. В данном исследовании дается источниковедческий анализ солдатским письмам. Автором делается особенный акцент письмам на татарском языке, написанным на арабской графике, которые до сегодняшнего дня остаются неизвестными научному кругу.

*Ключевые слова:* Первая мировая война, исторические источники, солдатские письма, рукописи, источниковедческий анализ.

**E.K. Salakhova**

**Problems and experience of learning the letters of the Tatar soldiers from the fronts of the First World War**

*Annotation.* Soldiers' letters written from the front and from the military hospitals, letters were sent to them from the homeland to the front, letters of prisoners of war are one of the most important and little-known sources in the history of World War I, which give the opportunity to see the true face and the reality of war to the ordinary people. In this research can see the source study of analysis of soldiers' letters. The author makes a special emphasis to the letters which are written in Arabic script, which stay unknown for the researches till nowdays.

*Keywords:* World War I, historical sources, the soldiers' letters, manuscripts, source study analysis.

**Автор турында мәгълүмат**

**Сәлахова Эльмира Кадим кызы** – тарих фәннәре кандидаты, Ш.Мәрҗани ис. Тарих институтының Татарстан халыкларының тарихи-мәдәни мирасы бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре (Казан шәһәре); e-mail: ilsalah@mail.ru

**Салахова Эльмира Кадимовна** – кандидат исторических наук, старший научный сотрудник отдела историко-культурного наследия народов РТ Института истории им. Ш.Марджани АН РТ (г.Казань).

**Salakhova Elmira Kadimovna** – candidate of historical sciences, senior researcher, Department of History and Cultural Heritage of Peoples of Tatarstan, Sh. Marjani Institute of History of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan (Kazan).

УДК 82-95"09"(470.41)

**И.Р. Тагиров**

# ОТЗЫВ О МОНОГРАФИИ АНВАРА ХАЙРИ «НОВОЕ В ПЕРЕВОДЕ НА ТАТАРСКИЙ И РУССКИЙ ЯЗЫКИ ПОВЕСТВОВАНИЯ ИБН ФАДЛАНА О ПУТЕШЕСТВИИ В БУЛГАРСКОЕ ГОСУДАРСТВО»*

Монография Анвара Хайри представляет новизну во всех отношениях. Во-первых, в ней работа Ибн Фадлана с арабского варианта переведена параллельно на два языка и с применением данных древнеуйгурского и древнетюркского языков. При этом автор проявил великолепное знание арабского языка. Во-вторых, автор подверг полномасштабному анализу все переводы этого известного сочинения, являющегося неоценимым источником для изучения быта и образа жизни многих народов. Разумеется, в первую очередь средневековых булгар.

Последнее имеет принципиальное значение в связи с созданием фонда «Возрождение», в деятельности которого булгарскому периоду нашей истории уделяется особое внимание.

Автор подверг тщательному и детальному сравнительно-сопоставительному анализу почти каждое слово сочинения Ибн Фадлана, показав как оно читалось его предшественниками и что оно означает на самом деле. Все это позволило автору выявить ошибки своих предшественников. Проделав эту сложнейшую операцию, он доказал, что Булгария – это не славянское царство, а государство тюрков, где в 922 году Ислам стал официальной религией этого государства. Он показал также, что Ислам здесь начал укореняться еще 300 лет тому назад и ко времени приезда багдадского посольст-

---

* Рецензируемая книга А.Хайри была издана в 2013 г. под названиями: «Повествование о путешествии Ахмеда Ибн Фадлана, написанное во время поездки в 921–922 годах в Булгарское государство (новое в переводе на русский язык и научных комментариях)» и «Әхмәд Ибне Фадланның 921–922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе (татар теленә яңача тәрҗемә һәм фәнни аңлатмалар)». – Прим. ред.

ва в стране имелись мечети, с минаретов которых раздавался азан. Обращение правителя Булгарии Алмыша к багдадскому халифу с просьбой прислать посольство для официального узаконения этой религии как государственной, в большей степени исходило из политических соображений.

Разумеется, величайшим недоразумением является попытка предшественников автора данного сочинения прочитать некоторые ключевые слова в произведении Ибн Фадлана, с целью придать им славянскую окраску. Таково, например слово «Блтавар», читаемое ими как Владимир. Правда, неизвестно о каком Владимире идет речь. Если это князь Владимир, при котором Русь принимает христианство, то, как он мог до этого принять Ислам. Между тем, общеизвестно, что князь Владимир отказался от принятия Ислама, ссылаясь на то, что на Руси любят веселье и питие. Впрочем, у Ибн Фадлана этому имеются убедительные доказательства. Официальной религией Руси в 988 году стало христианство в его православном формате.

Все достоинства труда Анвара Хайри трудно перечислить. Однако просматриваются и некоторые недостатки. Так, в работе немало повторений, причем в ряде случаев одних и тех же цитат. Ряд аргументов автора доступен лишь узкому кругу специалистов. Для более широкого круга читателей требуется более простой и упрощенный способ доказательств. За счет этого можно было бы работу несколько сократить, имея в виду и ее слишком большой объем.

Не приходится сомневаться в том, что Анваром Хайри проделан гигантский труд, результаты которого должны быть доведены до широкой общественности.

Предлагаю работу к печати.

**И.Р. Таһиров**

**Әнвәр Хәйринең «Ибн Фадланның Болгар дәүләтенә сәяхәтен тасвирлаучы сәяхәтнамәсен татарча һәм русчага тәрҗемә итүдәге яңалыклар» исемле монографиясенә бәяләмә**

**I.R. Tagirov**

**Opinion of the monograph Anwar Khairi «A new in the translation on the Tatar and Russian languages of narration of Ibn Fadlan about the travel to Bulgar state»**

**Автор турында мәгълүмат**

**Таһиров Индус Ризак улы** – тарих фәннәре докторы, КФУ профессоры, ТФА академигы, РФ һәм ТР атказанган фән эшлеклесе (Казан шәһәре).

**Тагиров Индус Ризакович** – доктор исторических наук профессор КФУ, академик АН РТ, заслуженный деятель науки РФ и РТ (г.Казань).

**Tagirov Indus Rizakovich** – doctor of historical sciences, professor of Kazan Federal University, academician of AS RT, honored scientist of RF and RT (Kazan).

УДК 013=512.145"19/20"

**Л.К. Тажиева**

# ОЛПАТ ГАЛИМНЕҢ МӨҺИМ ХЕЗМӘТЕ

*Аннотация.* Мәкаләдә танылган галим Әнвәр Хәйринең эшчәнлеге һәм татар халкының тарихын өйрәнү өчен зур әһәмияткә ия булган «Әхмәд ибне Фадланның 921–922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе» дип аталган рус һәм татар телләрендә чыккан хезмәте анализлана.

*Ачкыч сүзләр:* Болгар дәүләте, Ибне Фадлан сәяхәтнамәсе, тел тарихы, кульязма, тәрҗемә, ислам дине тарихы, текстология.

«Әхмәд ибне Фадланның 921–922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе» 2013 елда ТР президенты Р.Н. Миннехановның матди ярдәме белән дөнья күргән, татар һәм рус телләрендә чыккан 532 битлек китап – танылган галим Әнвәр Хәйринең соңгы хезмәте. Редколлегиягә халкыбызның күренекле галимнәре, билгеле шәхесләре кергән: ТФА академигы, тарих фәннәре докторы, КФУ профессоры И.Р. Таһиров, ТФА мөхбир әгъзасы, тарих фәннәре докторы, профессор Ф.Ш. Хуҗин, ТФА академигы, ТФА вице-президенты, КФУ профессоры Җ.Ш. Сөләйманов, КФУ гарәп теле укытучысы Л.К. Таҗиева, филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре, шәрыкъ телләре белгече С.М. Гыйлаҗетдинов.

Казан дәүләт университетында күп еллар дәвамында гарәп теле һәм әдәбиятын, иске татар язуын укыту дәвамында тирән белемле, танылган укучыларым күп булды минем. Әмма Әнвәр башкарак иде. Баштан ук аның белән тел тарихы, гарәп теле, аның халыкның рухи тормышындагы роле турында, башка мәсьәләләр турында да сөйләшүләребез, киңәшүләребез, фикер алышуларыбыз күп булды. Мин һәрвакыт аның миңа булган рәхмәтен, тирән ихтирамын тоеп яшәдем. Әмма, минем аңа биргән киңәшләремне, белемне шундый югары бәяләп, «Әхмәд ибне Фадланның 921–922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе» исемле хезмәтен «Гомере буе Казан дәүләт университетында гарәп теле укытып, фән, мәгариф, әдәбиятыбыз һәм мәдәниятебез өчен бик күп югары

әзерлекле белгечләр әзерләгән, мине дә шул тылсымлы гарәп китаплары дөньясына җитәкләп кертеп җибәргән иң яраткан Остазым Лена Кәлимулла кызы Таҗиевага багышлыйм», дигән сүзләр белән бирелгән багышлавы миңа әлегә кадәр бирелгән бөтен бүләкләрдән дә кадерлерәк булды. Әхмәд ибне Фадланның Идел буендагы Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе – Х гасырның беренче чирегендә яшәгән күп кенә халыкларның, шул исәптән безнең борынгы бабаларыбызның да тарихына, тормыш-көнкүрешенә, гореф-гадәтләренә, йолаларына, кием-салымнарына, ашау-эчүләренә, мәдәниятләренә караган, дөньяда сирәк очрый торган тарихи кульъязма чыганак булып санала. Әнвәр Хәйри әлеге хезмәтне тәрҗемә иткәндә, аның әһәмиятен, бөеклеген аңлап, зур җаваплылык тоеп эшләде, минем белән киңәште. Ул академиклар Х.Френ, А.П.Ковалевский, И.Ю. Крачковский кебек олпат галимнәрнең хезмәтләрен өйрәнде, аларга тирән анализ аша карады, ләкин иярмәде, бәлки фәнни төгәллек таләпләренә җавап бирә торган тәрҗемәне эшләп чыга алды. Бу сәяхәтнамә бик күп борынгы халыкларның, шул исәптән борынгы болгарларның да, тормыш-көнкүрешләре, гореф-гадәтләре, йолалары, мәдәниятләре турында бик сирәк очраучы кульъязма чыганакларның берсе буларак, аңа дөньяның бик күп илләрендә яшәүче галимнәр мөрәҗәгать итеп, өйрәнеп һәм тәрҗемә итеп караганнар.

Мәгънәсе ачылмаган сүзләрне һәркем үзенчә тәрҗемә итәргә һәм аңлатма бирергә тырышкан, төрле хаталар җибәрелгән, алар бер тәрҗемәдән икенчесенә күчереп барылган. Кайбер борынгы уйгур һәм төрки сүзләрне гарәп сүзләре итеп уку аркасында килеп чыккан буталчыклар да хезмәтнең асылын аңлауны катлауландырган. Хезмәтне тәрҗемә итү өчен, беренче чиратта, гарәп, рус, татар телләрендә глоссарий төзү юнәлешендә бик зур, шактый авыр эш эшләнде. Бу фәнни төгәллек, җентеклелек таләп итә торган эш. Әнвәр моны тулы җаваплылык тоеп, намус белән башкарды.

Белгәнебезчә, Әхмәд ибне Фадланның 921–922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе турында үзебезнең рус һәм татар галимнәренең дә, чит ил галимнәренең дә хезмәтләре шактый. Боларга өстәп нинди яңа сүз әйтелде икән дип, китап бик кызыксынып укыла. Чөнки Әнвәр Хәйрине борынгы текстларны күп өйрәнгән, бөртекләп эшли торган, тырыш, тәҗрибәле галим буларак беләбез. Инде студент елларында ук аның гарәп телен, факультетта чит тел өйрәнү күләмендә генә укытылуына карамастан, үзенең ты-

рышлыгы, мөстәкыйль рәвештә тирәнрәк өйрәнергә омтылуы нәтиҗәсендә яхшы ук әйбәт үзләштерүе күпләрне сокландыра иде.

Галим, иске татар һәм гарәп телендә язылган шактый гына чыганакларны татар һәм рус телләренә тәрҗемә итеп, фәнни анализ биреп, фәнни әйләнешкә кертеп җибәрде.

Дөнья күргән хезмәтләрендә һәр галимнең үз фикерен үткәрүе табигый. Ләкин чыганакларны үз тарихын матуррак, баерак, халкының ролен башка халыкларныкына караганда зуррак итеп күрсәтергә тырышу максатында бозып аңлату өчен файдалануга да мисаллар шактый китереп була. Мәсәлән, Шәрыкъны өйрәнүче рус галимнәренең Ибне Фадлан сәяхәтнамәсен тәрҗемә итеп, аңа аңлатмалар бирелгән хезмәтләрендә бу ачык сизелә. Китапка керештә автор үзен мондый тикшеренүгә этәргән сәбәпләрне күрсәтә. Аларның иң әһәмиятлеләреннән берсе – төрле авторлар тарафыннан эшләнгән тәрҗемәләрдә, югарыда әйтелгәнчә, гарәп теле күзлегеннән аңлатып булмый торган сүзләрне үз файдаларына борып тәрҗемә итү. Шуңа күрә галим иң беренче эш итеп А.П. Ковалевский тарафыннан 1956 нчы елда Харьковта бастырылган «Книга Ахмеда Ибн Фадлана о его путешествии на Волгу в 921–922 гг.» исемле китапның артында кушымта итеп бирелгән факсимиле нигезендә һәр сүзгә өч телдә – борынгы гарәп, рус һәм татар телләрендә – глоссарий сүзлек төзи. Бу эштә очраган кыенлыкларның берсе – факсимиледа күп кенә сүзләрнең начар, тонык булуы, кайберләренең тузып танып булмаслык хәлгә җитүе. Чыганакның гарәпчә басма текстын эшләп, әлеге хезмәтенә кушымта итеп бирүе белән Ә. Хәйри үзеннән соң әлеге чыганакны өйрәнергә алынган галимнәрнең эшләрен нык җиңеләйтә. Шуның белән бергә китапта факсимиле күчермә дә бирелә. Гомумән, сәяхәтнамәгә үзе тәрҗемә иткән һәм фәнни аңлатмалар ясаганнан соң, чагыштырыр өчен, автор бу китабына академиклар И.Ю. Крачковский, А.П. Ковалевский тәрҗемәләренең копияләрен дә китерә. Болардан башка Ибне Фадлан сәяхәте турындагы башка галимнәрнең хезмәтләре дә (Ш. Мәрҗани, З. Вәлиди, Р. Фәхретдинов һ.б.) бик тулы анализлана, кайберләренең тәрҗемәләре китапта бирелә. Әйтелгән фикерне ышанычлы дәлилләр өчен бу бик уңай: кирәкле урынны шундук табып, чагыштырып карарга мөмкинлек туа. Илчелекнең Багдадтан Болгарга кадәр юлын күрсәткән өч төрле карта күрсәтелгән, Ибне Фадлан сәяхәтнамәсе турындагы төп чыганакларны бергә туплаган, бу кулъязмага бәйләнешле хезмәтләргә тулы анализ биргән галим.

Әнвәр Хәйри һәр фикерен күп фактик материалларга таянып дәлилли. Моңа кадәр дөрес аңлатылмыйча, яки бөтенләй аңлатылмыйча килгән теге яки бу сүз, атама, кеше исемнәре гарәп теле грамматикасы, сүзьясалышы, сүз төзелеше, борынгы төрки, уйгур телләре нигезендә тикшерелә, сүз, җөмлә, контекст мәгънәсенә игътибар ителә.

Бер үк вакытта милли тарихыбызга караган иң борынгы һәм иң беренче язма чыганак булып торучы – 922 елда Идел буе Болгар дәүләтенә ислам динен рәсми дәүләт дине итеп игълан итәргә килгән илчелекнең җаваплы сәркатибе Әхмәт Ибне Фазланның сәяхәтнамәсен төп нөсхә кулъязмасының факсимиле күчермәсеннән турыдан-туры борынгы – классик гарәп теленнән бүгенге татар һәм рус телләренә тәрҗемә итеп, фәнни эшкәртеп матбугатка әзерләү белән шөгыльләнде. Текстның глоссариен – сүзлеген төзеп, татар һәм рус телләрендә тәрҗемә текстны эшләп, фән тарихында әле беренче тапкыр кулъязма китапның басма текстын гарәпчә басты.

Үзенең күпкырлы иҗаты белән Әнвәр Хәйри безнең илдә генә түгел, чит илләрдәге укучылары һәм галимнәр арасында ихтирам казанды. Алар аны күпкырлы галим, ислам дине белгече, борынгы шәркый чыганаклар буенча бик сирәк очрый торган белгеч буларак бәялиләр.

Әнвәр Хәйри ислам динен тирәнтен өйрәнеп, курыкмыйча, аңа объектив бәя бирүче беренче татар галиме булды. Ул Коръәннең иң күп һәм иң еш укыла торган 57 сүрәсен татар теленә тәрҗемә итеп, фәнни транскрипциясен һәм аңлатмаларын биреп, «Казан утлары» журналында 1990–1991 елларда бастырып чыгарды һәм белгечләрнең, дин әһелләренең уңай бәясен алды.

Республикабызның көндәлек матбугатында Әнвәр Хәйри бик күп догаларның гарәпчә язылышлары белән бергә фәнни транскрипцияләрен, татар теленә тәрҗемәләрен эшләп, республикабызда ислам динен өйрәнү, аны тарату, аңлатуга зур өлеш кертте.

Әнвәр Хәйри текстология фәненең хәзерге ысулларын камил белгән галим иде. Фәннең менә шушы гаҗәеп серле, искиткеч катлаулы, бик күп көч һәм сабырлык таләп итә торган иң авыр тармагы белән даими шөгыльләнү безнең борынгы тарихыбызга тирән төшеп, җитди фәнни тикшеренүләр алып барылуга нигез булды һәм киләчәктә дә әһәмиятләрен югалтмаячаклар.

**Л.К. Тазиева**

**Важный труд известного ученого**

*Аннотация.* В статье дается краткий анализ научной деятельности известного ученого Анвара Хайри и научному труду, имеющему важное значение для изучения истории татарского народа – «Повествование о путешествии Ахмеда Ибн Фадлана, написанное во время поездки в 921–922 годах в Булгарское государство», который был издан на русском и татарском языках.

*Ключевые слова:* Булгарское государство, описание путешествия Ибн Фадлана, история языка, рукопись, история ислама, текстология.

**L.K. Tazieva**

**Important work of a famous scientist**

*Annotation.* The article gives a brief analysis of the scientific activity of the famous scientist Anwar Khairi and scientific work of importance for the history of the Tatar people – «The narrative of the travel of Ibn Fadlan during your trip in the Bulgar state in 921 – 922 years», which was published in Russian and Tatar languages.

*Keywords*: Bulgarian state, a description of the travel of Ibn Fadlan, history of language, manuscript, history of islam, textual criticism.

**Автор турында мәгълүмат**

**Таҗиева Лена Кәлимулла кызы** – А.А. Жданов исемендәге Ленинград дәүләт университетының көнчыгыш телләр факультетын тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетында 50 елдан артык гарәп теле укытучысы булып эшли (Казан шәһәре); e-mail: tnd@rambler.ru

**Тазиева Лена Калимулловна** – преподаватель арабского языка, проработавшая в Казанском государственном университете более 50 лет, после окончания Ленинградского государственного университета им. А.А. Жданова (Казань).

**Tazieva Lena Kalimullovna** – teacher of Arabic, who worked in Kazan State University more than 50 years after graduating from A.A. Zhdanov Leningrad State University (Kazan).

УДК 94(470.41)"16/18"

**А.Х. Мәхмүтова**

# БӘЗӘКӘ АВЫЛЫНЫҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ: ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ ФАРАЗЛАР

*Аннотация.* Мәкаләдә сүз Татарстанның Менделеев районында урнашкан Бәзәкә авылының нигезләнүенә бәйле чыганаклар һәм аларны куллану мөмкинлекләре хакында бара. Чыганаклар – риваять, кабер ташлары, архив документлары – ярдәмендә ни дәрәҗәдә теманы ачыклап булуы хакында авторның уйланулары китерелә.

*Ачкыч сүзләр:* Бәзәкә, риваять, кабер ташлары, архив документлары, вотчина хокукы.

Авыллар тарихын өйрәнүчеләр алдына чишелеше табылырга тиешле бик күп проблемалар килеп баса. Аларның иң беренчесе – авылның барлыкка килү шартлары һәм вакыты. Авыл никадәр борынгырак булса, бу проблеманы чишү дә шулкадәр авырырак. Чөнки гасырлар аша тирәнгә төшкән саен, чыганакларга кытлык ныграк сизелә. Шуңа күрә мин үземнең чыгышымны чыганакларны барлауга багышладым.

Һичшиксез, әгәр авыл тирәсендә археологлар казу эшләре алып барган булса, аларның нәтиҗәләре төбәкнең борынгы чорларын аңларга ярдәм итәр иде. Ләкин мондый бәхетле авыллар хәзергә сирәк. Болгар чоры, Алтын Урда, Казан ханлыгы заманыннан калган язма чыганаклар да юк дәрәҗәсендә. Галимнәребез Шиһабеддин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдин һәм башкаларның әсәрләрендә авылыңның исемен очрату – шулай ук зур бәхет. Ә боларның берсе дә булмаса? Ул чагында авылларда буыннан буынга, телдән телгә тапшырылып килгән бәет-риваятьләр һәм дастаннар кала. Аларны ни дәрәҗәдә кулланып була? Менә шундый сораулар үз авылының тарихын торгызучыларның күбесен борчый дип әйтсәм, бер дә ялгышмам. Шуңа күрә күпләр, борынгы чорны өстән-өстән генә яктыртып, чыганаклар табуы җиңелерәк булган XIX–XX гасыр тарихын язу белән чикләнәләр.

Минем чыгышым Татарстанның Менделеев районындагы Бәзәкә авылының нигезләнүенә бәйле чыганаклар һәм аларны куллану мөмкинлекләре хакында. Бәзәкә авылында да борынгы заман-

нардан безнең көннәргә килеп җиткән риваятьләр шактый. Аларның берничәсе С.Таҗиевның 2000 елда Алабугада басылган «Туган авылыбыз Бәзәкә кайда да безнең йөрәктә» исемле китабында урын алган. Мин дә чыгышымда үземне эзләнүләргә этәргән бер риваятькә соңрак тукталырмын.

Икенче төр чыганаклар – кабер ташлары. Бәзәкә авыл зиратында да борынгы ташлар булуын филология фәннәре кандидаты Раиф Мәрданов ачыклады. Үзенең тамырлары да Бәзәкәдән булган галим, зиратның иске өлешен тикшереп, эзләнү нәтиҗәләрен 2004 елда «Менделеевск яңалыклары» газетасында бастырып чыгарды. Анда ул гарәп язулы 42 кабер ташын исәпкә алуы, аларны фотога төшереп, текстларын күчерүе хакында яза. Шул мәкаләдән бер өзек: «Бәзәкә авылының зираты бик зур, иске ташлар бик күп. Дөрес, XIX гасырда һәм XX гасыр башында куелган кайбер ташларның кеше исеме һәм елы кебек фактик мәгълүмат язылган өлешләре ватылган, яисә хәрефләре коелып-юылып беткән», – дип яза автор. – «Зираттагы иң борынгы таш каберстанның уртасында басып тора. Ул таш 1689 елда вафат булган Йөзекәй улы Айман исемле кешегә куелган. Андагы язуга караганда, ташны мәрхүмнең этисе куйдырган. Ташның биеклеге бер метр, киңлеге 50 см, калынлыгы 22 см».

Борынгы заманнарда Бәзәкәнең тагын бер зираты булган. Ул Бәзәкәдән 1–2 чакрым төньяктарак Көчәнде дип әйтелә торган урында урнашкан, әле 1930–1940 елларда да бу иске каберлекләр өстендә берничә иске язулы таш булуын мин үскәндә бабайлар сөйли иде. Вакыт узган саен ул ташлардагы язулар акрынлап коелаюыла барган, ә 1960–1970 елларда калган ташларны инеш буена трактор белән тарттырып төшереп, бушаган урынны чәчүлек иткәннәр. Шулай да ул ташларның берсе хәзер Менделеевск музеенда саклана. Р.Марданов, бу таш белән танышканнан соң, аның да шушы ук чорга караганлыгын ачыклады. Бер үк чорда язылган ташлы ике зиратның булуы шулай ук сораулар тудыра.

Чыганакларның өченче төркеме – архивларда саклаган рәсми язмалар. Минем карамакта булган Бәзәкәгә бәйле документларда иң борынгы даталар XVII гасырга – 1642, 1650, 1670, 1680, 1692, 1697 һ.б. елларга – караган. Бу язмаларда авыл-инеш исеменнән башка авыл тирәсендәге хәзер дә кулланышта булган елга-күлләр, ерынтычокырлар, юл-болыннар исемнәрен дә очратырга мөмкин. Димәк, ташъязма да, рәсми язмалар да авылның XVII гасырда яшәгәнлеген

раслый. Шушы ук дата Татар энциклопедиясендә дә бирелә. Бәлки миңа да шуның белән канәгатьләнергәдер?

Ләкин кечкенәдән туган авылымның борынгылыгы хакында риваять-хикәятләр тыңлап үскән бала буларак, минем чынбарлыкны барлыйсым килә. Әкиятләрдән дә кызыгырак тоелган бу риваятьләрне мин әбиләрдән кат-кат сөйләтә һәм һәрвакыт төрле сораулар бирә идем. Ә әбиләрнең җавабы бер – «мин сиңа үз әбиемнән ишеткәнне сөйләдем, шуннан артыгын белмим». Әнинең җавабы: «Үскәч, сорауларыңа җавапны үзең эзләп табарсың». Ниндиерәк сораулар иде соң ул? Мине ул вакытта борчыган сорауларның исемдә калганнары: Бу хикәят-легендаларның кайсысы чынбарлыкка туры килә? Яки ул әбиләр уйлап чыгарган әкият кенәме? Кайсы заманда булган бу вакыйгалар? Борынгы әби-бабаларыбыз яшәгән авылларны нинди дошман җимергән? Һ.б., һ.б. Чыннан да, бу риваятьләрнең чынбарлыкка туры килү-килмәвен ачыклау мөмкин микән? Үсеп җиткәч түгел (ул чорның үз сораулары күп, борынгы тарих еракта калган иде), инде олыгайгач, Бәзәкә тарихын барлауга тотынып, мин шушы сорауга җавап эзләп карарга булдым.

Минем хәтеремдәге үземә иң ошаган риваять-хикәяттән башлыйм.

Кайчандыр, бик күптән, борын-борын заманда, безнең авыл урнашкан якларга зур гына бер төркем кешеләр килеп чыккан. Төркемнең башлыклары – Бәзәк, Сәйтәк һәм Тәкәш исемле батырлар булган. Аларны өч дус дип тә, өч бертуган дип тә сөйлиләр иде. Бик ерактан килгән, арган-талчыккан кешеләр урман-әрәмәлекләре, елга-күлләре һәм хәтфә үләнле киң болыннары булган аулак урында ял итәргә туктаганнар. Тирә-юнь белән танышкач, алар урман-әрәмәлекләрдә төрле җиләк-җимеш-чикләвек, җәнлекләр һәм киек кошлар күп булуын, елга-күлләрнең кош-кортка һәм балыкка бай булуын күргәннәр. Чәчүлекләргә яраклы аланнар да булган монда.

Һәм өч батыр шушы җирдә туктап авыл корырга булганнар. Тау астыннан бәреп чыккан искитмәле чиста, тешне сындырырлык салкын сулы чишмә янында нигез салган алар яңа авылга. Бер ел үткәнме, ун елмы, батырлар яңа авылларга нигез салырга булганнар. Бәзәк үз исеме белән йөртелә башлаган авылда калган, Сәйтәк өч-дүрт чакрым көнбатышта булган, искиткеч тәмле сулы чишмә янында үз авылын, Тәкәш ике авылдан да бертигез ераклыкта төньяккарак таба булган шундый ук чишмә янында үз утарын булдырганнар. Шулай итеп Кама буе урманнары уртасында Кама елга-

сыннан җиде-ун чакрымдагы калкулыкта урнашкан өч авыл барлыкка килгән.

Бу хикәятнең икенче варианты яңа мәгълүматлар өсти. Безнең бабаларыбыз бу җирләрдән бик еракта, Идел (Волга) дип атала торган елга буенда, Болгар дәүләтендә, Бәзәкә исемле авылда тормыш көткәннәр икән. Ләкин дошман Бөек Болгар каласын да, аның тирәсендәге авылларны да җимергән-яндырган, малларын талап алган. Күп кеше һәлак булган, әсирлеккә төшкән. Исән калганнары качып котылган, төрле якка таралышкан. Шундый бер төркем, безнең якларга килеп чыгып, иске исем белән яңа авылга нигез салган. Риваятьнең тагын бер вариантында Идел буендагы Бәзәкә авылының Болгар бәкләренең биләмәсе булганлыгы һәм качып котылган төркем башында шул бәкләрнең берсе булуы хакында да сөйләнә иде.

Борынгы заманда Болгар дәүләтендә Бәзәкә исемле авыл булуы мөмкинме? Эзләнеп карыйк. Бүгенге Татарстанның Алексеевск районында, Иделгә коя торган Актай елгасы буенда Базяково исемле авыл бар. Авыл исемен татарчага Бәзәкә дип тәрҗемә итәргә була дип фараз кылыйк. Базяковоның тарихына күз салыйк. Алтын Урда чорында ук бушап калган бу җирләрне XVI–XVII гасырларда рус патшалары үзенең яраннарына хезмәтләре өчен өләшкән. Рус алпавытлары исә Мәскәү тирәсендәге өязләрдә яшәгән үз крестьяннарын яңа урыннарга, Волга буйларына күчергәннәр. Шундый бер алпавыт үз крестьяннары белән Актай елгасы буена урнашкан. Татар энциклопедиясе бу авылга XVII гасыр урталарына нигез салынган дигән мәгълүмат биргән. 1761 елда авылда Тихвин-Богородица чиркәве төзелгәч, авыл Богородицкое исемен алган. Совет заманында, дин-чиркәүләр белән көрәш башланган чорда, авыл борынгы болгар чорыннан ук килгән, рус телендә Базяково дип яңгыраган исеменә кайткан. Әлбәттә, Болгар дәүләтендә яшәгән авылның исеме русча түгел, ә болгар-татар телендә Бәзәкә булган.

Вакыйгаларның дәвамын болай фаразларга була.

Идел Болгарстанының йөзләгән авыл-шәһәрләре арасында Бәзәкә исемле авыл да булган дидек. Башка болгар авылларында яшәүчеләр кебек, бәзәкәлеләр дә икмәк үстергән, терлек асраган, киек кошлар, җәнлек аулау, балык тоту белән шөгыльләнгән. Уңдырышлы туфрак, куе һәм сусыл үләнле көтүлекләр, күп урманнар, мул сулы елгалар әлеге эшләр өчен уңай шартлар тудырган. 1236 елгы монгол афәтеннән исән калган җирләрдә тормыш яңадан

тернәкләнеп киткән. Ләкин ундүртенче гасыр азакларында бу җирләргә яңа афәт килгән. 1395 елны Аксак Тимер гаскәрләре Болгар, Сарай, Әстерхан кебек шәһәрләрне һәм Кырымдагы сәүдә үзәкләрен талаган-җимергән. Күп халык үтерелгән яки коллыкка алып кителгән.

Моның өстенә 1395 елның азагында берничә елга сузылган коточкыч ачлык башланган. Меңләгән кеше гомерен өзгән куркыныч авырулар таралган. 1405 елда гына бераз басыла төшкән чума чире аеруча куркыныч булган. Моннан соң да әле ул берничә тапкыр кабатланган. Урыс ушкуйниклары (юлбасарлары) да ел саен килеп авылларны талап-яндырып китә торган булганнар. Котылу чарасын эзләп, күпләр илдән киткән. Алар арасында бөтен бер кабиләләр дә, аерым олысларда яшәүчеләр дә булган. Бу вакытта Болгар шәһәре үзенең элеккеге көчен һәм Болгар җирләре үзәге ролен бөтенләй югалткан. Ызгыш-талашлар, Урда һәм рус кенәзләре һөҗүмнәре болгарлар хуҗалыгын тәмам җимергән. Шәһәрләр хәрабә хәленә килгән. Авыллар юкка чыккан. Болгарларның исән калганнары төньякка таба күченергә мәҗбүр булган. Алар Мишә, Казансу, Нократ елгалары буендагы җирләрне үзләштергән. Халыкны Кама-Чулман аръягы җирләре дә җәлеп иткән. Монда XV–XVI гасыр башларында дистәләгән авыллар барлыкка килгән.

Туган җирләрен ташлап китүчеләр арасында бәзәкәлеләр булуын да фаразлый алабыз. Аларның бер өлеше, риваятьтә сөйләнгәнчә, тынычырак тормыш эзләп, Кама буйларына килеп чыгарга һәм яңа урында иске исем белән яңа авылга нигез салырга мөмкин. Әгәр бу шулай булса, *Бәзәкә авылына хәзерге урында* ***XV гасырның беренче яртысында*** *нигез салынган* диярго мөмкинлек бар. Кызганыч, ләкин без бу фаразыбызны бернинди документ белән дә раслый алмыйбыз, чөнки ул чордан бернинди язмалар да, кабер ташлары да калмаган. Бәлки киләчәктә археологик эзләнүләр бу фаразны раслый, я булмаса, кире кага алыр. Авылның башлап урнашу чорына караган документаль чыганаклар булмаса да, халык хәтерендә саклаган риваятьләргә нигезләнгән шушы фаразны кабул итеп була. Чөнки бу риваятьләр әкияти, башка сыймаслык ниндидер могҗизалар, хакыйкатькә туры килмәстәй вакыйгалар хакында сөйләми.

Рәсми чыганакларга күчик. Бәзәкә исеме искә алынган иң борынгы документлар элеккеге Казан ханлыгы җирләре белән идарә итү өчен барлыкка килгән *Казан сарае Приказы (идарәханәсе)* материаллары арасында саклана. Беренче чиратта, бу *Писцовый*

*кенәгәләр.* Рус җирләрендә XV–XVII гасырларда халык санын, йорт-җир биләмәләрен теркәгән бу язмалар, Мәскәү билгеләгән *писец*лар (күчереп яки әйткәнне язучылар) тарафыннан урыннарда башкарылып, төрле салымнар билгеләү өчен кулланылган.

Рәсми документларда авылның исеме төрле язылышта – *Безяка, Бозак, Безяково, Безяки, Бизяки* формасында, инеш исеме *Безяка, Бозак, Безяковка, Безякинка* дип бирелгән. Шуңа да игътибар итик: документлар арасында, XVI–XVIII йөзләрдә үк архивларга эләгеп, кузгалмыйча безнең көннәргә кадәр сакланган язмалар юк дәрәҗәсендә. Патшалар һәм рәсми оешмалар тарафыннан бирелгән бу документларны безнең бабаларыбыз, буыннан буынга тапшырып, кадерләп, гасырлар буена саклаган. Кирәге чыкканда, хакимият әгъзаларына күрсәтә-күрсәтә, яки күчермәләрен ясатып-тапшырып, бабаларыбыз алардагы бәһасыз мәгълүматның безнең көннәргә килеп җитүенә сәбәпче булганнар. Шуңа күрә бу документлар еш кына очраклы рәвештә табыла. Безнең авылга – Бәзәкәгә караган чыганакларның да язмышы шундый булган. Мондый фактларга беренче тапкыр мин 1973 елда Россия дәүләт борынгы актлар архивында (РГАДА) юлыктым, соңрак Татарстан Республикасы Милли архивында (ТР МА) шул документларга нигезләнгән папкага тап булдым.

Аның беренчесе – *«Спорное дело об отводе земель вокруг города Елабуги»,* ягъни «Алабуга шәһәре тирәсендәге җирләрне бүлеп бирү хакында бәхәсле эш» дип аталган [РДБАА, 1306 фонд, 2 тасв., 127 эш]. Әлбәттә, бу исем минем табигый кызыксынуымны уятты – Алабуга – туган яктагы кала, анда минем әби-бабайлар яшәде, мин үзем дә 4 ел шунда педучилищеда укыдым. Папкадагы материаллар белән якыннан танышкач, гаҗәпләнүем тагын да көчәйде – монда безнең Бәзәкәбез хакында да материал бар икән бит! Папкадагы Бәзәкә җирләренә кагылышлы иң борынгы документлар XVII гасырга караган, ә папка үзе XIX гасырда, җирләр өчен бәхәсләшкәндә, барлыкка килгән икән.

Һәм менә, инде безнең көннәрдә, яңа табыш! Казанда яшәүче үзешчән тарихчы Руслан Шакиров Бәзәкә җирләре телгә алынган тагын бер папканың Казанда, Милли архивта булуын әйтте. Алабуга өяз суды фондында саклanучы бу папка – «ЗАПИСКА из дела О ПРАВАХ НА ВЛАДЕНИЕ ЗЕМЛЕЙ башкирами и тептярями в Елабужском и Сарапульском уездах» («Алабуга һәм Сарапул өязе башкорт һәм типтәрләрнең җирбиләүчелек хокуклары хакындагы эштәге язма») исемен йөртә икән [ТР МА, 986 ф., 1 тасв., 489 эш].

Һәм менә бу папка минем кулымда. 184 биттән гыйбарәт папкада төрле документлар җыелмасының җентекләп эшләнгән тасвирламасы бирелгән. Бу документлар Алабуга һәм Сарапул өязләрендә дәүләт тарафыннан уздырылган җир биләмәләренең чикләрен билгеләгән заманда туган дәгъвалашуга бәйле рәвештә 1799–1865 елларда җыелган булып чыкты. Ягъни бу материаллар алда сөйләнгән Мәскәү архивындагы материалларның күчермәсе яисә тасвирламасы дип әйтергә була. Мөгаен, документларны Мәскәүгә җибәрер алдыннан чиновниклар төгәл күчермәләрен алганнар яисә җентекле тасвирламалар ясаганнардыр. Шулай итеп, «күктән эзләгән, җирдә табылды».

Шушы ике чыганаклар җыентыгы авылыбыз тарихының борынгы чорын аңлау, фаразлау һәм тасвирлау өчен нигез булды. Бу җыентыкларда минем өчен иң мөһиме (һәм иң шиклесе дип әйтеп тә була) – бәзәкәлеләрдән кергән документлар тасвирламасында телгә алынган 1517 елгы грамота булды. Шул мәгълүматны бу урында тәкъдим итәм: «Повелением, произведенным при генеральном межевании спорам, поверенные спорющихся дач обязаны подписками в представлении в Межевую контору крепостей, каковые и представлены дачи № 12 деревни Безяков от башкирцев, тептярей и ясачных татар: 1-я, – *грамота 7025 года октября дня* (курсив минеке – *А.М.*), что при деле /122 ст./, засвидетельствованная в Оренбургской гражданской палате копия с сей грамоты от царя Петра Алексеевича на Уфу воеводе Леонтьеву по челобитной башкирцев Уфимского уезда Казанской дороги Ирминския волости Агильдейка Тямова да Еманка Юксеева» [ТР МА, 986 ф., 1 тасв., 489 эш, 58–59 б.]. 7025, ягъни 1517 елгы грамота хакында бу урында башка бер мәгълүмат та юк. Һәм гомумән бу дата башка бер җирдә дә кабатланмый. Ә менә Петр I дән Уфа воеводасы Леонтьевка җибәргән грамотада Бәзәкә җирләренең Тогай Беляковка («со товарищи») вотчина хокукы белән бирелүе хакындагы «старинная крепость», ягъни борынгы грамотаның 1643 елда янып юкка чыгуы турында сөйләнә. Бәлки шушы ике фактны берләштереп буладыр?

Менә XVII гасырга караган тагын бер документ. Аны галим Раиф Мәрданов Мәскәүдә РГАДАда табып, миңа куллану мөмкинлеген бирде. Ул «Ведомость с переписных книг Зюрейской дороги Казанского уезда 188 [1680] года» исемле кенәгәдән алынган. Бу урында аны тулысынча китерәм.

## *Гаилә*



Тормыш юлын башлаганда. 11 апрель 1969 ел



Яңа гаиләнең дуслары һәм туганнар белән төшкән беренче фотосы.
11 апрель 1969 ел



«Кадерле әткәй белән әнкәйгә!». Әнвәр, Альмира, Айдар.
Айдарга 5 ай ярым. Казан. 24 июль 1970 ел



Җиңү бәйрәмендә. Айдарга инде 7 яшь. Казан. 1977 ел



Гаиләбез ишәйде. Айгөлгә 1 яшь. Казан. 1984 ел



Хәйруллиннар гаиләсе. Казан. 23 апрель 1988 ел



Әнвәрнең әнисе
Гыйльмиҗиһан. 1999 ел



Альмира Хәйри оныклар
белән. Казан. 2003 ел



«Әби-бабайлар партиясе»нә кергәч. Әнвәр Хәйри оныклары Камил һәм Зөлфия белән. Казан. 2004 ел



Айдар белән Айгөл. Казан. 2004 ел



Бәйрәм табынын «корганда».
Казан. 2004 ел



Әнвәр Хәйри җәмәгате Альмира
белән. Казан. 2007 ел

*Эш*



Сыйныфташлар. Әнвәр сул як кырыйда, түбән рәттә утырган.
12 март 1960 ел



Күчмә театр артисты Нуретдин Нәҗмиев белән. 1966 ел



Казан театр училищесының 1 нче курсын тәмамлагач. «Массовка»да.
*Сулдан уңга*: Әнвәр Хәйруллин, Равил Шәрәфиев, Илдар Хәйруллин.
Казан. 1968 ел



КДУның татар драматургия студиясе. Җитәкчесе – Гәүһәр Камалова.
Ә.Хәйруллин арткы рәттә сулдан бишенче. Казан. 1968 ел



Күренекле татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның тууына 150 ел тулуга багышланган конференциядә катнашкан галимнәр
*Арткы рәттә сулдан уңга*: Сәлам Алишев, Әнвәр Хәйруллин, Шифа Ханбикова, Мәсгут Гайнетдинов, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов; *урта рәттә сулдан уңга*: Р.Шәрәфетдинова, Камил Фасеев, Гөлсинә Мөхәммәдова, Вахит Хаков, Фазыл Фасеев, Әбрар Кәримуллин; *беренче рәттә сулдан уңга*: Риза Газизов, Мөхәммәт Гайнуллин, Мидхәт Мөхәррәмов, Солтанморат Акбеев. Казан, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы актлар залы. 1975 елның 11 яки 12 феврале



Сабакташлар белән истәлеккә төшкән фоторәсем
*Икенче рәттә сулдан уңга*: Зиннур Мансуров, Александр Герасимов, Фиргать Газизуллин, Мөшәррәф Галиев, Әнвәр Хәйри.
*Беренче рәттә сулдан уңга*: Рашат Низамиев, Рәсимә Талибуллина, Флера Ганиева, Рамил Галимов. Казан. 6 июнь 1982 ел



Хезмәттәшләр. Рафаэль Мөхәмәтдинов белән киңәшләшкән мизгел.
Казан. 1985 елның октябрь ае



Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм тарих институтының
иҗтимагый фикер тарихы бүлеге хезмәткәрләре
*Сулдан уңга утырганнар*: Фәрит Солтанов, Әбрар Кәримуллин,
Яхъя Абдуллин, Рашат Әмирханов; *басканнар: беренче рәттә* – Нурия
Гәрәева, Фәридә Гаффарова, Наилә Рәхмәтуллина, Әнвәр Хәйруллин;
*икенче рәттә* – Тәфкил Камалов, Мансур Зарипов, Гамирҗан Дәүләтшин,
Рафаэль Мөхәмәтдинов. Казан. 1987 ел



«Мирас» журналында эшләгән чор.
1992 ел



Бөтендөнья татар лигасы президенты Али Акыш
халыкара «Мирас» журналы редакциясендә кунакта.
Казанда Али Акышның 75 еллык юбилеен бәйрәм итү көннәре
*Утырганнар сулдан уңга*: баш мөхәррир урынбасары, язучы, галим һәм журналист Касыйм Фәсахов; баш мөхәррир, язучы Әхмәт Сәхапов; Али Акыш (Мюнхен); җаваплы сәркәтип, галим һәм журналист Әнвәр Хәйри; әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире, галим һәм журналист Һәнүз Мәхмүтов; *басканнар сулдан уңга*: рәссам Ринад Галимуллин; юрист Йосыф Сәхапов; баш рәссам Рушан Шәмсетдинов; тарих бүлеге мөдире, галим һәм журналист Илшат Хәлиуллин; редакция хезмәткәре Павел Карнашин. 26 июнь 1993 ел



Әнвәр Хәйри Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, рәссам Эрот Зарипов ясаган портреты янәшәсендә. 1997 ел




Казан-Чаллы арасын ат арбасында уздык. 1998 ел

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Әнвәр Хәйри. 1998 ел





Әнвәр Хәйри. 1998 ел




Казан университеты гарәп теле укытучысы Лена Таҗиева һәм Әнвәр Хәйри. 13 март 1998 ел. Мидхәт Шакирҗанов фотосы



Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Әнвәр Хәйригә Татарстанның атказанган фән эшлеклесе дипломын тапшыра. Казан Кремле, 2001 ел



«Ирек» мәйданында «Хәтер көне».
*Сулдан уңга*: Разил Вәлиев, Рамил Курамшин, Әнвәр Хәйри.
Казан. 15 октябрь 2001 ел



Фаяз Хуҗин, Җәүдәт Сөләйманов, Әнвәр Хәйри. Казан. 2006 ел



Татарстанның Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Әнвәр Хәйригә
Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре дипломын тапшыра.
2008 елның октябрь ае



Әнвәр Хәйри шәхси китапханәсендә. 2008 ел

*«Починок на пустоши меж речки Безяка и Текеша.*

В нем татарских 11 дворов. В них людей – 13 человек, у них детей – 20, братьев – 5, внук – 1, вотчим – 1.

Платит тот починок 7 ясаков с получетью» [РДБАА, 350 ф., 2 тасв., 1102 эш, 646 б.].

Чыганактагы мәгълүмат шактый күп сораулар тудыра. Шуларның берсенә генә тукталам. Бу документта нинди Бәзәкә хакында сүз бара? Бәлки авыл ул чорда хәзерге урыныннан ике-өч чакрым өскәрәк урнашкан булгандыр? XVIII гасыр чыганаклары бу сорауны ачыкларга мөмкинлек бирде – беренче ревизия материаллары Бәзәкә инеше буенда ике авыл, өченче ревизия – өч авыл булуын күрсәтә. Шуларның өченчесе нәкъ Тәкәш һәм Бәзәкә инешләре аралыгында булган дип билгеләргә була, чөнки ревизия материалларында бу авылның исеме «Бозак словет Токмаклы» дип күрсәтелгән, ә Тукмаклы дип бүген дә бу урын атала.

Минем карамакта тагын бер төр чыганаклар тупланды. Ул Бәзәкәгә кагылышлы ревизия материаллары: XVIII гасырдан беренче һәм өченче ревизия материаллары сакланган, ә XIX гасырда үткән биш ревизия материаллары барысы да безнең көнгә килеп җиткән. Аларда тупланган бай материал авылның тормышын тасвирларга, гасыр ярым эчендә барган социаль-иҗтимагый үзгәрешләрне күзәтергә мөмкинлек бирә. Гомумән алганда, XIX–XX гасырга караган Бәзәкәгә бәйле төрле характердагы архив чыганаклары шактый күп. Һәм алар авыл тормышын төрле яктан тасвирлау мөмкинлеген бирә.

Кыска гына нәтиҗә: минем фикеремчә, яхшылап эзләнсәң, һәрбер татар авылына бәйле тарихи чыганакларны табып була.

## ӘДӘБИЯТ

1. Мәрданов Р. Бәзәкә авылы тарихына кайбер мәгълүматлар // Менделеевск яңалыклары. 2004. 23, 30 июль.

2. ТР МА, 986 ф., 1 тасв., 489 эш.

3. РДБАА (РГАДА), 1306 ф., 2 тасв., 127 эш.

4. РДБАА (РГАДА), 350 ф., 2 тасв., 1102 эш.

**Кыскартылган сүзләр:**

РДБАА – Россия дәүләт борынгы актлар архивы.

ТР МА – Татарстан Республикасы Милли архивы.

**А.Х. Махмутова**

## Возникновение деревни Бизяки: источники и гипотезы

*Аннотация.* В статье рассматриваются источники, которые могут дать ключ для раскрытия времени возникновения деревни Бизяки Менделеевского района РТ. Делаются краткие характеристики источников по теме. Приводятся некоторые размышления автора о возможности использования легенд при обосновании даты основания деревни.

*Ключевые слова:* Бизяки, легенда, надмогильные камни, архивные документы, вотчинное право.

**A.Kh. Makhmutova**

## The appearance of the village Bizyaki: sources and hypotheses

*Annotation.* The article considered sources which can provide the key for opening time of appearance of the village Bizyaki of the Mendeleev district of Tatarstan. Made brief characteristics of the sources on the theme. Are some of the author's reflections about the use of legends in the justification of the date of the founding of the village.

*Keywords:* Bizyaki, legend, gravestones stone, archive documents, patrimonial law.

**Автор турында мәгълүмат**

**Мәхмүтова Альта Хаҗи кызы** – тарих фәннәре кандидаты, ТР ФАнең Шиһабетдин Мәрҗани ис. премия лауреаты (Казан шәһәре).

**Махмутова Альта Хазеевна** – кандидат исторических наук, лауреат премии им. Ш.Марджани АН РТ (г.Казань).

**Makhmutova Alta Khazeevna –** candidate of historical sciences, laureate of the Prize named Sh. Marjani of AS RT (Kazan).

УДК 82-95"20"(470.41)

**Ә.Р. Нурхәмәтова**

# ӘНВӘР ХӘЙРИНЕҢ «ШӘҺРИ БАНУ – ШӘРБӘН КЫЙССАСЫ» ӘСӘРЕ БУЕНЧА ИҖАДИ ЭШ

*Аннотация.* Язмада Аксубай төбәкне өйрәнү музеенда төбәк тарихы белән кызыксынучы мәктәп балалары арасында Әнвәр Хәйринең «Шәһри Бану – Шәрбән кыйссасы» китабы буенча уздырылган рәсем ясау конкурсы турында бәян ителә.

*Ачкыч сүзләр:* Әнвәр Хәйринең «Шәһри Бану – Шәрбән кыйссасы», укучыларның иҗади эше, төбәк тарихы.

Кеше һәрвакыт үз туган җирен яратып, аңа тартылып, аның үткәнен һәм бүгенгесен хәтердә барлап яши. Туган ягыңның, үз район һәм авылыңның тарихын белү – һәр кешенең изге бурычы. Әнвәр Хәйринең «Шәһри Бану – Шәрбән кыйссасы» китабы белән танышкач, шәхсән үземдә, төбәгебез өчен горурлык хисе туды. Нинди бай тарихлы төбәктә яшибез икән! Моны ничектер балаларга җиткезәсе иде бит.

Аксубай төбәкне өйрәнү музее каршында йөрүче балалар белән Әнвәр Хәйринең «Шәһри Бану – Шәрбән кыйссасы» әсәре буенча иллюстрацияләр эшли башладык. Бик кызыклы, матур рәсемнәр килеп чыкты. Балалар мавыгып, кызыксынып эшләделәр.

Музейда «Ефәк юлы буйлап» дип аталучы балалар иллюстрацияләреннән күргәзмә оештырылды. Менә хәзер инде Аксубай халкы да туган як тарихыбыз белән якынрак танышты, кызыксына башлады. Соңрак күргәзмәбез Татарстан Республикасы дәүләт рәсем сәнгате музееның залларында үзенең урының алды. Күргәзмәне ачу тантанасында балалар үзләре Шәрбән кыйссасын сөйләделәр. Шулай итеп, Аксубай риваятьләре белән Казан халкы да танышты.

Балалар хезмәте югалмасын, киләсе буыннарга барып җитсен дигән теләк белән китап бастырып чыгарырга булдык. «Бөек ефәк юлы буйлап» дип исемләнгән китабыбыз Аксубай районының визит карточкасына әйләнде. Бу китап Аксубай районы авылларының тарихи һәм истәлекле урыннары хакындагы риваятьләрне үз эченә ала. Әлеге риваятьләрне укып, без Шәһри Бану (Шәрбән), Болгар

шәһәрчеге Мәрҗән, Кызлар Тавы (Татар Сөнчәлесе) һ.б. турында мәгълүмат алабыз.

Галим-тарихчы якташыбыз Әнвәр Хәйри менә шундый эшкә безне җанландырды. Без Әнвәр Хәйригә чиксез рәхмәтле. Аның белән горурланып яшибез.

**А.Р. Нурхаметова**

## Творческая работа по книге Анвара Хайри «Сказание о Шахри Бану – Шербени»

*Аннотация.* В публикации повествуется о проведении в Аксубаевском краеведческом музее среди учащихся, интересующихся историей края, конкурса рисования по «Сказанию о Шахри Бану – Шербени» Анвара Хайри.

*Ключевые слова:* Анвар Хайри, «Сказание о Шахри Бану – Шербени», творческая работа учащихся, история края.

**A.R. Nurkhametova**

## Creative work on the book of Anwar Khairi «The legend of Shahri Banu – Sherbini»

*Annotation.* The publication describes the conducting in Aksubaevo local museum among students interested of the history of the region, the contest drawing on «The legend of Shahri Banu – Sherbini» of Anwar Khairi.

*Keywords:* Anwar Khairi, «The legend of Shahri Banu – Sherbini», creative work of students, the history of the region.

**Автор турында мәгълүмат**

**Нурхәмәтова Әлфия Рәшид кызы** – Аксубай төбәкне өйрәнү музее директоры (шәһәр тибындагы Аксубай поселогы).

**Нурхаметова Альфия Рашидовна** – директор Аксубаевского краеведческого музея (пгт Аксубаево).

**Nurkhametova Alfiya Rashidovna** – Director of Aksubaevo local museum (Aksubaevo).

УДК 82.09(470.41)

**Р.Ф. Харрасова**

# УЗГАН ЧОРЛАР ШИГЪРИЯТЕН ШӘРЕХЛӘҮ ПРОБЛЕМАСЫ

*Аннотация.* Мәкаләдә текстны абсолют аңлауның бер идеал булуы, теләсә кайсы шәрехләүнең иреклелеге турында сүз бара. Текстны аңлатучы галим әсәр үзенчәлеген генә түгел, кабул итү үзенчәлеген дә исәпкә алырга тиеш. Узган чорлар поэтик мирасын өйрәнүчеләрнең суфичылык поэзиясенең образлар системасын яхшы белүе, ачыктан-ачык һәм яшерен мәгънәләрне янәшә куя алуы, алынмаларны тәрҗемә иткәндә лексик эквивалентларны таба белүе һ.б. кирәк.

*Ачкыч сүзләр:* суфичылык әдәбияты, текстология, татар әдәбияты тарихы, шигърият, интерпретация.

Әдәби әсәрләрне дөрес аңлау һәм аңлату проблемасы галимнәрдән дә битәр әдипләрне борчый дип уйлыйм. Безгә фикеребезнең, гомумән, әсәр аша җиткерергә теләгән эчтәлекнең укучыга барып җитүе, тасвирлаган образларыбызның иҗади кабул ителүе соң дәрәҗәдә мөһим, чөнки китапларны шул максаттан чыгып язабыз һәм аларның бәяләнүе дә укучыга күпме дәрәҗәдә аңлаешлы булуыннан тора.

Укучы прозаик әсәрдә урын алган тормыш барышын тулаем язылганча кабул итә алса да, шигъриятне һәркем үзенчә аңлый, бу шулай булырга тиеш, ул шуның белән кызыклы, дигән караш яшәп килүгә карамастан, поэтик текстларның да каләм иясе язганча аңлашылуы – идеалдыр. Әсәр эчтәлеген автор каләменнән төшкәнчә кабул итү укучының аны үзенә үлчәп каравына һич кенә дә комачауламый. Шәхси тормышы башкаларныкы белән нык кисешкәнлектән, укучы, вакыйга-күренешләр, сәнгати образлар тормышчан булса, әдәби дөньяга барыбер кереп китәчәк, үзен вакыйгалар шаһите сыйфатында тоячак, теге яки бу күренешләргә мөнәсәбәтен ачыклаячак. Укучының фантазиясен эшкә җигүе, аңын активлаштыруы кирәк, әмма аның шул рәвешчә нәкъ менә язучы фикерләренә якын карашларга барып чыгуы тагын да кирәгрәк.

Галимнәр, мөгаллимнәр, текстларны аңлатканда, авторлар каршында җаваплылык хисе тоеп эш йөртергә тиеш, ә бит кеше хезмәтенә сансыз мөнәсәбәт белдерүче режиссерлар, сценарийчы-

лар һәм, гомумән, әдәбиятка саксыз якын килүче кайберәүләр авызыннан соңгы елларда, текст әдип каләменнән төштеме, анықы булудан туктый, дигән бик куркыныч караш әледән әле ишетелгәли. Боларны күздә тотканда, текстларны шәрехләү проблемасының торган саен ныграк актуальләшә баруы бәхәс тудырмый.

Әдәби текстларны шәрехләүгә түбәнсетебрәк карау электән килә, бәлки, бу китап уку, аны бәяләү технологиясендә аскырак баскычта торган гамәлгә карата өлешчә гаделдер дә, әмма төгәл шәрехтән башка дөрес анализ юклыгын да онытырга ярамый.

Текстны автор теләгәнчә аңлауның төп шартлары күп түгел. Шуның иң тәүгесе – укучының язучы дәрәҗәсенекеннән түбән булмаган аңга, күзаллауларга иялеге. Икенчесе – фикерләү сәләтенең үскәнлеге. Әгәр шулай икән, ул әдип карашларын кабул итмәскә дә мөмкин, әмма, текст белән юл арты юл танышып, үзе дә сизмәстән автор логикасына ияреп китеп, әсәр эчтәлеген дөрес ачачак.

Шәрехләү, чагыштырмача гадирәк гамәл булса да, анализга шактый якын тора, аларны еш кына бер-берсеннән аерып карау да кыен. Дөресен генә әйткәндә, фәнни-эстетик анализдан бигрәк, тасвирлау өстенлек иткән татар әдәбияты белемебездә күпчелек гыйльми хезмәтләр шәрехләүгә нигезләнә яисә фәнни язмаларда шәрехләү теге яки бу күләмдә очрамый калмый. Бу бигрәк тә узган чорлар әдәбиятын чагылдырган хезмәтләрдә ачык күренә. Әлеге күренеш галимнәребезнең фәлсәфи-эстетик анализга сәләтсезлеген күрсәткән шикелле булса да, һәр очракта да түгел.

Герменевтик методның фәнебездә активлашуының объектив сәбәпләре бар. Әйтик, моңа кадәр, гарәп шрифтында язылган күпчелек әсәрләр массаларга бөтенләй таныш булмаганлыктан, аларны эчтәлекләрен ачмыйча аңлату мөмкин түгел иде. Без бит әле татарча укымаган яисә аз укыган, начар төшенгән аудиторияне дә күздә тотып эш йөртәбез, һәм аларны башта текстларның үзләре белән билгеле бер дәрәҗәдә таныштыру аерымачык кирәк.

Еллар узган саен, искә алынган проблема хәл ителер кебек иде, әмма эшләр катлаулана гына бара. Элекке мирасның кириллицага күчерелеп яңадан бастырылганы да еш кына укучы кулына барып ирешми я булмаса зур күпчелектә аларны укуга ихтыяҗ формалашмаган. Егерменче гасыр башына кадәр иҗат ителгән әдәбиятны әле дәрәҗәле галимнәрнең дә зур кыенлык белән аңлавын онытырга ярамый, чөнки алар гарәп-фарсы теленең белгечләре түгел, әлеге телләрдә язылган әдәбиятта да тәрбияләнмәгән.

Узган гасырда, бигрәк тә фәнгә зур таләпләр совет чорында чыгарылган сүзлекләрнең, читкә тибәрелеп, яңаларына алмаштырылуы, дәүләт нәшриятының төзүчесе, гарәп-фарсы сөйләм теленең үзенчәлекләреннән хәбәрсезлеге өстенә, татар филологы да булмаган сүзлекне төп кулланма итүе, андагы язылышны күчләп дәреслекләргә, шул исәптән без дә хәзерләшкән әдәбият тарихларына кертүе укытучыларны, тотрыклы кагыйдәләргә нигезләнгән сөйләмдә тәрбияләнгән буыннарны авыр хәлгә куйды, күп кенә сүзләрнең басмалар аша ныгыган, аңлатып булган элекке язылышын текстлардан кысрыклап чыгарды. Моның, бер яктан, текст аңлауга зыяны артык юк та кебек, әмма ул нәфис әсәрләргә, фәнгә, гомумән, әдәбиятка һәм телгә, аның язма һәм сөйләмә төрләренә саксыз караш формалаштыруга үзеннән өлеш кертми калмый.

Язылышны буталчыкландыру янәшәсендә, без, галимнәр, тарафыннан ашыгыч рәвештә хәзерләнгән китаплар, текстологик эш башкарганда, өстән төшерелгән сан артыннан куарга мәҗбүрлегебез, һәм аның, үз чиратында, текстларның рус хәрефләренә хаталы күчерелешенә, еш кына бик үк төгәл булмаган аңлатмалар белән чыгуы кебек күренешләр дә бар бит әле. Беләбез ки, китап инде кириллицада дөнья күргән икән, без, галимнәр, күпчелек очракта оригиналга таянмыйбыз, бастырган кешеләрнең төгәллегенә ышанабыз.

Сүзлек составының зур өлешен гарәп-фарсы лексемалары алып торуына карамастан, заман яшьләренә, мәктәп балаларына өлкәннәр сөйләмендә актив йөргән алынмалар да аңлашылмый. Бүгенге көндә көндәлек сөйләмдә пассив катламга күчкән төрки-татар сүзләрен аңламаучылар да торган саен күбәя. Шушы шартларда текстларны шәрехләү проблемасы тагын да актуальләшеп китә. Әгәр укучы, хәтта укытучы һәм галим дә текстны, шул исәптән аерым сүзләрне тулысы белән төгәл аңламый һәм кабул итми икән, әдәби әсәргә дә дөрес анализ бирмәячәк. Мәктәпләр өчен хәзерләнгән яңа дәреслекләрдә аңлатмалар саны арту, дәресләрдә сүзлек эшенә күп вакыт калдырулар нәкъ шушы хәлләрне ачык сөйли.

Теге яки бу текстны шәрехләп бирми торып, укучыда текст бөтенлеге тойгысы уятып булмый. Шәрехләү кабул итү, аңлау, аңлату кебек өч гамәл-төшенчәне үз эченә сыйдыра, ә бит алар анализның да эчтәлеген билгели. Димәк, шәрехләү белән анализ бер-берсен алмаштырмасалар да, үзара шактый якын тора. Әгәр галим текстны үзенең эчке тоемы белән аңлавына нигезләнеп анализ-

лый икән, укучы аның тоемына таяна булып чыга. Галимнең үзенең дә һәр укыганда текстка төрлечәрәк якын килүе, аны аермалырак аңлатуы әнә шул эчке тоем үзгәрешләренә барып тоташа. Аңа исә теге яки бу вакыттагы кәеф, зиһен ачыклыгы кебек психологик хәл-халәтләр дә тәэсир итә.

Төрле чор һәм төрле милләт галимнәренең милли-иҗтимагый мәнфәгатьләрне күздә тотып субъектив башкарылган, бигрәк тә заманга яраклаштырылган интерпретациясе шулай ук укучыны автордан һәм ул иҗат иткән тексттан ерагайта. Идеологик максатларны күздә тотып та фальшка барырга, текстны менталь киңлеккә, заманга яраклаштырып актуальләштерергә ярамый дигән карашта торам.

Узган чорлар шигърияте интерпретацияләү галимнәребез өчен иң авыры. Бигрәк тә безнең суфичылык кебек күренешләрнең төбенә төшеп аңламавыбыз, һәр иҗатны мөмкин кадәр бу дөнья тормышы, реалистик фикерләү белән ныграк бәйләргә тырышуыбыз текстларны дөрес аңлатудан ерагайта. Мин моны Кандалый хакындагы бер язмамда шушы рәвешчә билгеләп үткән идем: һәрбер каләм иясенең мирасыннан яңа фикер, форма, образлар эзләп мавыккан совет чоры галимнәре тарафыннан башка төрки әдәбиятларда хәзергәчә ныклы һәм актив урта гасырчылык традицияләренә бераз бәя киметелде сыман. Һичшиксез, образлар системасы, сюжетлары һ.б., беренче чиратта, борынгы мифологиягәдән, төрле эчтәлектәгерәк, юнәлештәгерәк тамырлары да булган ислам әдәбиятыннан, башка диндәге халыкларның мистик карашларны чагылдырган сүз сәнгатьләреннән килгән һәм Аллага мәхәббәтне данлаган суфичылык шигърияте кайберәүләрнең дини әдәбият белән тәңгәлләштерүе һәм поэтик юнәлеш буларак бәяләп бетермәве я булмаса дини-дидактик сүз мирасындагы образлар системасының тормышчан да, заманча да әсәрләр иҗат итәргә яраклылыгын танымаулары күзәтелде.

Г.Кандалыйның гына түгел, башкаларның да яңа рухтагы, эчтәлектәге шигъриятенә берьяклырак бәя бирелде, әдәби күчемлелек проблемасы тиешле игътибарга алынмыйча, шагыйрь мирасын үзенә кадәр иҗат итүчеләрнекеннән кискен аерып куярга омтылыш ясалды. Никадәр генә тормышчан язмасын, күпсанлы шигырьләрендә җир мәхәббәтен сурәтләү үзәктә тормасын, Г.Кандалыйның әдәби мирасында саф суфичылык әсәрләре дә бар иде; хәтта Сахибҗамал, Фәрхи, Шәфгый кебек гүзәлләргә мәхәббәт хисләрен

җиткергәндә, Г.Кандалый суфичылык әдәбиятының барлык мөмкинлекләрен эшкә җикте, аңа хас образлар системасын булдыра алганча мул файдаланды. Бигрәк тә кыска күләмле тезмәләрен гади халык телендә иҗат иткән Г.Кандалый поэзиясендә гарәп-фарсы алынмаларының күплеге әнә шуның белән аңлатыла да. Суфичылык поэзиясендә актив кулланылышта булган төрле тип конструкцияләр, аерым алганда фарсы теле аша кергән изафәләр Яңа заман шагыйре поэзиясендә традицияләр тотрыклыгы хакында сөйли. Һәм менә без, XX гасыр башына кадәр иҗат ителгән барлык шигърияткә шушы позицияләрдән торып якын килергә тиешле.

Кандалый белән бәйләү җиңелрәк булуга карамастан, үзенчәлекле мәхәббәт шигырьләре язган С.Рәмиевне, Г.Тукайны искә төшерик. Аларның кайбер әсәрләрендә гашыйклык татлы газап, мәҗнүнлек, табынган объектның колы хәленә төшерүче хис, кешене үстерүче дә, рухи һәм физик юкка чыгаручы да итеп күрсәтелә, ә бит мәхәббәтне шушы рәвешчә тасвирлау нәкъ менә суфичылык әдәбиятына барып тоташа.

Татар әдәбияты тарихында суфичылык күренеше, суфичылык әдәбияты махсус тирәнтен өйрәнелмәгән өлкәләрнең берсе булып кала бирә. Без, әдәби текстларны интерпретацияләгәндә, суфичылык идеологиясенең алга таба дөньяга килгән күзаллауларга да үтеп керүен аңлап эш итәргә тиеш. Бигрәк тә мөгаллим-шагыйрьләр иҗатында, әйтик, Утыз Имәнинең, Г.Чокрыйның күп кенә әсәрләрендә әдәби текстлар белем бирү юлларының берсе булып тора. Шул ук Кандалыйның да саф суфичылык рухындагы әсәрләре шәкертләр өчен дәреслек хезмәтен үти.

Ачык, ягъни өс һәм яшерен, ягъни асмәгънәгә ия суфичылык поэзиясе татар әдәбиятының алга таба аллегорик планда яисә читләтеп әйтү яссылыгында үсеп китүенә хезмәт итә, ул әдәбиятта метафоралаштыру күренешенең көчәюенә китерә. Шагыйрь бигрәк тә мөстәкыйль дәүләт, милли яшәеш турында уйланганда, икепланлы символикага ия суфичылыктан ук килгән әдәби алымнарга таянып эш йөртә. Мистикага зур урын бирүгә карамастан, кеше хисләре үтә дә көчле чагылыш тапкан суфичылык поэзиясен аңлау өчен, без барлык көнчыгыш әдәбиятларын, аларда кулланылган образлар системасын белергә, шул образларның мәгънә эчтәлеген туплаган белешмәлекләрдән хәбәрдар булырга, үзебезнең әдәбиятка ятышлыларын төзергә, бастырып чыгарырга тиешбез.

Суфичылык шигъриятендә кешенең дини тәҗрибәләре генә түгел, көндәлек яшәеше дә чагылыш таба, шунлыктан хәтта шактый абстракт тасвирлы юллары да көчле эмоциональ тәэсиргә ия булып тора. Дөнья әдәбиятларында бүгенгәчә суфи шагыйрьләр һәм, суфи булмауларына карамастан, аларның традицияләрен дәвам итүчеләр иҗатындагы дәрәҗәдә поэтик буяулар матурлыгы күзәтелми!

Башка төрки халыкларның галимнәре һәм шулай ук руслар тарафыннан да «Коттадгу белек» поэма-мәснәвиендә, Мәхмүд Кашгари төзегән мәгълүм телләр сүзлегендә суфичылыкка мөнәсәбәтле өзекләр барлыгы исбатланды, алга таба бу төр күчемлелекнең әдәбиятта эзлекле чылбыр рәвешендә ныгый гына баруын күрсәтү бурычы тора, һәм әдәби текстларны мөмкин кадәр күбрәк һәм төгәлрәк шәрехләү шул эшкә хәзерлек баскычы булыр иде.

Әдәбият белемебездә татар шигърияте тарихында яисә гомумән сүз сәнгатендә Коръән суфичылыгы кебек темалар да өйрәнелмәгән килеш кала бирә, әмма теге яки бу иҗатларның Изге китап белән бәйләнешләре аерым диссертацияләрдә чагылыш тапкалап килә. Карендәш халыкларның гыйльми хезмәтләрендә шулай ук Өмми Камал һәм башка шагыйрьләр мирасы суфичылык белән тыгыз бәйләнештә шактый ачылган, ә без бу өлкәгә кереп барган хәлдә тукталып калдык шикелле.

Татар әдәбиятында теләсә кайсы иҗатны фольклор һәм суфичылыкның бергә гармоник тәэсир рәвешендә яктырту кызыклы. Көнчыгышның суфичылык шигърияте җыр символикасын автор текстларына трансформацияләүгә үзеннән зур өлеш кертә. Суфичылыкның кануни поэтикасы исә шагыйрьләргә үзләрен чорнап алган тирәлеккә яңа күз белән карарга булыша, шуның нигезендә традицион образлар яңача ачылып, текст эчендә мәрҗән кебек җетеләнеп китә.

Кайбер шагыйрьләребезнең язганын, бигрәк тә мәгърифәтчелек йогынтысына эләккән каләм ияләребезнең иҗатын ничек кенә диннән ерагайтырга тырышма, ислам идеалларын яклаулары, аның әхлак нормаларына таянулары, үгет-нәсихәт, яхшыга өндәүләре белән генә дә, алар үзара тыгыз бәйләнештә кала. Кандалыйның җир кызына булган мәхәббәт шигырьләре дә шул ук куркыту, өндәү, тәрбияләү рухында һәм дини суфичылык символикасы белән шыплап тулган түгелмени соң?!

Иманлылык, рухи сафлык, гаделлек, яхшыга омтылыш кебек идеяләр нәкъ менә ислам әдәбияты, суфичылык поэзиясе тәэсирендә

әдәбиятыбызда ныгый, чөнки шул ук идеяләрнең бу тормыш өчен дә, бакыйлык өчен дә әһәмияте чиксез дип карала. Ахыр чиктә мәгърифәтчелек әдәбияты геройлары да барысы да диниләр, Аллага ихлас ышанучылар, шәригать киртәләрен атлап чыкмаучылар бит. Кандалыйныкыдай гыйсъянчылык рухы да бөтен суфичылык әдәбияты өчен хас. Исламда тыелган шәраб эчү кебек элементларны текстларга кертү, әмма аларга башка мәгънә салу суфи шагыйрьләрнең асылда дуалистлар икәнлеген күрсәтеп тормыймы икән?..

Гарәп-фарсы шагыйрьләре, бигрәк тә Гомәр Хәйям кебек талантлар иҗат иткән текстларның Коръән сурәләре белән турыдан-туры бәйләнешлелеге, һәрберсенең Изге китаптан мотивлашуы күптән дәлилләнде. Татар әдәбият белемендә узган чорларга караган бик күп нәфис текстларның Коръән, хәдисләр белән бәйләнешләрен ачыклау шулай ук алда фәндә көчәергә тиешле юнәлеш булып тора. Суфичылык әдәбиятының ислам уку йортлары галимнәре тарафыннан ныграк өйрәнелүен, ә безнең тарафтан кимрәк игътибарга алынуын да билгеләп үтәргә, моны шулай ук дини гыйлемнәрдән хәбәрдарсызлыгыбыз белән бәйләп карарга кирәк.

Төрки халыкларда дини әдәбиятны суфичылык әдәбиятыннан аерып карау мөмкин дә түгел, чөнки ул исламны таратуда зур эш башкара, суфичыл характердагы әсәрләр еш кына укучы тарафыннан дин дәреслеге дәрәҗәсендә кабул ителә. Мәгърифәтчелек, аң-белем тарату функциясе йөкләнгән суфичылык әдәбияты безне бик эзлекле рәвештә мәгърифәтчелек әдәбиятына алып килә. Бу төр фикер әдәбият белемебездә я яңгырамый, яисә бик йомшак һәм зәгыйфь кенә ишетелә шикелле.

Бигрәк тә ачы нәтиҗәләрне ассызыклаган, я булмаса дәлилләнмәгән хакыйкатьләрне алга сөргән, яшәү мәгънәсен аңлаткан, рухи кыйммәтләрне алга куйган фәлсәфи лириканың тамырлары да суфичылык әдәбиятына барып тоташа. Димәк ки, без кайсы гына язучы, узган чорларда шигърият нигез төр булганлыктан, бу очракта, шагыйрь иҗаты суфичылык белән тыгыз бәйләнешләрдә генә өйрәнелә ала. Без хәтта Алланы тулысынча кире каккан совет чоры әдәбиятын да бу тамырлардан кисеп ала алмыйбыз, ул аны тегеләйме-болаймы шифалы сулары белән сугара.

Текст интерпретацияләү турында сүз алып барган чыгышыбызда шәрехләүнең оригиналны мөмкин кадәр тулырак ачуына, борынгы әдәбиятны суфичылык күренеше белән ныграк бәйләүгә бирелде, чөнки әлегә нәкъ менә алар узган чорлар шигъриятен өйрәнүче

галимнәр тарафыннан ахыргача хәл ителмәгән иң зур проблемалар булып тора.

**Р.Ф. Харрасова**

### Проблема интерпретации поэтических текстов прошлого

*Аннотация.* В статье говорится, что любая интерпретация текста произвольна, а абсолютный смысл текста – недостижимый идеал. Ученому при разъяснении текста важно не только учитывать своеобразие самого произведения, но и своеобразие его восприятия. Исследователи поэтического наследия прошлого обязаны глубоко разбираться в образной системе суфийской поэзии, уметь соотнести прямые и скрытые смыслы, найти лексические эквиваленты при переводе заимствований и т.д.

*Ключевые слова:* суфийская литература, текстология, история татарской литературы, поэзия, интерпретация.

**R.F. Kharrasova**

### The problem of interpretation of the poetic texts of the past

*Annotation.* The article States that any arbitrary interpretation of the text, and the absolute meaning of the text is an unattainable ideal. The scientist, the explanation of the text is important not only to consider the originality of the work itself, but also the uniqueness of his perception. The researchers of the poetic heritage of the past must be understand in the imagery of Sufi poetry, be able to relate the direct and hidden meanings, to find lexical equivalents in the translation of borrowings, etc.

*Keywords:* Tatar literature, poetry, Sufism literature, textual critic, interpretation.

**Автор турында мәгълүмат**

**Харрасова Рифә Фатхрахман кызы** – филология фәннәре кандидаты; доцент, ТР ФАнең өлкән фәнни хезмәткәре (Казан шәһәре); e-mail: Rita.rahman@yandex.ru

**Харрасова Рифа Фатхрахмановна** – кандидат филологических наук; доцент, старший научный сотрудник АН РТ (г.Казань).

**Kharrasova Rifa Fatkhrakhmanovna –** candidate of philological sciences, docent, senior researcher of the Academy of Sciences of RT (Kazan).

УДК 2-29(282)(0.032)

**А.Г. Хәйретдинов**

# МУСА ҖАРУЛЛАҺ БИГИЕВНЫҢ КУЕН ДӘФТӘРЛӘРЕ

*Аннотация.* Мәкаләдә Муса Җаруллаһ Бигиевның шәхси китапханәсендә сакланган куен дәфтәрләре һәм аларның эчтәлеге турында мәгълүмат бирелә.

*Ачкыч сүзләр:* Муса Бигиев, Муса Җаруллаһ, гарәп язулы кульязма чыганаклар, ислам белеме, ислам тарихы, ислам фәлсәфәсе, татар иҗтимагый фикер тарихы, татар дини фикер тарихы.

Күренекле татар дин галиме вә җәмәгать эшлеклесе Муса Җаруллаһ Бигиев гомерен туктаусыз сәфәрләрдә үткәргән. Алман иле, Финляндия, Япония һәм Көньяк-Көнчыгыш Азиянең колонияләре, Госманлы хәлифәлегенең Хиҗаз, Шам, Шәриф, Гыйрак, Анадолу, Мисыр кебек биләмәләре, Иран, Әфганстан, Кытай, Һиндстан... Кайда гына булмаган олуг галимебез, ниләр генә күрмәгән. Муса әфәнденең әйтүенчә, кайда гына булса да, аның сандыкта йөртелгән шәхси китапханәсе һәрчак янында булган. Гыйлем иясе вә язучы буларак Муса әфәнде сәфәрләрендә алган тәэсирләрен, юлда туган фикер-кичерешләрен, үзенең күңел халәтен куен дәфтәрләрендә чагылдырып барырга гадәтләнгән була. Әлеге чыгышымда Муса әфәнде калдырган кульязма мирасның әнә шул өлеше турында кыска гына бер хәбәр ясыйсым килә.

Мәгълүм булганча, Муса Җаруллаһ гомеренең соңгы көннәрен Каһирәдә үткәрә һәм 1949 елда шул шәһәрдә бакыйга һиҗрәт кыла. Аның гомере буе туплаган шәхси китапханәсе вә шул исәптән куен дәфтәрләре дә югалмый. Галимнең Каһирәле якын дуслары Габдерәшит казый Ибраһимовның кызы Фәүзия ханым белән Галимҗан Идриси [Хайрутдинов, 2005, с.36] Муса әфәнденең васыятен үтәү йөзеннән ул шәхси китапханәне Төркия Милли китапханәсенә тапшыралар. Шулай итеп, әлегә кадәр бу хәзинә Анкарада саклана. Моннан берникадәр вакыт элек Истанбулда яшәүче дусларым Булат вә Илсөяр Рәмиевларның ярдәме вә арадашлыгы белән Муса әфәнденең куен дәфтәрләренең электрон күчермәләре минем кулыма да килеп керде.

Ошбу куен дәфтәрләре төрле калынлыкта һәм зурлыкта булган 27 дәфтәрдән гыйбарәт. Араларында мәктәпләрдә кулланыла торган

12 битле гади язу дәфтәрләре дә бар, шактый күп сәхифәле, мәсәлән 86 битле катыргы тышлы блокнотлар да бар. Дәфтәрләрнең уртак күләме якынча 1260 сәхифә тәшкил итә.

Бу дәфтәрләргә карап галим кылган сәфәрләр, узган юллар географиясен, зиярәт иткән илләр, шәһәрләр, авылларны барлап, күзаллап була. Биредә Советлар Союзында нәшер ителгән мәктәп дәфтәрләре бар, моннан тыш Кабул, Дели белән Бомбей, Тәһран вә Исфаһан, Гыйрак вә Шам, ниһаять, Истанбулда бастырылган дәфтәр һәм блокнотлар бар.

Кульязмаларның эчтәлегенә килгәндә, ул гаять төрле.

Дәфтәрләрнең һәркайсында диярлек төрле темаларга караган мәгълүмат бар. Алар арасында дини мәсьәләләр, мәсәлән, мөтга никяхы турында бер хәбәр, этимологиягә кагылышлы татарча-урысча язмалар, тарих, язма чыганаклар белеме, география, астрономия һәм ел исәбе, сәфәр вакытларында күргәннәрен чагылдырган кыска гына күзәтүләр, теге яки бу шәһәр вә авылларның көндәлек тормышын тасвирлаган парчалар, фәлсәфи уйланулар, төрле шәхесләр белән очрашу-аралашулар, ислам дөньясының сәяси-иҗтимагый вәзгыяте турындагы фикерләр һәм башка күптөрле язмалар. Аерым бер дәфтәр галимнең 1927 елда кылган хаҗ сәфәрнамәсенә багышланган. Гомумән алганда, Муса әфәнденең шәхси язмаларын уку дәвамында ул яшәгән дәвернең тере сулышын, халәтен кайгы-хәсрәтләрен тоеп була.

Кайбер дәфтәрләрдә галимнең фәнни эшчәнлеген чагылдырган язмалар бар. Андыйлардан, мәсәлән, Муса әфәнденең ниндидер китапханәдә язып алган китаплар исемлеге һәм андагы аерым китапларга карата кыска тасвирламалар рәвешендәге язмаларны атап була. Дәфтәрләрнең кайберләрендә Муса әфәнденең гарәп яки татар телендә язылган гыйльми әсәрләре бар. Татар телендә язылганнардан гаилә темасына кагылышлы күләмле бер мәкаләсе игътибарны җәлеп итеп тора. Сүз дәфтәрләрнең берсендә урын алган һәм «Гаиләдә хатын» дип аталган 22 битлек бер әсәр турында бара. Әлеге әсәрнең Муса Бигиевның «Коръән кәрим айәт кәримәләре нурлары хозурында хатын» исемле китабына кермәгән мөстәкыйль хезмәте булуы бик ихтимал.

Моннан тыш кайбер дәфтәрләр Муса Бигиевның үзе өчен күчереп яки күчертеп язган теге яки бу әсәрләрдән гыйбарәт. Моннан аңлашылганча, Муса әфәнде теге яки бу фәнни әсәрләрне үзе өчен бик әһәмиятле вә кирәкле дип санаган һәм аларны үзе белән

йөртү өчен күчереп язган булган. Мисал өчен, П.Ф.Тома исемле авторның «Фәлсәфә дәресләре» исемле хезмәтенең кулдан күчерелгән нөсхәсен атап була. Димәк, Муса әфәнде ислам диненә кагылышлы темалар белән чикләнмичә, гомере буе Көнбатыш фәне белән дә кызыксынып, танышып, өйрәнеп торган.

Муса Бигиевның язма мирасының куен дәфтәрләрендә сакланган өлешен өйрәнү эше әле башланып кына килә. Шуңа күрә әлеге кыска күзәтүдә Муса әфәндедән безгә мирас булып калган куен дәфтәрләре турында һәм аларның эчтәлеге турында тулы мәгълүмат бирү күздә тотылмый. Максатым ошбу «Әнвәр Хәйри укулары» дип аталган фәнни чарада катнашу форсаты белән милли мәдәниятебез вә тарихыбыз өчен әһәмиятле булган бу мирас турында бер хәбәр ишеттерү иде.

Алга таба, иншаллаһ, Муса Бигиевның куен дәфтәрләре турында җентекле тасвирлама язу, алардагы материалларның хәрефләтә күчермәсен булдыру, аларны хәзерге татар һәм урыс телләренә тәрҗемә итү ниятендәмен. Бу планнарым тормышка ашса, Муса әфәнденең куен дәфтәрләренә багышланган, аларның эчтәлеген тулаем чагылдырган һәм үз эченә дәфтәрләрнең һәр битенең фотосурәтен алган бер каталог дөнья күрер дип ышанып калам.

## ӘДӘБИЯТ

1. Хайрутдинов А.Г. Муса Джаруллах Бигиев. Казань: Изд-во «Фән» Академии наук РТ, 2005. 180 с.

**А.Г. Хайрутдинов**

## Записные книжки Мусы Джаруллаха Бигиева

*Аннотация.* Статья информирует о записных книжках из личной библиотеки Мусы Джаруллаха Бигиева и содержит их краткое описание.

*Ключевые слова:* Муса Джаруллах Бигиев, арабографичные рукописные источники, исламоведение, история ислама, исламская философия, история татарской религиозной мысли, история татарской общественной мысли.

**A.G. Khayrutdinov**

## Private notebooks of Musa Jarullah Bigiev

*Annotation.* The article informs about notebooks from a personal archives of Musa Jarullah Bigiev and provides a brief description of their contents.

*Keywords:* Musa Bigiev, Musa Jarullah, manuscript sources in Arabic script, Islamic studies, history of Islam, Islamic philosophy, the history of Tatar religious thought, the history of Tatar social thought.

**Автор турында мәгълүмат**

**Хәйретдинов Айдар Гарәфетдин улы –** фәлсәфә фәннәре кандидаты, ТФА Ш.Мәрҗани ис. Тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре (Казан шәһәре).

**Хайрутдинов Айдар Гарафетдинович –** кандидат философских наук, старший научный сотрудник Института истории им. Ш.Марджани АН РТ (г.Казань).

**Khayrutdinov Aydar Garafetdinovich** – candidate of philosophical sciences, senior researcher, Sh. Marjani Institute of History of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan (Kazan).

УДК 001(470.41)"18/19"

**Р.Ф. Шәфигуллина**

# МИЛЛИ МӘГАРИФ ҺӘМ МИЛЛИ ТӘРБИЯ КҮЗЛЕГЕННӘН КАЮМ НАСЫЙРИ МИРАСЫ

*Аннотация.* Мәкалә бөек татар мәгърифәтчесе, энциклопедияче галим Каюм Насыйриның гыйльми эшчәнлегенең методологик нигезләре, аның татар һәм рус мәдәниятләре арасында корган арадашлыкның үзенчәлекләре һәм фәлсәфәсе турында мәгълүмат бирә.

*Ачкыч сүзләр:* Каюм Насыйри, татар мәгърифәтчелеге, татар мәгърифәтчелеге тарихы, татар педагогикасы, татар педагогикасы тарихы, милли мәгариф, милли тәрбия.

Халкыбызның иң мәшһүр шәхесләреннән берсе Каюм Насыйри (1825–1902) күренекле мәгърифәтче, педагог, әдип, галим буларак билгеле. Ул Көнбатышның прогрессив фикере белән Шәрыкъ дөньясы казанышларын бергә үреп, үзара килештереп милләтебезнең рухи һәм интеллектуаль тормышында яңа дәвер башлап җибәргән, татар мәгърифәтчелеген яңа баскычка күтәргән галим.

Каюм Насыйриның киң колачлы мәгърифәтче булып җитешүенең нигезендә аның гаиләдә алган тәрбиясе һәм иң алдынгы татар мәдрәсәләрдә үзләштергән гыйлеме ята.

Габделкаюм бине Габденнасыйр (Каюм Насыйри) 1825 елның 2(14) февралендә Зөя өязе (хәзерге Татарстанның Яшел Үзән районы) Югары Шырдан авылында дөньяга килә. Әлеге авылга нигез салучыларның болгар ханнары токымыннан булулары турында галим горурлык хисләре белән яза. Аның нәсел шәҗәрәсе тарихның нәкъ әнә шул тирән катламнарына барып тоташа. Нәселләрен башлап җибәргән Быраш баба исемле танылган бер гаскәри, Казан ханлыгы дәверендә үк Идел елгасының Тау ягына килеп урнашкан була.

Быраш-бабаның варислары, шул заманнан алып берничә гасыр дәвамында җирле мөселманнарның абруйлы башлыклары, авыл старосталары һәм указлы муллалары буларак халыкка хезмәт иткәннәр.

Каюм Насыйриның Казандагы музеенда[11] галимнең үз куллары белән ясаган нәсел шәҗәрәсе саклана. Шәҗәрәдә Быраш-бабаның Казан ханнарына һәм Мәскәү кенәзләренә хезмәт иткән углы Габдерраззак мулла буынының ишле, күпсанлы вәкилләренең нәсел чылбыры чагылыш тапкан. Каюм Насыйри, үзенең данлыклы вә абруйлы бабасына ихтирам күрсәтү йөзеннән, кайбер хезмәтләрен «әр-Раззакый» дип тә имзалый торган була [Салихов, URL].

Шулай ук бөтен җаны-тәне белән туган төбәгенә һәм аның тарихына тирән ихтирам белән хезмәт итүче Каюм Насыйри, дөнья күргән әсәрләренең ахырына, ата-бабалары, туган җире алдында баш иеп һәм нәсел җебенең башлангыч чорына ишарә кылып: «Габделкаюм мелла Габденнасыйр углы, мелла Хөсәен углы, мелла Әлмөхәммәт углы, Йосыф углы, мелла Габделгазиз углы, Галикәй углы, мелла Габдерраззак углы, Габдулла әш-Шырдани әл-Болгари» дип тә имза куя.

Күрүебезчә, фән һәм гыйлемгә тартылу – Каюм Насыйрига затлы нәселеннән тапшырылган бүләк. Мәсәлән, аның бабасы Хөсәен бине Әлмөхәммәт Бәрәскә авылындагы (Татарстанның Әтнә районы) Сәгыйд бине Әхмәд мелланың данлыклы мәдрәсәсен тәмамлаган һәм XVIII гасырның икенче яртысыннан алып XIX гасыр башларына кадәр Югары Шырдан авылында имам вазыйфасын башкарган. Моннан тыш ул остазлык кылган, фәнни эзләнүләр алып барган һәм үзеннән соң шәкертләр арасында киң кулланылган гарәп синтаксисы (ән-нәхү) белән гарәп грамматикасы (әс-сарф) буенча хезмәтләр язып калдырган. Алар арасында, мәдрәсәләрдә төп дәреслек булып торган «Шәрхе Мелла», «Мисбах», «Сарфы Һаваи», «Гавамил» кебек китапларны атарга була. Болардан тыш, Хөсәен бабаның хөсне-хат сәнгате, ягъни матур язу осталыгына ия булганлыгы да, үз гомерендә берничә йөз Коръән күчереп язганлыгы да Каюм Насыйринең истәлекләрендә хәбәр ителә.

Ә инде Хөсәен бине Әлмөхәммәт бабаның угылы Габденнасыйр бине Хөсәен хәзрәт (Каюм Насыйриның әтисе), фәндә бик сәләтле булып, Казан каласында вә Бәрәскә белән Мәчкәрә

[11] Каюм Насыйриның Казандагы музее Татарстан Республикасының Милли музееның филиалы булып тора. Ул, Каюм Насыйриның Казанда, гомеренең соңгы елларын үткәргән нигездә, ягъни туганы Мөхәммәдбәдигъ Хөсәенов йорты урынында, Париж Коммунасы, 35 адресы буенча урнашкан. Мөхәммәдбәдигъ Хөсәенов илле сигез ел дәвамында «Галия»/«Галеевская» мәчетендә мөәзин вазыйфасын башкарган кеше.

(Татарстанның Кукмара районы) авылларының данлыклы мәдрәсәләрендә дини белем алган, «үзенең заманында, гаярь, үткен, бик зирәк адәм булган. Вә һәм урыс телен кәма һүә (тиешлечә – *Р.Ш.*) яхшы белгән». Әтисе кебек үк ул да гарәп теле теориясе белән тирәнтен шөгыльләнә, хат сәнгате һөнәренең чын остасы буларак китаплар күчереп яза. Шулай булса да, Габденнасыйр указлы мулла булырга омтылмый, бар вакытын һәм көчен туган авылына, авылдашларының мәнфәгатьләрен кайгыртуга багышлый. Каюм Насыйри язганча: «...заманасының атасыдыр, ягъни һәрбер мөптәла (бәлагә юлыккан. – *Р.Ш.*) кешегә вә аннан эстәп килгән адәмнәргә ата кебек шәфкатьчән булган адәмдер, шул сәбәпле, изгелекле вә изгелеге күп булган өчен, «Әбелхәер» (игелеклелекнең атасы – *Р.Ш.*) кушылган» [Гайнуллин, 1948, 5 б.].

Каюм Насыйри әтисенең дин өлкәсендәге рәсми дәрәҗәләргә салкын карашының, үзенең объектив сәбәпләре дә бар икән. Фән докторы Мәсгуд Гайнетдин күрсәтүенчә, К.Насыйриның әтисе Сәгыйд хәзрәтнең шәкерте булып торган. Каюм Насыйриның әнисе ягыннан якын туганнары – югарыда телгә алынган дамелла Сәгыйд бин Әхмәд һәм аның уллары – күренекле абызлардан булган [Гайнетдин, 2003, 8 б.].

Димәк, Каюм Насыйриның көчле шәхес, зур галим буларак өлгерүендә ата-бабасының тәэсире, нәселдән килгән сыйфатлар, туган йортта алган тәрбиясе мөһим роль уйнаганнар. Галим үзе язганча, эш сөючәнлек һәм максатка ирешүдә тырышлык күрсәтү әтисе биргән тәрбиянең нәтиҗәсе булган: «Һәр бәндәгә итҗиһат ләзем эш, дип балаларына даим ишеттерер иде».

Ата белән улының рухи бәйләнешен күрсәтеп торган ядкарьләр бүгенге көндә дә исән. Музейда Каюм Насыйриның әтисе Габденнасыйр хәзрәт яза башлаган «Утыз вәгазь» исемле китап саклана. Бу китапны, авторы тәмамлап өлгермәгәнгә күрә, аны, әтиләренең васыятен үтәп, уллары Габделкаюм белән Габделкави бергә язып тәмамлап, нәшер итеп чыгаралар.

Башлангыч белемне Каюм Насыйри төп нигездә заманасының иң укымышлы кешеләреннән берсе булган әтисеннән ала. 1841 елда Габденнасыйр мулла үзенең улы Габделкаюмны Казанга алып килә һәм Бишенче Таш мәчет («Галия» мәчете) мәдрәсәсенә сабак алырга бирә. Бу уку йортында Каюм Насыйри әтисенең остазы булган данлыклы галим Сәгыйд бин Әхмәд әш-Шырдани һәм, күрәсең, мәдрәсә буенча сабакташы (һәрхәлдә дамелла Әхмәд хәзрәтнең пишкадәм

шәкерте) булган Шәмсетдин бине Шәмсуар әл-Каструмави хәлфә җитәкчелегендә дини гыйлем ала. Гарәп, фарсы, төрек телләрен, үзлегеннән урыс телен өйрәнә. Бу уңайдан, яңадан профессор М. Гайнетдиновның сүзләренә мөрәҗәгать итик: «...Каюмның да урыс телен үзләштерүгә җитди игътибары, беренче чиратта һәм башлыча, урыс теле аша Аурпа мәдәниятенә якынайыйм яки «прикладной» фәннәр нигезләрен үзләштерим дип түгел, ә нәсел традициясен дәвам иттерү булган» [Гайнетдин, 2003, 7 б.].

Мөгаен, рус телен камил дәрәҗәдә белү сәбәпле Каюм Насыйрины мәдрәсәне тәмамлагач та 1855 елда Казан Рухани семинариясендә укытырга чакыралар. Биредә аңа татар теле дәресләрен алып бару эше йөкләнә. Шулай итеп, Каюм Насыйриның педагогик эшчәнлеге башлана.

Семинариядә булачак христиан руханиларына татар телен укыткан дәвердә Каюм Насыйри Русия һәм Көнбатыш мәгариф системаларында кулланылган алдынгы уку-укыту методик алымнары белән якыннан таныша. Ул алга таба ысулларны татар мәгарифенең теориясе һәм гамәли тәҗрибәсенә кертеп җибәрә. Бу үзенчәлек аның төрле фәннәргә караган дәреслекләрендә аеруча көчле чагылыш таба. Шул рәвешле, аның 1871 елда башлангыч белем бирә торган рус-татар дөньяви мәктәбен ачуы да галимнең яңа милли мәгариф концепциясен принципиаль рәвештә үзгә булган яссылыкка гамәлгә ашыра башлавының нәтиҗәсе булып тора.

Каюм Насыйри эшчәнлегенең колачы елдан ел киңәя. Аның галим һәм пропагандист буларак эшчәнлеге тирә-як дөньяның, яшәешнең, кешелек җәмгыятенең төрле өлкәләренә, күренешләренә, үзенчәлекләренә юнәлтелгән була. К.Насыйри химия, физика, гыйльме-н-нөҗүм (астрономия), геометрия, математика, география, медицина, тарих, ботаника, эпитафика, агрономия, музыка, тел белеме, әдәбият вә әдәбият белеме, генеалогия һ.б. фәннәре белән кызыксына. Моннан тыш Каюм Насыйри Казан император университеты каршындагы «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» эшендә катнаша. Күренекле тюрколог галимнәре (В.В.Григорьев, Н.Ф.Катанов, В.Д.Смирнов) аңа югары бәя бирә. Бу эшчәнлекләрнең нәтиҗәләре – татар мәдәниятенең, мәгарифенең, дини һәм фәнни фикеренең алга таба үсешенә нигез булган күпсанлы фәнни-гамәли китаплары.

Мәгърифәтче татар милләтенен бай рухи дөньясы зиннәтләрен, күпкырлы, борынгы тарихи ядкарьләрен барлап, туплап рус һәм көнбатыш зыялыларына таныта. Шул ук вакытта татар халкын дөнья мәдәниятенең, аерым алганда Россия һәм Ауропада булган иң алдынгы күренешләр белән таныштыра.

## ӘДӘБИЯТ

Гайнетдин М. Каюм Насыйри: шәхес һәм иҗат // Насыйри Каюм. Сайланма әсәрләр. 4 томда, 1 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 368 б.

Гайнуллин М. Каюм Насыйри (тормыш һәм иҗат юлы) // Насыйри Каюм, 1825–1945: тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары. – Казан: Татгосиздат, 1948. – 3–40 б.

Салихов Р.Р. Участь первопроходца (Каюм Насыри). URL: http://tatarica.narod.ru/cult/biographies/science/kayum.htm

**Р.Ф. Шафигуллина**

# Наследие Каюма Насыри с точки зрения национального образования и национальной педагогики

*Аннотация.* Статья информирует о методологических основах научной деятельности выдающегося татарского просветителя Каюма Насыри, о его философии межнациональных взаимоотношений и особенностях построения межцивилизационного диалога между татарской и русской культурами.

*Ключевые слова:* Каюм Насыри, татарское просветительство, история татарского просветительства, татарская педагогика, история татарской педагогики, национальное образование, национальное воспитание.

**R.F. Shafigullina**

# The legacy of Qayum Nasyri from the point of view of national education and national pedagogy

*Annotation.* The article informs about the methodological foundations of scientific activity of the prominent Tatar enlightener of Qayum Nasyri, about his philosophy of inter-ethnic relationships and characteristics of building inter-civilizational dialogue between Tatar and Russian cultures.

*Keywords:* Qayum Nasyri, Tatar enlightenment, the history of Tatar enlightenment, Tatar pedagogy, the history of Tatar pedagogy, national education.

**Автор турында мәгълүмат**

**Шәфигуллина Раушания Фаил кызы** – филология фәннәре кандидаты, Каюм Насыйри музее директоры (Казань шәһәре); e-mail: raushani@list.ru

**Шафигуллина Раушания Фаиловна** – кандидат филологических наук, директор музея Каюма Насыри (г. Казань).

**Shafigullina Raushaniya Failovna** – candidate of philological sciences, Director of Qayum Nasyri Museum (Kazan).

# Ә.Хәйри язмалары һәм хезмәтләренең библиографик күрсәткече

УДК 929=512.145"19/20"(470.41)

**Әнвәр Хәйри**

## ТӘРҖЕМӘИ ХӘЛЕМ

Мин, Әнвәр Нәҗип улы Хәйруллин (Хәйри), 1947 елның 2 декабрендә Татарстан Җөмһүриятенең Аксубай районы Шәрбән авылында гади колхозчылар гаиләсендә 8 нче бала булып дөньяга килгәнмен. 1954 елда укырга кереп, 1962 елда Шәрбән авылы сигезьеллык мәктәбен тәмамладым. 1958–62 елларда, җәйге каникулларда колхозның ат көтүен көттем. Атлар һәм китап укырга ярата идем. 4 сыйныфны тәмамлаганда авыл китапханәсенең һәм мәктәп китапханәсенең бөтен китапларын укып бетергән идем инде. 1962 елның көзендә Аксубай урта мәктәбенә укырга керсәм дә, ноябрь ае каникулына кадәр укыгач, укуны ташлап, мин 1963 елның язына кадәр Аксубай урман хуҗалыгында урман кисүче булып эшләдем. 1963–66 елларда үз авылымда – «Большевик» күмәк хуҗалыгында тракторчы ярдәмчесе һәм комбайнчы ярдәмчесе булып эшләдем. 1963 елда укырга кереп 1966 елда Татарстанның Октябрь, хәзерге Нурлат районы Колбай-Мораса авылы урта мәктәбен тәмамладым. Әдәбиятка һәм тарихка мәхәббәтем шул мәктәптә формалашты. 1966 елда Казан театр училищесына укырга кердем. 1967 елда Казан дәүләт университеты тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кереп, аны 1973 елда тәмамладым. 1969 елның сентябреннән читтән торып уку бүлегенә күчеп Казан шәһәренең 80 нче мәктәбендә гарәп теле укытучысы булып эшли башладым һәм 1974 елның май аена кадәр шунда эшләдем. 1969 елның көзеннән бер үк вакытта Татарстанның дәүләт музеенда борынгы кулъязмалар буенча фәнни хезмәткәр булып эш-

ли башладым һәм анда 1974 елның май аена кадәр эшләдем. Матбугатта беренче язмаларым 1960 еллар ахырында, 1970 еллар башында күренә башлады. 1974 елның май аеннан 1991 елның ноябрь аена кадәр СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының иҗтимагый фикер тарихы бүлегендә фәнни хезмәткәр булып эшләдем. 1991 елның ноябрь аенда, борынгы чыганаклар белән эшләүче тәҗрибәле белгеч буларак, мине «Мирас» журналын оештыру өчен шул журнал редакциясенә эшкә күчерделәр һәм анда мин баштан тарих, фәлсәфә һәм рухи мирас бүлеге мөдире, аннан соң җаваплы сәркатиб, баш мөхәррирнең беренче урынбасары, ә соңыннан ислам динен өйрәнү бүлеген оештыргач, 1995 елның июль аена кадәр, ягъни журналдан киткәнче, шул бүлекнең мөдире булып эшләдем. 1995 елның июленнән 1996 елның июненә кадәр Казандагы «Синдикат» акционерлар җәмгыятендә «Рухи яңарыш» фонды директоры булып эшләдем. 1996 елның июненнән Татарстан Милли китапханәсендә гыйльми сәркатиб, баш библиотекарь, аннан соң директор урынбасары булып эшләдем. Хәзерге вакытта Милли китапханәнең сирәк китаплар һәм борынгы кульязмалар бүлегендә баш фәнни хезмәткәр булып эшлим. 1970 елдан башлап, төп эшем белән бер үк вакытта: Казан дәүләт университетында, Казан дәүләт педагогия университетында, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында, Казан дәүләт медицина университетында, Казан авыл хуҗалыгы академиясендә, Татар укытучылар белемен күтәрү институтында, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында, Татар дәүләт көллиятендә (соңыннан Татар гуманитар институты), Укытучылар йортында һәм башка уку йортларында гарәп телен, иске татар телен, рухи мәдәниятебез тарихын, ислам дине тарихын, халык медицинасы тарихын, халык педагогикасы тарихын укыттым. 1986 елның октябреннән 1996 елның июнь аена кадәр Татарстан Милли китапханәсенең фәнни киңәшчесе булып эшләдем. 1974 елдан башлап Татарстан Милли музееның Гыйльми совет әгъзасы буларак та эш алып барам.

2006 елның декабрендә мине БМО ның берләштерелгән әгъзасы – Халыкара Мәгълүматлаштыру академиясенең академигы итеп сайладылар.

2010 елның декабрендә мине Санкт-Петербургтагы Петр I исемендәге Фәннәр һәм Сәнгатьләр академиясенең академигы итеп сайладылар.

2007 елның маенда мине «Россия ислам мирасы» исемле Бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Совет әгъзасы итеп сайладылар.

2008 елның февралендә мине «Россия ислам мирасы» исемле Бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан бүлеге Советы рәисе итеп сайладылар.

Минем тарафтан XIX–XX гасыр татар мәгърифәтчеләренең һәм әдипләренең күптөрле китаплары тәрҗемә ителеп басылып чыкты. Аларның кайберләре – аерым китаплар булып, кайберләре – баштан журнал басмасы булып һәм соңыннан тагын китап булып, кайберләре – бер җыентык китап эчендә берничә китап булып басылып чыктылар. Менә шуларның барысын бергә исәпләгәндә, гомуми саны 86 га җитә. Шуларның 8-е – үзем язган, автор китаплары:

1. Әнвәр Хәйри. «Шәһри Бану – Шәрбән кыйссасы» (Борынгы болгар шәһәре – Шәһре Бануның (Шәрбәннең) нигезләнүенә 1100 ел тулуга багышлап). Яр Чаллы, 1996. 59 б.

2. Әнвәр Хәйри. «Ислам дине бәйрәмнәре». Казан, 1996. 72 б.

Бу китап – Татарстан радиосыннан тулысынча халыкка да җиткерелде.

3. Әнвәр Хәйри. «Ризаэддин бине Фәхреддин әсәрләрендә тәрбия – әхлак мәсьәләләре». Әлмәт муниципаль институтында басылды. Әлмәт, 2004. 27 бит.

4. Әнвәр Хәйри. Борынгы Татар Бизнәсе авылы тарихы (Рөстәм Бакиров. «Безнең тамырлар Бизнәдә» исемле китап эчендә). Казан, 2011. 560 бит.

5. Әнвәр Хәйри. 921–922 елларда Болгар дәүләтенә сәяхәте вакытында язган Ибне Фадлан китабы. Китапны татар теленә тәрҗемә итүче, компьютерда гарәпчә басма текстны басучы һәм кереш сүзне эшләүче Әнвәр Хәйри. Китап «Сүз» нәшриятында 2012 елда Болгардагы Коръән залы өчен кыскартылып басылып чыкты, күләме 150 бит.

6. Анвар Хайри. Повествование о путешествии Ибн Фадлана во время поездки в Булгарское государство в 921–922 годах. Книгу перевел на русский язык, отпечатал на арабском языке на копьютере полный текст рукописи и написал вводное слово Анвар Хайри. Книга издана в сокращенном варианте в издательстве «Слово» в 2012 г., для Коранного зала в Булгаре, объемом 150 страниц.

7. Әнвәр Хәйри. 921–922 елларда Болгар дәүләтенә сәяхәте вакытында язган Ибне Фадлан китабы. Китапны татар теленә тәрҗемә

итүче, компьютерда гарәпчә басма текстны басучы һәм кереш сүзне, кушымталарны эшләүче Әнвәр Хәйри. Китап «Сүз» нәшриятында 2013 елда басылып чыкты, күләме 532 бит.

8. Анвар Хайри. Повествование о путешествии Ибн Фадлана, написанное во время поездки в 921–922 годах в Булгарское государство. Книгу перевел на русский язык, отпечатал на арабском языке на компьютере полный текст рукописи и написал вводное слово, сделал приложения Анвар Хайри. Книга издана в издательстве «Слово» в 2013 г., объемом 512 страниц.

Шул сериядән тагын 2 китап нәшриятта басылуны көтеп яталар. Шулар өстенә 750 ләп фәнни хезмәтләрем матбугатта басылганнар, шул исәптән 132 се – фәнни һәм фәнни–популяр җыентыклардагы мәкаләләр; 289 ы – фәнни мәкаләләр, тәрҗемә ителгән һәм текстологик эшкәртүләр узган хезмәтләр төрле үзәк һәм җирле журналларда; 240 ы – төрле газеталарда басылган фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләр.

Бу фәнни хезмәтләр бик күп мәсьәләләргә, шул исәптән тел тарихы, әдәбият тарихы, татар халкы тарихы, Идел буенда ислам тарихы, мәдәният тарихы, сәнгать тарихы, татар халык медицинасы тарихы, халык педагогикасы тарихы, татар халкының иҗтимагый фикер тарихы, татар язу тарихы, татар халкының рухи мәдәнияте тарихы, татар авыллары тарихы, Уфадагы Диния Нәзарәте тарихы, татар халык этнографиясе, кабер ташлары, Коръән Кәримнең тәрҗемәләре һәм аны матбугатка әзерләү, XIX–XX гасырларның мәшһүр татар мәгърифәтчеләре һәм әдипләре Г.Курсави, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Р.Фәхретдин, М.Бигиев, З.Камали, Г.Ибраһимов, Р.Гайнетдин, Г.Акыш, Г.б.Сөләйман, Низаметдин, М.б.М.Йортыши, М.Х.б.Хөсәен һәм башкаларның иҗат мирасларын өйрәнүгә һәм аларны гаять авыр катнаш телләрдән аңлатмалы (аннотацияле) тәрҗемә итеп яңадан халыкка кайтару кебек мөһим мәсьәләләргә багышланганнар.

Минем тарафтан Ш.Мәрҗанинең «Мөстафадел – әхбар...» дигән ике томлы тарихи хезмәте (тиражы – 50000 данә) Казанда 1989 елда, Р.Фәхретдиннең «Болгар вә Казан төрекләре» исемле китабы (тиражы – 25000 данә) Казанда 1993 елда, шул ук китабы латин хәрефләрендә (тиражы – 500 данә) Казанда 1997 елда, Ш.Мәрҗани һәм Р.Фәхретдин китаплары өзекләренең тәрҗемәләре – «Татар тарихы: онытылмас сәхифәләр» исемле китапта. Казан, 1994 ел, 38–96, 212–246 б.б. тиражы – 20000 данә: «Ислам дине – нинди дин?»,

«Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр», «Нәсыйхәт – 1», «Нәсыйхәт – 2», «Нәсыйхәт – 3», «Тәрбияле бала», «Әһле гыяль», «Шәкертлек әдәпләре», «Укыту кагыйдәләре», «Тәрбияле ана», «Тәрбияле хатын», «Гаилә» китаплары; К.Насыйри, М.Бигиев, З.Камали, Г.Ибраһимов, Р.Гайнетдин, Г.Акыш, Г.б.Сөләйман, Низаметдин, М.б.М.Йортыши, М.Х.б.Хөсәен һәм башка мәгърифәтчеләрнең һәм әдипләрнең хезмәтләре тәрҗемә ителеп матбугатта басылдылар.

Бик күп республика, бөтенсоюз, бөтенроссия һәм халыкара фәнни конференцияләрдә катнашып, татар иҗтимагый фикер тарихы, ислам дине тарихы, татар халкының халык медицинасы тарихы, татар халкының педагогика тарихы һәм башка мәсьәләләр буенча чыгышлар ясадым.

Бер үк вакытта төрле очерклар һәм публицистик мәкаләләр язу белән дә шөгыльләнәм. Татарстан радиосының «Балкыш» тапшыруында һәм «Яңа гасыр» радиосында даими рәвештә тәрбия – әхлак мәсьәләләренә багышланган чыгышлар ясадым.

Бер үк вакытта мин милли тарихыбызга караган иң борынгы һәм иң беренче язма чыганак булып торучы – 922 елда Идел буе Болгар дәүләтенә ислам динен рәсми дәүләт дине итеп игълан итәргә килгән илчелекнең җаваплы сәркатибе Әхмәд Ибне Фадланның сәяхәтнамәсен төп нөсхә кульязмасының факсимиле күчермәсеннән турыдан–туры борынгы – классик гарәп теленнән бүгенге татар һәм рус телләренә тәрҗемә итеп, фәнни эшкәртеп матбугатка әзерләү белән шөгыльләндем. Текстның глоссариен – сүзлеген төзеп, татар һәм рус телләрендә тәрҗемә текстны эшләп, фән тарихында әле беренче тапкыр кульязма китапның басма текстын гарәпчә басып куйдым. Бик четерекле фәнни аңлатмалар язуны төгәлләп, татар һәм рус телләрендәге бу олы хезмәтемне 750 шәр битле 2 томда, барысы 1500 битлек күләмдәге кульязмамны 2011 елның 1 сентябрендә «Сүз» нәшриятына тапшырдым.

2013 елның март ае башында бу ике монография әйбәт кенә басылып чыктылар, татар телендәгесе – 532 бит, рус телендәгесе – 512 бит. 24 мартта Татарстан Республика Фәннәр академиясенең Кече залында бу китапларны зурлап тәкъдим итү мәҗлесе булып узды һәм шунда бу хезмәтләргә бик югары бәя бирелде... Татарстан Республика Фәннәр академиясе канцеляриясе аркылы алар 35 илнең илчелекләренә һәм әйдәп баручы университетларына җибәрелделәр. Болардан тыш, алар бүләк итеп Австралия, Кытай, Төркия һәм дөньяның башка илләренә җибәрелделәр.

Хәзерге вакытта мин Ризаэтдин Фәхретдиннең төп нөсхә китаплары белән параллель рәвештә үзем тәрҗемә иткән китапларын туплап 21 китаптан, 9 томнан торган сайланма хезмәтләрен һәм үземнең аның иҗаты турында язган язмаларымны кушып, барысы 10 том хезмәтне матбугатка әзерләү һәм бастыру чарасын күреп йөрим. Аллаһы Тәгалә көч һәм дәрт биреп торсын иде!...

Бер үк вакытта аерым кешеләргә һәм вакыйгаларга багышланган очерклар һәм публицистик мәкаләләр дә язам...

1991 елда Татарстан ССР Югары Советы Указы белән мәдәният өлкәсендәге казанышларым өчен миңа **«Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

1999 елның 28 октябрендә Татарстан Президенты Указы белән күпьеллык нәтиҗәле фәнни-тикшеренү һәм мәгърифәтчелек эшчәнлегем өчен миңа **«Татарстанның атказанган фән эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

1994 елда Кол Гали исемендәге Халыкара бүләк бирү Комитеты карары белән татар халкының күп гасырлык рухи һәм тарихи-мәдәни мирасын халкыбызга яңадан кайтарып бирү өлкәсендәге уңышларым өчен миңа **«Кол Гали исемендәге Халыкара бүләк»** тапшырылды.

2004 елда милли мәгарифне үстерүдәге казанышларым өчен **Республиканың Каюм Насыйри исемендәге премиясе** бирелде.

2005 елның 31 мартында **Татарстан Республикасының Язучылар Берлеге әгъзасы** итеп кабул ителдем.

2007 елның 8 июлендә Татарстанның «Сәләт» яшьләр хәрәкәте эшендә күпьеллык нәтиҗәле эшчәнлек алып барганым һәм бу оешманың барлыкка килүендә эчкерсез ярдәмем өчен Татарстанның «Сәләт» яшьләр хәрәкәтенең иң югары бүләге – **Алтын күкрәк билгесе** белән бүләкләндем.

2007 елның 2 декабрендә, татар халкының тарихи һәм мәдәни мирасын саклауда үземнән лаеклы өлеш керткәнем, үсеп килүче яшь буынга күп еллар дәвамында әхлак тәрбиясе биргәнем һәм татар халкының үзаңын үстерү юнәлешендә актив эшчәнлегем өчен **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт Хаты** белән бүләкләндем.

2007 елның 2 декабрендә, дини әхлакны, дин әһелләренең тормышын һәм иҗатын өйрәнүдәге фәнни хезмәтләрем өчен, әдәби

иҗат өлкәсендәге уңышларым өчен **Татарстан Республикасының Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт Хаты** белән бүләкләндем.

2007 елның 28 декабрендә, халыкны әхлакый тәрбияләү өлкәсендәге фәнни әдәбиятне үстерүдәге казанышларым өчен **Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасының Язучылар берлегенең проф. Җамал Вәлиди исемендәге әдәби премиясе** тапшырылды.

2008 елның 29 маенда, мәдәният өлкәсендәге казанышларым һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтем өчен Россия Президенты Указы белән **«Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

2009 елның 18 июнендә, хакыйкать юлындагы гадел гамәлләрем, тормышыбызга Ислам дине кыйммәтләрен кертүне актив пропагандалаганым, хәзерге яшьләрне дини гореф-гадәтләр һәм дини йолалар рухында тәрбияләгәнем өчен, яшьләребездә күпмилләтле Ватаныбызга карата ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләгәнем өчен **Бөтенроссия «Россия Ислам мирасы» иҗтимагый хәрәкәтенең дипломы** белән бүләкләндем.

2011 елның 24 августында, тәрбия өлкәсендә укыту-методик ярдәмлекләр һәм үзенчәлекле фәнни хезмәтләр язган өчен Татарстан Республикасы Президенты Указы белән яңа гына гамәлгә куелган премия – Татарстан Республикасы Премьер-Министры карары белән **Ризаэддин Фәхреддин исемендәге Республика Хөкүмәте премиясе** тапшырылды.

2013 елның 8 февралендә, әдәбият һәм сәнгать үсешенә керткән зур өлешем өчен **Татарстан Республикасының мәдәният министрлыгының «Мәдәнияттәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе** белән бүләкләндем.

2013 елның 9 апрелендә, нәтиҗәле фәнни-тикшеренү эшчәнлегем, мәгариф системасының үсешенә һәм яшь буынны тәрбияләүгә керткән шәхси өлешем һәм күпьеллык намуслы хезмәтем өчен **Татарстан Республикасының фән һәм мәгариф министрлыгының «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе** белән бүләкләндем*.

---

* Әнвәр Хәйри 2015 елда Петр I исемендәге Фәннәр һәм Сәнгатьләр Академиясенең Михаил Шолохов исемендәге премиясе лауреаты исеменә лаек була. – Прим. ред.

УДК 929=512.145"19"(470.41)

**Әнвәр Хәйри**

# ХАТИРӘЛӘР ЯҢАРГАНДА. НИЧЕК ИТЕП МИН 466 ТӨРКЕМНЕҢ КИЯВЕ БУЛЫП КИТТЕМ…

Тарих мең дә тугыз йөз дә алтмыш җиденче сәнәдә мин – Казан театр училищесының узган елгы шәкерте, яңадан имтихан биреп Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетындагы татар теле һәм әдәбияте бүлегенә укырга керү бәхетенә ирештем. Мин бала вакыттан бик күп китап укып үстем, миңа «китап җене кагылган» иде. Шул укылган китапларның да файдасы тигәндер бәлки, аннан соң, минем мәктәптәге укытучыларым да искиткеч әйбәт, үз эшләренә бирелгән, тирән белемле һәм үз белгәннәрен безгә дә бирә белә торган фидакарь шәхесләр иде. Аларның күбесе хәзер мәрхүмнәр инде... Мин аларның рухына: «Миңа белем биргән барлык остазларымның рухлары шат булсын иде, каберләре якты, нурлы булсын иде, дөньяда бәндәчелек белән белеп һәм белмичә кылган хата-кимчелекләрен, ялгышларын, гөнаһларын Аллаһы Тәгалә гафу итеп, җаннары Фирдәвес җәннәте түрендә булырга насыйп итсен иде!» дип Коръәни Кәрим укыгач һәм намазларымнан соң дога кылам...

Остазларыбыз безне укырга гына һәм тирән белемле булырга гына өйрәтмәделәр, алар, безгә биргән белемнәре өстенә, безне югары әхлаклы, намуслы, тугрылыклы, ярдәмчел, эшчән, сабыр булырга да, авырлыкларга түзә белергә дә, кыскасы, һәркемне мөстәкыйль тормыш корып яши алырлык итеп тәрбияләделәр, белмәгән нәрсәләрне өйрәттеләр...

Казан шәһәренең Кызыл Позиция (Красная Позиция) урамында урнашкан Казан дәүләт университетының 2 нче тулай торагының 13 нче бүлмәсенә урнашып яши башлагач (Актаныш районының Чишмә колхозына барып көзге басу эшләренә булышып кайткач) һәр көнне безнең бүлекнең укытучылары-профессорлары Ибраһим ага Нуруллин, Вахит абый Хаков, Сәгадәт абый Ибраһимов, Мостафа абый Ногманов, Зәет абый Мәҗитов, Алмазия апа Нуриева, Флера апа Сафиуллина, Флера апа Гыйльманова, аспирантлар Фәһимә апа Хисамова, Хатиб абый Миңнегулов, Шәйхи абый Садретдинов һәм башка укытучылар чиратлашып, берәм-берәм

кичләрен тулай торакка безнең янга килеп барыбызны да барлап, тәртипләребезне тикшереп, дәресләребезне әзерләтеп китәләр иде. Аларның барысы да безнең бүлмәгә кереп чишенеп, бүлмәләрне тикшереп чыгалар иде дә, без йокларга ятканчы, ягъни төнге сәгать 11 ләргә кадәр утыралар, белмәгән әйберләребезне аңлаталар, безнең өчен бик күп кызыклы мәгълүматлар сөйлиләр иде. Кызыл почмакта күренекле кешеләр белән очрашулар үткәрәләр иде. Алар шулай итеп беренче семестр беткәнче, без тәмам укуга бирелеп, кереп киткәнче безнең белән шөгыльләнделәр, вакытларын да, кайберләре (мәсәлән, Ибраһим абый Нуруллин Бөек Ватан сугышы инвалиды булуына карамастан) сәламәтлекләрен дә кызганмыйча, безне үз балалары кебек үз итеп, әле генә авыллардан килгән һәм тормыш тәҗрибәләре бөтенләй булмаган яклаучысыз-саклаучысыз балаларны төрле көтелмәгән хәлләрдән һәм төрле бозык юлларга кереп китүдән саклап, үзләрен чын укытучы-тәрбиячеләр, олы йөрәкле, кешелекле, мәрхәмәтле, чын зыялы кешеләр итеп күрсәттеләр. Без аларны үзебезнең иң якын кешеләребез итеп күрә идек, төрле киңәшләр сорый идек һәм кайвакытта бик нык кысып тотсак та акчаларыбыз калмаганда, алар безгә матди ярдәм дә күрсәтәләр иде...

Актаныш районыннан эштән кайтып укый башладык. Беркөнне мин гадәтемчә, элек бергә укыган дусларым янына Казан театр училищесына киттем, кочаклашып-күрешеп сөйләшеп утырганнан соң мин китәргә җыендым. Дамирә дустым Кузаева (Соңыннан Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты булды, хәзер инде күптән вафат, урыны җәннәттә булсын иде!...) Пермь өлкәсе Барда районының Барда урта мәктәбендә бер караватта йоклап укыган сабакташы Альмира Аптуковага бер кечкенә генә хат кисәге язып биреп, ул хатны аңа тапшыруымны үтенде. Тулай торакка кайткач ук, мин хатны өченче катка, Альмира бүлмәсенә меңгердем, ләкин аларның ишекләре бикле булды.

Мин бүлмәмә төшеп шактый көтеп утырсам да мине сорап керүче булмагач, тулай торак астында урнашкан юыну бүлмәсенә төшеп душта коенып-юынып мендем һәм дәресләремне әзерләргә утырдым. Бервакыт ишек шакыдылар, мин «Керегез!» дип эндәшкәч ишек ачылды һәм: «Син беренче кер!», «Юк, син кер!» дип бер-берсенә карап елмаешып ике кыз басып торганын күргәч, үзем ишек янына барып: «Кызлар, бүлмәгә керегез, ишек төбендә торсагыз үсмәссез» дидем. Алар керделәр, Дамирәнең амәнәтен

тапшырдым һәм бераз сөйләшеп утырдык. Альмира Дамирә янына училищега килеп йөргәнгә күрә, миңа ул таныш булып чыкты, ә аның белән бергә кергән дус кызы – бер караватта аяклы-очлы йоклый торган Рая Закирова булып чыкты. Бик ачык, күңелле кызлар булып чыктылар...

Шулай бер-беребезгә китаплар, кирәк әйберләр сорап, кайвакытта сәбәпсез дә, сөйләшеп утырыр өчен генә дә кергәләп, аннан соң инде тагын да ешрак керешеп йөри башладык. Буш вакытларыбызда бергәләп киногa, театрга, Үзәк ял паркына, Аэропортка барып кайта торган булдык, шулай итеп, без Альмира белән дуслашып та киттек.

Минем хәтерем бик көчле иде, укыган китапларны юлын-юлга яттан сөйли торган идем. Тулай торакның дүртенче катында зур гына китапханә һәм уку залы бар иде. Анда укырга, дәресләрне әзерләргә шактый кеше йөри торган иде. Альмира белән без дә шунда кереп утырабыз һәм иртәнге сәгать дүрткә кадәр укып утыра идек, төн буена мин гарәп телен өйрәнәм, Альмира үз дәресләре белән утыра, ял иткәндә мин аңа үзем укыган әдәби әсәрләрне яттан сөйлим... Шулай итеп, бергәләп белемнәребезне тирәнәйтеп утырулар ешая башлады.

Беренче курстагы кышкы сессиянең соңгы имтиханнарын тапшырып йөргәндә авылдан этидән ашыгыч телеграмма алдым. Анда кыска гына: «Әниең авыр хәлдә, тиз арада кайтып җит!» диелгән иде. Мин имтиханымны ничек биргәнемне дә хәтерләмим, очып дигәндәй тулай торакка кайтып җиттем дә, юлга җыена башладым. Үч иткәндәй, акчаның да беткән чагы туры килде, чөнки миңа – француз теленә йөрмичә үз теләгем белән гарәп телен өйрәнү дәресләренә йөргәнем өчен, деканатыбыз секретаре Нурия Мортазовнаның «тырышлыгы» белән, беренче курс тәмамланганчы бер тиен дә стипендия түләмәү шарты белән генә университеттан куылмыйча калган ач шәкерткә һәм атна саен шимбә, якшәмбе көннәрендә иртән бер шешә кефир эчеп китеп алтмышар тонналы күмер, цемент бушатып, тоннасына бер сум исәбеннән акча эшләп уку бәхете тигән иде. Сессия вакытында вагоннар бушатырга да йөреп булмады. Шуңа күрә, ерак юлга чыгарга түгел, трамвайга түләргә дә рәт юк чак... Кемнән булса да бурычка да сорап булмый, сессияләрен тапшырган барлык студентлар әти-әниләре янына кунакка, каникулга кайтып бетеп баралар.

Үз көнемне үзем күреп яшәргә өйрәнгән кеше буларак, мин беркайчан да кызлардан акча сорамый идем... Ә монда чарасызлыктан берни эшләп булмый, кая барасың, авыру әни янына кайтырга кирәк... Аннан соң, мин бик оялчан бала булып үстем, мине мәктәптә дә, оялганым өчен кызлар һәрвакыт үртиләр иде, миңа берәрсе туры караса, мин җир тишегенә кереп китәрдәй булып, колакларыма кадәр кызарып чыга идем. Ә монда оялмыйча акча сорарга кирәк, ләкин ничек итеп сорарга менә!... «Битемә чабата каплап» дигәндәй, чарасызлыктан оятымны каядыр качырып торып, Альмира янына кердем. Сүземне башлый алмыйча интегеп беттем. Ул минем бик борчылганымны йөземнән үк күреп алыптыр инде, «Әнвәр, нәрсә булды сиңа, бөтенләй төсең калмаган, ап-ак булгансың, берәр кайгың бармы әллә?» дип сорап куйды. Мин дәшмичә генә аңа телеграмманы күрсәттем. Ул да бик хафаланып: «Ай, Аллам, кайчан китәсең, юлга акчаң бармы соң?» дип минем күзләремә карады. Мин сүзсез генә «Юк!» дип башымны чайкадым. Ул урыныннан сикереп торып карават астындагы яшел чемоданын тартып чыгарды да, кулъяулыкка төрелгән бер төргәк акча алып минем кулыма тоттырды. «Мә, юкка аптырап йөрмә, хәзер үк юлга әзерлән, әйдә, үзем дә булышам» дип мине кулымнан тотып кибеткә алып керде һәм бик күп күчтәнәчләр алдырды. Самолетка билет алышып, «Әниең исән-сау булсын, мин теләп торырмын, үзең дә исән-сау гына йөреп кил, яме!» дип аэропортта озатып калды. Аның да әти-әнисе янына кайтасы булгандыр инде, ләкин ул, минем ул акчаны аласым килмичә ничек кенә карышсам да, бөтен акчасын миңа тоттырып җибәреп, минем өчен үзе каникулны тулай торакта уздырган иде...

Мин күп итеп күчтәнәчләр алып тиз арада кайтып җиткәч, әниемнең ничек шатланганын үзем генә беләм, мин аны район табибларына күрсәтеп йөреп, аякка бастырып калдырып, укуыма бераз соңга калып та бардым... Акча турында кызыксынгач, әнигә кем ярдәм иткәнен сөйләдем дә, ул шаккатып: «И-и улым, бигрәк мәрхәмәтле, кешелекле бала икән, кешенең кемлеге авыр вакытта сынала, җирдә менә шундый кешеләр күбрәк булсын иде, туры килгәндә үзең дә ярдәм ит аңа!...» дип изге теләкләрен теләп, дога кылып куйды.

Мин ишле гаиләдә, сигезенче бала булып, 1947 елда, әтигә 41, әнигә 40 яшь тулгач дөньяга килгәнмен, миннән соң әле Нурия сеңелем бар, аны әни 42 яшендә тудырган. Әти-әни гомерләре буена

динне бик нык тоттылар, дин иң кысылган, иң эзәрлекләнгән вакытта да һәм «намаз укымыйлармы икән?» дип кайбер куштан авыл укытучылары йорт саен тикшереп йөргәндә дә, качып-посып булса да биш вакыт намазларын, һәм нинди авыр елларда да уразаларын калдырмыйча тотып, кыскасы, мөмкин булган барлык дини бурычларын булдыра алган кадәр үтәп яшәделәр һәм безне дә дин кысаларында тәрбияләп, «бусы гөнаһ, тегесе оят...» дип үстерделәр. Моның өчен аларга мең-мең рәхмәт, әлбәттә... Урыннары җәннәттә булсын иде!...

Аннан соң, безнең гаиләдә, авырып урын өстендә ятмаган һәркем – зурмы син, кечкенәме син, үзеңнең көчең җиткән хезмәтне җиренә җиткереп эшләргә һәм эшсез эленке-салынкы йөрмәскә тиеш идек. Шунлыктан, кушканны, әйткәнне көтеп тормыйча, бер тапкыр кушып күрсәтеп биргән эшне үзебез белеп эшләргә тиеш идек. Урамда бушка вакыт уздырып уйнап йөрү ярамый иде. Кыскасы, без теләсә нинди эшне, хәтта көчебез җитмәс авыр эшләрне дә җиренә җиткереп эшләргә өйрәнеп, эшкә пешеп үстек. Бу сыйфат миңа үз гомеремдә бик тә ярап куйды. Нинди генә эшкә алынсам да, аны җиренә җиткермичә туктамый идем...

Үскәндә безне көндезләрен дә, кичләрен дә урамга, клуб тирәсенә һәм клубка чыгарып йөртмиләр иде. Шуңа күрә, кызлар белән генә түгел, хәтта үземнең яшьтәш малайлар белән дә, мәктәптәге аралашуларны санамасаң, аралашу тәҗрибәсе бик аз иде. Шунлыктан миндә, хәзерге тел белән әйтсәң, бер комплекс, кешедән оялу һәм аралаша белмәү комплексы үсеп-яшәп килде һәм ул сыйфат миңа гомерем буе бик нык комачаулады. Шул сәбәпле, мин тормышта бик күп нәрсә югалттым, үзем теләгән бик күп нәрсәгә ирешә алмадым... Мин берәр кеше белән, бигрәк тә берәр кыз белән сөйләшә башласам, оялып кызарып, тирләп чыга идем һәм сөйләр сүзләрем бик күп булса да, каушаудан бөтенесен онытып бетерә идем. Китаплар укыганда бөтен китапларны хәтергә сеңдереп, тулысынча яттан сөйли ала торган булсам да, имтиханнарда каушап коелып төшәм дә – бар белгәнемне онытам, бераз утыргач яңадан барысы да искә төшсә дә, «ялгыш берәр сүз әйтеп куярмын да, оятлы булырмын», дип башны аска иеп утыра идем, укытучылар минем күп укыганны һәм күп белгәнне белгәннәренә күрә, төрле ысуллар белән аны тартып чыгаралар иде...

Шул кышкы каникулдан соң без Альмира белән тагын да ныграк дуслаша төшеп, тора-бара әлеге оялчан, самими балалык дуслыгы –

зур хискә, мәхәббәткә әйләнеп китеп, без һәркайда, һәрвакытта бергә була торган идек. Атна саен Альмираның апасы белән җизнәсе эшли һәм яши торган Биектау районының Ямаширмә авылына, Венера апа белән Феликс абыйга кунакка кайта идек. Алар икесе дә институтны тәмамлап, шул авылга юллама белән эшкә җибәрелгәннәр иде. Шулай бер ел ярым дуслашып йөргәч, мин Альмирага өйләнешергә тәкъдим ясадым. Ул риза булды. 1969 елның 11 апрелендә, мин икенче курста укыганда, без Казан шәһәренең Үзәк ЗАГСында язылыштык һәм тулай торакның унөченче бүлмәсендә тыйнак кына студент туе уздырып алдык. Гаилә тормышыбыз башланды, ләкин Альмира өченче катта үз бүлмәсендә, мин беренче катта унөченче бүлмәдә... Бергә торырга урын да, рөхсәт тә юк. Өйләнешеп аерым яшәве бер дә рәхәт түгел инде. Шунлыктан, мин читтән торып уку бүлегенә күчеп, тулай тораклан квартирага күчеп, эшкә урнашып, гаиләмне тәэмин итеп, тулы канлы тормыш белән яшәргә карар кылдым. Миңа бу вакытта 21 яшь иде.

Шунысын да әйтеп узу кирәктер, безнең Альмира белән ел ярым дуслашып йөрүебез – шулкадәр чиста, шулкадәр саф, бер-беребезгә карата шулкадәр ихтирамлы мөнәсәбәтләргә корылган иде ки, мин һәрвакытта берәр ялгыш сүз, яки аның хәтерен калдырырлык берәр ярамаган сүз әйтүдән сакланып йөрдем. Кая инде анда, бүгенге яшьләр кебек беренче күреп сөйләшүдән соң ук җенси мөнәсәбәткә керү... Әйтергә ярамаса да әйтим инде, әле без, өйләнешкәндә, хәзерге киноларда күрсәткән кебек, «җүнләп» үбешә дә белми идек, башкасын әйтмим дә инде...

Азып-тузып йөрмичә генә гаилә тормышын башлап җибәрдек. Җәй буе эзләп йөреп, Казанның Яңа Савин районында бер тавык сараена квартирага кердек. Аның «квартира» дип әйтерлек җире булмаса да, бергә тору өчен ярый иде. «Сөйгәнең белән шалаштa яшәү дә – оҗмахка тиң» дигәндәй, без тулы квартира хакы түләп торырга риза булып кергән бу «бина» – моннан 18 ел элек тавык сарае итеп ике такта арасына пычкы чүбе тутырылып ясалган 6 кв.м. зурлыктагы, ачык китап зурлыгындагы ике тәрәзә, «подтопка» дип аталган кечкенә генә мич кисәге булган куыш иде. 18 ел буена анда күселәр, тычканнар оялап, үзләренә күптөрле юллар салып, тишкәләп бетергәннәр иде. Шул «өйдә» 1970 елның 8 февралендә яраткан Айдар улыбыз туды. Көздән язга кадәр, балага салкын булмасын, дип ике сәгать саен мичкә ягып торабыз, ләкин җылы гына тормый, бөтен тишек-тошыклардан җил суырып бетерә. Иртәнге

чәйгә һәм бала юындырырга, дип кичтән алып кайтып куйган ике чиләк су идәндә торып, иртән торганчы боз ката иде.

Айдарга ике яшь тулган көнне урамда 40 градус салкын иде. Мин иртән эшкә киттем (мин ул вакытта Казан шәһәренең 80 нче урта мәктәбендә гарәп теле укытучысы һәм Татарстан Дәүләт музееның әдәбият бүлегендә фәнни хезмәткәр булып эшли идем). Дәресләрдән соң педсовет утырышы булып, эштән соң гына кайттым. Айдарны котлап мәдәният институтында укып йөрүче Нурия сеңелем килгән булган, чәй эчтек тә йокларга яттык, алар өчәүләп сәкегә, мин үз урыныма. Бервакыт болар «пожар!...», «янабыз!» дип чырыйлап кычкырып мине селкеп уяттылар. Мин сикереп тордым да, иң әүвәл урын-җире белән баланы күтәреп алып, Альмира белән Нурияне алга төрткәләп ишекне ачып сикереп кенә чыктык, яна торган түшәм җимерелеп килеп тә төште һәм кибеп беткән такта стеналар салам кебек янып 10 минут эчендә юкка чыкты... Без төнге сәгать 1 дә, 40 градуслы салкында урам уртасында бала күтәреп, бернәрсәсез басып калдык... Ул төнне күршеләрдә утырып чыктык...

Янгын чыгуның сәбәбен соңыннан белдек, күрше әбинең үзләренә каршы якта гына торучы кияве бик әшәке кеше булып, гел аракы эчеп, боларга кереп һаман талашып, аракы сорап җаннарына тия икән... Көндез кереп тагын аракы сораган бу, әбинең аракысы булмаганмы, булып бирмәгәнме, белмибез, кияү шуңа үч итеп төнге сәгать бердә әбинең утын сараена ут төрткән. Кипкән утыннар шунда ук дөрләп янып киткән һәм безнең квартира хуҗаларының утын сараена күчкән, ә алар анда язга ит кыйммәтләнгәч суеп сатар өчен көздән алып симертә торган 6 мы, 8 ме баш сарык асрыйлар иде. Күршеләренең «пожар!...» дип кычкырган тавышка уянып сикерешеп чыгалар да, болар, ут эченнән сарыкларын коткарырга керешәләр, ә безнең ишеккә тибәргә дә башларына килми, әгәр Нурия сеңелем йоклап китә алмыйча безнең «өебезнең» стеналарына ут капканын сизмәгән булса, без шунда янып та үлгән булыр идек... Шулай итеп, безне Аллаһы тәгалә Үзе саклап калды...

Икенче көнне бала күтәреп, күрше урамда яшәүче, миннән соң гына өйләнеп, хатыны Резидә һәм, Айдардан бер айга гына соңрак туган кызлары Лилия белән бер әбинең кечкенә генә бүлмәсендә квартирада яшәүче сабакташым Рифкать Муллиннарга барып кердек. Рәхмәт, якты йөз белән каршы алдылар, кайгыбызны уртаклаштылар һәм үзләренә дә бик кысан бүлмәләрендә, өстәл астында безгә урын тәкъдим иттеләр... Кая барасың, без бик шатланып риза

булдык... Рифкать үзләреннән ерак түгел яңа йорт төзелешендә төнге каравылчы булып эшли иде һәм мин аның белән төннәрен аның «вагонка»сына кунарга китә идем, ә Альмира, Пермь өлкәсенең Барда районындагы Каенавылда яшәүче энисе Айдарны килеп алып киткәнче бер атна шул өстәл астында йоклады.

Шулай бер көнне, очраклы рәвештә генә мине эштә, әдәбият бүлегендә, Дәүләт музее директоры Владимир Михайлович Дьяконов күреп алып үзенең бүлмәсенә чакырды. Кергәч үк: «Әнвәр, синең белән шундый зур бәхетсезлек булган икән, ә син миңа кермичә йөрисең, мин сиңа нәрсә белән булыша алам, нинди ярдәм кирәк, барысын да әйт!...» дип миннән нәрсә булганын сөйләтте. Завхозны чакырып алып, безгә берәр «раскладушка», берәр йокы капчыгы, атнага ике тапкыр чиста урын җир бирергә кушып, хезмәткәрләр эштән кайтып киткәч, үзем эшли торган әдәбият бүлегендә яшәргә рөхсәт итеп: «Күпме кирәк – шукадәр яшәгез, нәрсә кирәк – сора, һәрвакытта ярдәм итәрмен» дип озатып чыгарды. Аннан соң ул миңа өч айлык эш хакы күләмендә матди ярдәм күрсәтте...

Шунысына йөрәгем әрни иде: Альмира ул вакытта телефонистка булып эшкә урнашкан иде, беренче сменада эшләгәндә көндезге сәгать 1 дә эштән кайтып, 1 чәшкә чәй дә эчә алмыйча шыкыраеп катып, кичке сәгать 6 да бөтен хезмәткәрләр кайтып киткәнче көтеп, урамда йөри торган иде...

Без шул әдәбият бүлегендә ярты ел яшәдек... Акчаларыбыз да янган иде, матди ярдәм акчасына бер электр чәйнеге сатып алып, шунда баштан икебезгә пакеты 9 тиенлек 4 кечкенә пакет вермишель ашы пешереп ашыйбыз, аннан соң юып, эченә чәен салып чәй кайнатып эчәбез, аннан соң тагын юып, су кайнатып, туалетка барып, раковина тишеген кулъяулык белән тыгызлап куябыз да, киемнәребезне юабыз...

Музейда 5 ай яшәгәч, мине Мәгариф министры Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтов чакыртып алды да: «Әнвәр, син минем карап торган бердән-бер гарәп теле укытучым һәм минем ышанычымны аклап әйбәт кенә эшләп тә киләсең, мин синең авыр хәлеңә кереп, шәһәр идарәсе белән сөйләшеп, сиңа иске булса да бер өйдән бер квартира юллый алдым. Яңа өйдән булдырып булмады, агач өй булса да, бер ел яшәсәгез, алдагы елда ул урыннар сүтелеп, сез яңа квартира алачаксыз!...» дип канатландырып җибәрде... Барып карадык, безнең баштан үткәннәребездән соң зур мичле, 18 квадрат

метрлы квартира – патша сарае төсле тоелды. Менә бәхет, ниһаять баш өстебездә үзебезнең түбәбез булды!...

Гомуми коридорны; һәр квартирага сыңар керосинканы; туалетның тышта булуын; һәр елны көздән алып язга кадәр туңып шартлап ярылган һәм гамәлгә яраксыз колонкадан су килмәгәч, көн саен эштән соң, өчәр-бишәр чакрым ике чиләк белән су эзләп йөрүләрне; ә минем айлык эш хакым 105 сум гына булганга күрә, тормыш итәргә җитәрлек акча эшләр өчен миңа берничә урында эшләргә туры килгәнне; ике катлы агач өйнең беренче катта яшәүче күршеләребез утын сатып алырга акчаларын кызганып электр урлап ясалма «кәҗә» куеп чыгып китеп, ел саен кыш көннәрендә өчәр-дүртәр тапкыр ут чыгарып, безнең икенче каттан турыдан-туры кар өстенә тәрәзәләрдән генә сикерүләрне һәм башка күп санлы кыенлыкларны исәпкә алмаганда, бу өйдә дә яшәп була иде әле...

Аллаһының рәхмәте белән һәм министрның ышандыруы белән без бу өйдә 15 ел «рәхәтләнеп» яшәдек... 1984 елның 29 мартында сөекле Айгөл кызыбыз туды. Альмира ул елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле кафедрасында «учебный мастер» булып эшләде. Айдар улыбыз өйдән ерак булмаган, элек 1974 елның май аена кадәр үзем гарәп теленнән укыткан 80 нче мәктәптә укыды. Ул вакытта Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән фәнни хемәткәре булып эшләгәндә, 1985 елның декабрендә, тавык сараенда яшәп янгында исән калган урыннан ерак булмаган җирдә, миңа, инде хәзер «39 нчы квартал» дип аталган урында, тугыз катлы «ленинградка» дип аталган өйдән өч бүлмәле квартира бирделәр. Без күчеп киткәннән соң да, без 15 ел буе «бик бәхетле» булып гомер кичергән агач өебез-шактый озак еллар сүтелмичә торды. Без элеккеге күршеләребезне сагынып, еш кына хәл белергә барып йөри идек...

Яңа яшәү урынына күчкәч, Альмира: «Айгөл кызым үз янымда булыр», дип безнең йортта гына урнашкан балалар бакчасына эшкә урнашты һәм кешеләр кебек иркен өйдә иркенләп, рәхәтләнеп яши башладык. Берничә елдан соң Айдар улыбыз армиягә китеп исән-сау хезмәт итеп кайтып, университетның үзебез укыган татар теле һәм әдәбияте бүлеген бик яхшыга тәмамлап чыгып, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының аспирантурасын да төгәлләп, андагы халык авыз иҗаты бүлегендә фәнни хезмәткәр булып эшләде... Өйләнде, быел 10 нчы сыйныфны тәмамлаучы Ка-

мил исемле улы һәм 8 нче сыйныфны тәмамлаучы Зөлфия исемле кызы бар...

Айгөл кызыбыз Казан шәһәренең 13 нче гимназиясендә һәм 16 нчы балалар музыка мәктәбендә берьюлы укып, 9 сыйныфтан соң Казан музыка училищесының хор-дирижер бүлегенә укырга кереп, аны бик яхшыга тәмамлап, Казан дәүләт консерваториясенең җыр сәнгате («вокал») бүлегенә укырга керде. Аны кызыл диплом белән тәмамлап, аспирантурасын да уңышлы төгәлләп куйды. Г.Камал театрына музыкаль әсәрләрдә уйнар өчен штатка алдылар, хәзер ул шунда эшли. Ире Салават белән Җәмилә исемле бер «тәти» генә кыз үстерәләр, майның 21 ндә бер яшь тула Аллаһы боерса...

Без Альмира белән сөенеп, шатланып, иң әүвәл, Аллаһы Тәгаләгә биргәннәре өчен мең-мең рәхмәт әйтеп, аннан соң тормышыбыздан бик канәгать булып, бик бәхетле булып яшәп торабыз, әлхәмдү лилләһи раббил-галәмин!... Булганына шөкер итеп, булмаганына өметләнмичә, рәхәтләнеп яшибез. Әнә шулай итеп, 6 квадрат метрлы тавык сараенда яши башлап, зур тормыш сынаулары аркылы үтеп, бу көннәрдә өйләнешүебезнең 45 еллыгын билгеләп үтә торган вакытта, үзебезчә булдыра алган кадәр тормышыбызны көйләп, үзебезчә барлык мөмкинлекләребезне булдырып, рәхәт гаилә тормышында яшәвебезгә без бик шат... Инде Раббем Аллам, бер Ходаем тигезлектән генә аермыйча, урын өсләрендә ятарлык каты авыруларсыз яшәрлек матур картлык кына бирсен иде инде!...

Татар халкында «Җүләр – хатынын мактар, акыллы – атын мактар» дигән әйтем бар, янәсе хатын-кызны мактарга ярамый!... Моңа мин ирләр шовинизмыннан чыгып әйтелгән сүз, дип карыйм һәм мине «җүләр икән бу» дисәләр–диярләр, ләкин мин моңа каршы «Мактый алырлык хатының бар икән, син аны макта һәм: «минә минем хатыным нинди!» дип үзең дә мактан!» дип җавап бирер идем. Әйе, чыннан да, миңа Аллаһы Тәгалә мактанырлык хатын бирде. Альмира бик уңган, тырыш, чиста, эшчән кеше булды. Ул түзем, сабыр холыклы, Аллага шөкер, юк-бар белән ваксынып җан кыйнамады... Нинди генә авырлыклар күрсәк тә, ул мине тынычландырып, «ярар, борчылма, үз вакыты белән барысы да булыр әле!», дип әйтеп килде. Ул балалар һәм оныклар өчен кайгыртучан һәм яратучан әни һәм дәү әни булды, минем өчен ышанычлы һәм тугрылыклы хатын булды. Ул беркайчан да «тегe яки бу әйбер кирәк, матур кием-салым, тәмле ризык, иркен һәм бөтен мөмкинлекләре булган заманча квартира, машина һәм башка

әйберләр кирәк!» дип аптыратмый, нәрсә барына риза булып, булмаганына өметләнмичә, тавышланмыйча, боларның берсе дә ул сорап кына булмаганын, ә фәкать авыр хезмәт нәтиҗәсендә генә килгәнен аңлап, акыл белән яши. Ул минем фәнни эшемә дә бик нык булыша, элек минем бөтен китапларымны, язган барлык хезмәтләремне машинкада басып ярдәм иткән булса, ул хәзер мине бөтен вак-төяк тормыш мәшәкатьләреннән бушатып, фәкать иҗат белән генә шөгыльләнергә барлык шартларны тудырып тора. Мин иртәдән төнгә кадәр эшләп, иҗат эшләре белән генә шөгыльләнеп утырам... Әгәр дә ул миңа шундый шартлар булдырып тормаса, мин бу кадәр эшләрне, әлбәттә, башкара алмас идем... Мин бу дөньяда, тормышта, фәндә, иҗатта нәрсәгә булса да ирешкәнмен икән, аларның яртысы – Альмиранықы, дип саныйм... Мин шуңа күрә Альмирага бик рәхмәтлемен. Инде күптән вафат булган әтисе белән әнисенә дә шундый ипле, итагатьле, уңган-булган һәм тәрбияле кыз үстергәннәре өчен мең-мең рәхмәт укыйм... Урыннары җәннәттә булсын иде!... Амин!...

Мин үземне 466 төркемнең иң бәхетле кияве итеп саныйм, һәм сезнең барыгызны да бик хөрмәт итәм, сау-сәламәт һәм бәхетле булуыгызны телим!...

*Казан дәүләт университетының элеккеге 476 нчы төркем шәкерте, 466 нчы төркемнең иң бәхетле кияве Әнвәр Нәҗип улы Хәйруллин (Әнвәр Хәйри). 2014 санәнең 23 нче март көне.*

*Чыганак: Кариева Ләйсән. Мәңгелек мәхәббәт юлыннан. (Остазлар һәм сабакташлар). Казан, 2014. 194–204 б.*

**Әнвәр Хәйри**

# ТӨРКИ-ТАТАР КУЛЪЯЗМАСЫ

Борынгы төрки кулъязма китаплар; маһир халык һөнәрчеләре тарафыннан нечкә зәвык һәм гаҗәеп осталык белән эшләнгән, күңелгә рәхәтлек һәм ләззәт бирә торган шәмаилләр; Идел буе Болгар дәүләте чорында алтыннан, көмештән һәм бакырдан ясалган бизәнү әйберләре, савыт-сабалар һәм сугыш кораллары, металлга чокып язылган көнкүреш әйберләре; алтын, көмеш һәм гади җепләр белән чигеп язылган тукымалар, япмалар; зур осталык белән бизәлгән һәм чокып, калкытып язылган борынгы кабер ташлары; төрле стильдә башкарылган матур язу үрнәкләре, язу әсбаплары һәм башка бик күп төрле әйберләр – болар барысы да борынгы болгар-төрки-татар бабаларыбызның язу һөнәренә, язу сәнгатенә булган олы ихтирамы турында сөйли. Аларның гаҗәеп осталыкларына карап сокланасың һәм алар өчен горурлык хисләре кичерәсең...

Борынгы төрки кабиләләрнең һәм халыкларның сөйләм теле чагылган язулы ядкәрләр аз сакланган. Безнең көннәргә кадәр килеп җиткән текстларның күбесе әдәби тел ядкәрләре булып та торалар.

Борынгы төрки әдәби телләрнең иң элгәре үрнәкләре – төрки рун язулары теле (VII–IX йөзләрдә язылган Орхон-Енисей ташъязма ядкәрләре). Борынгы төрки әдәби телебез – угыз һәм уйгыр кабиләләре теле җирлегендә формалашкан. Төрле халыклар һәм төрле катлам кешеләре тарафыннан кулланылуы сәбәпле, әдәби телебез торган саен шомарган, торган саен камилләшкән, баеган. Борынгы төрки әдәби телдә иҗат ителгән иң әһәмиятле ядкәрләр булып Тоньюкук (VIII йөз), Күлтәгин (732 ел), Билге каһан (735 ел) ташъязмалары саналалар. Төрки телле халыкларга билгеле булган борынгы уйгыр теле җирлегендә кайбер әдәби телләр дә формалашкан. Аның тәэсирендә XI–XII гасырларда Караханилар мөселман дәүләте территориясендә уйгыр әдәби теле оеша. Бу телдә (уйгыр һәм гарәп графикасында) А. Йүгнәкинең «Һибәтел-хакаикъ» («Хакыйкатьләр бүләге»), Й. Баласагунлының «Котадгу белег» («Игелекле белем»), Мәхмүд Кашгариның «Диване лөгатет-төрк» («Төрки сөйләшләр җыентыгы») әсәрләре һәм башка ядкәрләр иҗат ителгәннәр.

XIII–XIV гасырларда Алтын Урда җирләрендә, Сыр Дәрьяның түбән агымыннан көнбатышка табан җирләрдә «Харәзем төркие» дип аталган әдәби тел барлыкка килгән, аның нигезенә җирле кыпчак һәм угыз кабиләләре теле салынган. Бу телдә Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия» («Пәйгамбәрләр турында кыйссалар»), Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е, Харәзминең «Мәхәббәтнамә»се һәм башка гарәп һәм өлешчә уйгыр язулы ядкәрләре иҗат ителә.

Урта гасырлардагы төрки әдәби телләр үсешендә соңгы этап буларак, чыгтай теле барлыка килә. Аның нигезендә XVI–XIX гасырларда төрки әдәби телнең төбәк вариантлары, шул исәптән Идел буе төрки-татар теле формалаша. Моннан тыш, XIII–XIV гасырларда кулланылыш даирәсе бик киң булмаган борынгы төрки әдәби телләр булганлыгы билгеле. Боларга мисал итеп Идел-Чулман буендагы гарәп язулы кабер ташларындагы болгар телен; Мысыр һәм Сүриядә язылган кульязмаларда кулланылган мәмлүк-кыпчак әдәби телен; Кече Азия һәм Кавказ арты ядкәрләренең сәлҗүк телен; XIII–XIV гасырларда гамәлдә булган кыпчак сөйләм телен; латин язуында язылган «Кодекс Куманикус»ны (1303 ел) һәм Каменец-Подольскида табылган әрмән язулы суд актларын күрсәтергә була...

Идел буе Болгар дәүләте һиҗри белән 310 елның 16 мөхәррәм көнендә, ә безнеңчә 922 елның 21 май көнендә Ислам динен – үзенең барлык җирләрендә рәсми дәүләт дине итеп игълан итә. Әмма ләкин, Ислам дине – Идел һәм Чулман буйларына, безнең борынгы бабаларыбыз тормышына аннан 200–230 еллар чамасы элегрәк үтеп кергән булган инде.

Ислам дине белән бергә, борынгы болгар-төрки бабаларыбызның рухи тормышында биниһая зур роль уйнаган гарәп язуы да кабул ителә. Мәгълүм булганча, гарәп язуы гамәлгә кергәнче, борынгы бабаларыбыз «чөй язу» («руник язу») белән файдаланган булганнар. Ә гарәп язуы кергәч, бу язу әкренләп кулланылыштан төшеп калган. Гарәп язуының иң борынгы формасы булып «куфи» язуы, ягъни «ноктасыз» язу санала. Беренче күчереп язылган Коръән нөсхәләре дә нәкъ менә шушы «куфи» язуында язылганга күрә, бу язу – изге язу саналган.

Гарәп язуының керүе болгар-төрки бабаларыбызның рухи тормышында шулкадәр зур әһәмияткә ия була ки; алар мөселман дине чәчәк атып килә торган Шәрыкътагы кебек үк, Ислам дине һәм фикыһ (мөселман юриспруденциясе), мәдәният һәм сәнгать, фән

һәм әдәбият, тарих һәм фәлсәфә, тыйбб (медицина) гыйлеме һәм мәгърифәт һәм үзләре өчен гаҗәеп кызыклы башка бик күп һәм яңа әйберләр белән кызыксыналар. Бу очракларда язуның мөһимлеге һәм кыйммәте әйтеп бетергесез зур була.

Борынгы бабаларыбыз нинди генә әйберләргә язмаганнар... Археологик тикшеренүләр нәтиҗәсендә безгә бабаларыбызның алтынга, көмешкә, бакырга, тимергә, ташка, сөяккә, үгез тиреләренә күптөрле язулар язып калдырганлыклары мәгълүм булды. Алар тимер йозакларга, көмеш һәм бакыр тәңкәләргә, балдак, беләзек кебек бизәнү әйберләренә, ук-җәяләргә, кылыч-калканнарга һәм башка бик күп әйберләргә матур итеп чокып яисә уеп яза торган булганнар. Безгә алардан кыя ташларын ватып алып, шомартып, төрле үсемлекләрдән торган милли бизәкләр белән бизәп, чокып яки калкытып язылган тарихи истәлекләр калган. Әлеге язулар аркылы болгар-төрки бабаларыбыз үзләренең эчке кичерешләрен, табигатькә һәм әйләнә-тирә мохиткә үзенең хәерхаһ мөнәсәбәтен, уй хыялларын, тормыш-көнкүрешләрен, акыл көчен һәм сәләтен-тапкырлыгын, тарихи вакыйгаларын, кыскасы, үз чорының бөтен матурлыгын, рухи һәм матди рәвештә безгә изге мирас итеп җиткерергә тырышканнар.

Фәндә гарәп язуының (почеркының) 120 төрле үрнәге барлыгы мәгълүм. Шуларның 30 төре – Октябрь инкыйлабына кадәр бөтен мөселман һәм төрки-татар дөньясында иң актив кулланышта булган. Бу язу төрләре Россиянең Идел-Чулман буе, Урал алды, Урта Азия, Казахстан, Кыргызстан, Кавказ җирләрендә яшәүче барлык мөселман һәм төрки-татар халыклары мәдрәсәләрендә ибтидаи (башлангыч) сыйныфларда ук инде яттан өйрәтелеп, бала вакытта канга-хәтергә сеңдерелә торган булган. Бу 30 төрле язуның һәрберсенең аерым бер вазыйфасы булган. Мәсәлән, Коръән Кәримне язар өчен бер төрле язу, әдәби, тарихи, фәлсәфи, гомумән, фәнни әсәрләрне язганда икенче төрле язу, проза әсәрләре язар өчен өченче төрле язу, шигъри әсәрләр иҗат итәр өчен дүртенче төрле язу, патша фәрманнары язу өчен бишенче төрле язу, сугылган акчаларга язар өчен алтынчы төрле язу, эш-канцелярия кәгазьләре язар өчен җиденче төрле язу, мәхәббәт хатлары язышу өчен тагын аерым язу, гомумән, тормыш итәр өчен һәр өлкәнең, һәр тармакның үз язу стиле булган. Димәк, әгәр мәдрәсәдә укучы шәкерт әлеге 30 төрле язуның бер генә төрен үз вакытында тиешле дәрәҗәдә ятлап өйрәнеп, хәтеренә сеңдереп калмаса, ул – тормыш итәргә тулы-

сынча әзерлекле кеше булып җитешә алмаган. Шуңа күрә, бу фәнне үзләштерүгә элеккеге мәдрәсәләрдә аеруча нык игътибар бирелә торган булган.

Төрки-татарларда һәм гомумән, мөселман халыкларында язу һөнәре, бигрәк тә китап язу һөнәре – элек-электән иң мактаулы, иң кадерле һәм иң изге һөнәр саналган. Шуңа күрә, аны 30 төргә бүлеп кулланганнар да... Шуннан чыгып, язуның пөхтәлегенә, матурлыгына һәм ачыклыгына гына түгел, ә матур итеп бизәлүенә дә зур игътибар бирелгән. Эчтәлеге нинди булуга карап, китапның албите (титул бите) төрле бизәкләр белән бизәлә торган булган. Иң еш кулдан күчерелеп языла торган китаплардан Коръән һәм аның тәфсирләре булган. Әлбәттә, болгар-төрки бабаларыбыз тарафыннан урта гасырның атаклы галимнәре, шагыйрьләре һәм язучыларының фәнни, тарихи, әдәби әсәрләре дә укылганнар һәм кулдан-кулга йөреп күчерелгәннәр. Коръән һәм дини эчтәлектәге китаплар «куфи», «нәсех», «рәйхани» яки «сөлес» язуы белән, гадәттә эре хәрефләр белән күчерелгәннәр. Кайвакытта текстның хәрәкәләренә (хәреф асты һәм өсте билгеләренә) тәңгәл килерлек бизәкләр белән дә бизәгәннәр. Дөньяви эчтәлектәге китаплар төсле бизәкләр белән бизәлә торган булган. Әдәби, фәнни һәм тарихи әсәрләр XIV гасырга кадәр «нәсех» һәм «тәгъликъ» стилендә язылган. Ә XIV–XV гасырлар арасында шул ике язу рәвеше бергә кушыла да, «нәстәгъликъ» язуы барлыкка килә. Баштан ул матур язу өчен генә кулланылса, соңыннан «нәсех» һәм «сөлес» язуларын кысрыклап чыгара һәм дини эчтәлектәге китаплар да аның белән генә языла башлый. Бу язу төре төрки-татарларда 1930 елга кадәр яшәп килә. Ул, бер яктан башка язуларга караганда гадирәк, икенче яктан, язу өчен матуррак һәм тиз язу өчен уңайрак булган.

Әле исемнәре аталган язу төрләреннән башка тагын «мөхаккак», «сиякат», «иҗазәт», «тәүкыйг», «рәка», «шикәстә», «дивани», «дивани җали», «кырма», «тавуси», «сөнбөли», «гөлзар», «мөдавар», «шәҗәри» һәм башка язу төрләре дә булганнар.

Төп кулланылышта булган әлеге язулар, урта гасырларның бер сәнгать төре буларак, үз чорының сәнгатькә һәм гамәлгә булган ихтыяҗын канәгатьләндергән. Аның үсешенә һәм үзгәрешенә шул чорның сәяси, тормыш-көнкүреш һәм мәдәни шартлары көчле йогынты ясаган. Аны үстерүгә фарсы һәм төрки телләрендә сөйләшүче һәм гарәп язуы белән файдаланучы күп кенә халыкларның язу осталары күп көч куйганнар. Алар, гарәп осталары эшләгән язу

үрнәкләре белән генә чикләнеп калмыйча, үзләре дә аерым язу үрнәкләре уйлап чыгарганнар.

Шундый язулар белән инде IX гасыр ахырында – X гасыр башында ук болгар бабаларыбызның дини әдәбияттан тыш тыйбб (медицина), тарих, фәлсәфә, әдәбият һәм башка фәннәргә караган китаплар язганлыклары фәндә мәгълүм. Аннан соң, X гасырда, инде шул чордагы бөтен Көнчыгышка танылган табиб Әбү Гали Синаның, Харәзем табибы Габделхәсән әл-Хаммарның, энциклопедик галим Әбү Рәйхан әл-Бирунинының, шулай ук мәшһүр галим Мөхәммәд ибне Муса әл-Харәзминең һәм Урта Азиядән сәүдә кәрваннары белән килеп җиткән башкаларның әсәрләрен укып һәм кулдан күчереп язып, борынгы бабаларыбыз бөтен Болгар дәүләтенә тараткannар. Шундый күркәм үрнәк Болгар дәүләтендә төрле фәннәр үсешенә зур этәргеч ясаган, һәм болгарлар арасында XII гасырның беренче яртысында Ягкуб бине Ногманның «Болгар тарихы» китабы языла. Шул чорда яшәгән Борһанетдин Ибраһим Йосыф әл-Болгари риторика (матур сөйләм сәнгате), гади дарулар турында махсус әсәрләр һәм әс-Сәмәркандинең «Әдәб» исемле китабына аңлатма язган.

Ислам дине кабул ителүгә кадәрге вакытларда иҗат ителгән халык авыз иҗаты ядкәрләренең («Бәдавам» һәм башкалар) бүгенге көнгә кадәр сакланулары, X–XII гасырларга караган бәетләр, XI гасыр башында яшәгән тел галиме Мәхмүд Кашгари аркылы безгә килеп җиткән җырлар, тарихи риваятьләр, язу мәдәниятенең керүе һәм таралуы, мәчет-мәдрәсәләрнең, руханиларның һәм башка укымышлы кешеләрнең барлыкка килүләре, кабер ташлары язулары, дин һәм күптөрле фән тармакларына караган китаплар язылу, Шәрыкъ галимнәре һәм язучылары тудырган әсәрләрнең болгар бабаларыбыз тарафыннан укылулары, кулдан күчерелеп таралулары – тора-бара XIII гасыр башында Болгарда Кол Галинең «Йосыф вә Зөләйха» әсәре кебек даһи әсәр иҗат ителүгә китергән. Бу әсәр һәм «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Фәрхад һәм Ширин», «Таһир белән Зөһрә», «Мәүлед» һәм гомумтөрки тел иҗат мирасы буларак тудырылган башка зур күләмле шигъри әсәрләр кулдан күчерелеп, бик еракларга таралганнар. Алар Идел-Чулман буе, Урал алды җирләреннән тыш Урта Азиядә, Казах, Кыргыз далаларында, Кавказда яшәүче мөселман төрки халыкларга да барып җитеп, аларның да милли рухи хәзинәләренең, рухи мәдәниятләренең нигез ташы булып хезмәт иткәннәр. Шулай ук, гомумтөрки мираска әйләнеп калган дини эчтәлекле «Нәсыйхәтес-салихин», «Тәгъбирнамә», «Ва-

сыятнамә», «Рузнамә», «Кыйссасел-әнбия» («Пәйгамбәрләр тарихы») кебек чәчмә әсәрләрен һәм башка бик күп тарих китаплары да шундый ук бәхетле язмышка дучар булганнар.

Ачык, укый алырлык, чиста, матур, аңлаешлы язу белән язылган борынгы төрки-татар кулъязмаларын уку – үзе бер рәхәт ул. Аларны укыганда шул чорлардагы вакыйгалар күз алдына килә, үзеңне шул вакыйгалар шаһиты итеп тоясың, әйтерсең лә син ниндидер бер тылсым дөньясына эләгеп, алар янында йөрисең, сөйләшәсең, үзеңне иң бәхетле кеше итеп сизәсең, ә горур болгар бабаларыбыз серле елмаеп, күз сирпеп кенә сиңа сәлам бирәләр төсле...

Ул борынгы кулъязмаларны укуның бер серенә төшенсәң, сүз башында, сүз уртасында һәм сүз соңында сузык авазларның ничек язылу үзенчәлекләрен, аннан соң тартык авазларның кушылып язылу үзенчәлекләрен белсәң, шулар өстенә борынгы кулъязмалар белән эшләү тәҗрибәң дә булса, аларны укуның бернинди катлаулылыгы да юк... Әгәр китапны күчереп язучы игътибарлы булып, барлык сүзләрне дә дөрес язса, шул ук, бер үк язу белән язылган гарәп, фарсы, төрек, борынгы төрки һәм борынгы уйгыр телләрендәге язуларны бер үк дәрәҗәдә эшкәртәсең, эш итәсең, тәрҗемә кыласың, тарихи аңлатмалар бирәсең...

Миңа ярты гасырга якын фәнни эшчәнлегем вакытында бихисап күп кулъязма чыганаклар белән эш итәргә туры килде. Идел-Чулман буйларында язылган чыганакларны миңа Казанда гына түгел, ә Ташкент һәм Бохара китапханәләрендә дә, архивларында да, Санкт-Петербург, Мәскәү, Уфа, Оренбург шәһәрләренең архивларында һәм китапханәләрендә дә бик күп күрергә һәм эш итәргә насыйп булды. Миңа гарәп хәрефләре белән язылган әзәрбәйҗан телендәге бик зур күләмле «Искәндәрнамә» поэмасын да кулъязма хәлендә укырга туры килгәне бар; Дагстанның кумык телендәге борынгы кулъязма әсәрләрен дә; төрек телендәге борынгы язмаларны да, үзбәк телендәге кулъязма китапларны да; борынгы һәм хәзерге уйгыр телендәге ядкәрләрне дә; Кытай, Төркия, Польша, Румыния, Венгрия, Белоруссия, Литва, Латвия татарларының гарәп хәрефле борынгы кулъязма китапларын да; гомумән, шактый гына төрки халыклар телендә иҗат ителгән чыганакларны укып карарга насыйп булды. Ни гаҗәп, язу алымнары да, стильләре дә төрледән–төрле булса да, аларның барысын да укып та, аңлап та була. Чөнки аларның хикмәтләрен генә белергә кирәк... Әмма ләкин, баштан аларның әлеге шул хикмәтләрен, тел һәм язу үзенчәлекләрен төшенер өчен шактый

вакыт тирләп-пешеп эшләп утырырга кирәк. Бер төшенсәң, аннан соң эшләр җайланып китә...

Борынгы теләсә нинди гасырда язылган, теләсә нинди эчтәлектәге төрки-татар кулъязмалары белән эш итә белү – аларны укып мәгънәләренә төшенү һәм кирәк икән – тәрҗемә итә алу, аннан соң аларга тасвирлама һәм аңлатмалар яза белү – үзен «Галим» дип санап йөргән һәр кешегә, бигрәк тә тарихчыларга (чөнки «тарих» сүзе үзе үк борынгылыкны, узган заманны аңлатып тора), филологларга, философларга, мәдәният һәм сәнгать белгечләренә, гомумән, гуманитар фәннәр өлкәсендә эшләүче һәр белгечкә мәҗбүри белергә тиешле изге бурыч, дип саныйм...

Борынгы кулъзмалар белән эшләү – һәркемнән иң әүвәл зур сабырлык-түземлек, зиһен-хәтер көче, гыйлем тирәнлеге, бик зур тәҗрибә, биниһая зур тырышлык, тапкырлык, гаҗәеп көчле үҗәтлек, үз алдыңа куйган максатка ничек кенә булса да ирешергә теләү, намуслылык, актив кулланылышта булган гарәп, фарсы, төрек, борынгы төрки, борынгы уйгыр һәм башка шәркый һәм төрки телләрне камил белүең сорала. Болардан тыш, тагын, аналитик акыл белән тәвәккәллек һәм кыюлык та бик кирәк сыйфатлар булып торалар.

Бу сыйфатларга ия булып, сихри тылсым дөньясына чумып эшләүдән һәм яшәүдән дә рәхәтрәк һәм ләззәтлерәк тагын берәр төрле халәт табып буламы икән?... Чөнки син бу тылсым патшалыгының солтаны; бу өлкәдә синнән дә күп белүче башка берәү дә юк; төрле гасырларда, төрле телләрдә, төрле язу үрнәкләрендә язылган бу чыганакларны фәкать син генә укый һәм аңлый аласың; аларга синең генә тешең үтә; ул чыганаклар фәкать сиңа гына буйсыналар; сиңа гына үзләренең гасырлар төпкеленә яшергән серләрен ачалар; бабаларыбыз үзләре белән алып киткән гаҗәеп бай тарих серләрен һичбер ялгансыз, дөрес итеп ачып, бүгенге халкыбызга син генә кайтара аласың!... Башкалар егыла-тора акча һәм дөнья малы артыннан куган чакта, син бер үзең бу дөнья мәшәкатьләреннән аерылып, Бөек Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен дип, савап өчен дип, борынгы бабаларыбызның мирасларын кайтарып утыру – БӘХЕТ түгелмени дуслар!!!...

Бәхетле Әнвәр Хәйри.

*Чыганак: Идел. 2014. №4. 54–57 б.*

# ӘНВӘР ХӘЙРИНЕҢ ТӘРҖЕМӘИ ХӘЛЕНДӘ ҺӘМ ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ ИГЪТИБАРГА ЛАЕК ВАКЫЙГАЛАР*

1947 (2 декабрь) – Татарстанның Аксубай (элеккеге Тельман) районының борынгы Шәрбән (Шәһри Бану) авылында туган.

1954 – 1962 – Шәрбән сигезьеллык мәктәбе укучысы.

1958 – 1962 (җәй) – «Большевик» колхозының ат көтүе көтүчесе.

1962 (көз) Аксубай рус урта мәктәбе укучысы.

1962 (көз) – 1963 (яз) – Аксубай леспромхозының Шәрбән участогы урман кисүчесе.

1963 (җәй) – 1966 (җәй) – «Большевик» колхозының тракторчы һәм комбайнчы ярдәмчесе.

1963 – 1966 – Октябрь (хәзерге Нурлат) районының Колбай-Мораса урта мәктәбе укучысы.

1966 – 1967 – Казан театр училищесының татар актерлары бүлеге студенты.

1967 – 1969 (көз) – Казан дәүләт университеты тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенең көндезге студенты.

1969 – 1973 – Казан дәүләт университетының читтән торып укучы студенты.

1969 (сентябрь) – 1969 (декабрь) – Казан мехкомбинатының чимал цехында тире сыгучы гади эшче.

1969 (сентябрь) – 1974 ( май) – Казан шәһәрендәге 80 нче урта мәктәпнең гарәп теле укытучысы.

1969 (октябрь) – 1974 (май) – Татарстан дәүләт музееның әдәбият бүлегендә борынгы кульъязма һәм басма чыганаклар белгече, фәнни хезмәткәр.

1969 (октябрь) – 1984 (октябрь) – Татарстан дәүләт музееның төнге каравылчысы.

1972 (сентябрь) – 1973 (июнь) – Казан дәүләт университеты тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә гарәп теле укытучысы.

* Ә.Хәйри төзегән.

1972 (сентябрь) – 1973 (июнь) – Казан дәүләт педагогия институты тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә гарәп язуы (иске татар теле) укытучысы.

1973 (июнь) – Казан дәүләт университетын уңышлы тәмамлау турында диплом ала.

1974 (май) – 1991 (ноябрь) – СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының иҗтимагый фикер тарихы бүлеге фәнни хезмәткәре.

1974 (сентябрь) – 1976 (июнь) – КПССның Казан шәһәр комитеты каршындагы марксизм-ленинизм Кичке университетында фәлсәфә факультетының пропаганда бүлеген тәмамлап югары сәяси белем ала.

1974 (көзге, кышкы) – 1991 (язгы айларда) – Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында аспирантлар фәнни хезмәткәрләр өчен гарәп язуы (иске татар теле) укытучысы.

1974 (көзге, кышкы) – 1979 (язгы айларда) – Казан дәүләт педагогика институты тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә гарәп язуы (иске татар теле) укытучысы.

1979 (көзге, кышкы) – 1984 (язгы айларда) – Казан дәүләт педагогика институтының фәнни коммунизм кафедрасында һәм институт китапханәсендә фәнни хезмәткәр.

1975 (көзге, кышкы) – 1985 (язгы айларда) – Казан дәүләт университеты тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасында гарәп теле, гарәп язуы (иске татар теле) укытучысы.

1977 (көзге, кышкы) – 1982 (язгы айларда) – Казан авыл хуҗалыгы институтының тарих кафедрасында гарәп язуы (иске татар теле) укытучысы.

1985 (көзге, кышкы) – 1991 (язгы айларда) – Казан дәүләт мәдәният институтының тарих кафедрасында гарәп язуы (иске татар теле) укытучысы.

1980 (көзге, кышкы) – 1995 (язгы айларда) – Татарстан укытучылар белемен күтәрү институтында татар теле һәм әдәбияты кафедрасының рухи мәдәниятебез тарихы укытучысы.

1981 (көзге, кышкы) – 1986 (язгы айларда) – Казан дәүләт медицина институтының социаль гигиена кафедрасында татар халык медицинасы укытучысы.

1981 (көзге, кышкы) – 1991 (язгы айларда) – Казан шәһәре укытучылар йортында гарәп теле һәм гарәп язуы (иске татар теле) укытучысы.

1986 (көзге, кышкы) – 1991 (язгы айларда) – Татарстанның В.И.Ленин исемендәге Фәнни китапханәсендә гарәп язуы (иске татар теле) укытучысы.

1986 (көзге, кышкы) – 1996 (язгы айларда) – Татарстанның В.И.Ленин исемендәге Фәнни китапханәсенең, соңыннан Татарстан Милли китапханәсенең фәнни хезмәткәре.

1995 (язгы, кышкы) – 1996 (язгы айларда) – Татарстан гуманитар көллиятендә гарәп язуы (иске татар теле) укытучысы.

1969 – 1992 – Татарстан «Белем» җәмгыятенең иң актив бушлай татарча лекцияләр укучы лекторы.

1976 – 1991 – КПССның Татарстан Өлкә Комитетының пропаганда бүлеге каршындагы Лекторлар төркеменең штаттан тыш бушлай татарча лекцияләр укучы лекторы.

1974 – 1991 – КПСС ҮКна, КПСС ӨКна, КПСС ШКна, КПСС РКна, Республика прокуратурасына, Татарстан Министрлар Советына, Татарстан Верховный Советына халыктан килгән гарәпчә язулы моң-зар белән тулы хатларны бушлай укып тәрҗемә итеп, күчереп язып, адресатларына җибәреп торучы.

1991 (ноябрь) – 1995 (июнь) – «Мирас» журналының тарих һәм фәлсәфә бүлеге мөдире, җаваплы сәркатиб, баш мөхәрриренең беренче урынбасары, дин һәм әхлак бүлеге мөдире.

1996 (июль) – 1996 (ноябрь) – Татарстан Милли китапханәсенең гыйльми сәркатибе, сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегенең баш китапханәчесе.

1996 (декабрь) – 1997 (январь) – Татарстан Милли китапханәсенең директор урынбасары.

1997 елның 15 январеннән* – Татарстан Милли китапханәсенең сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

---

